PRESSA.RU

ЯҢӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№12 (300) – ДЕКАБРЬ 2016

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

2017: Экология һәм җәмәгать урыннары елы

Үз биеклегеңдә калу

Серле болгар калалары нәрсә көтә

КЫШ БАБАЙДАН ЯҢА ЕЛ ТАБЫНЫ

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Троицкая
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская
Линар Закиров
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Веб-редактор: Олеся Бондаревская,
bond@tatmedia.com
Авторлар: Гөлүсә Закирова, Катерина Котова,
Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Ната Смирнова, Александр Эшкинин
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Әхмәрова
Тышлыкта – Ната Смирнова фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: **3500** данә,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү
мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры
килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге
өчен редакция җавап бирми. «Промо» һәм «Медиа»
рубрикалары материаллары реклама-коммерция
нигезендә басыла.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № М-3213

Басарга кул куелды: 23.12.2016

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры:
Нина Әхмәтшина, nivlana@tatmedia.com,
тел. (843) 222-09-76

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Юлия Фәсахова, тел. (843) 222-06-05

Махсус проектлар бүлеге белгече:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ЧИРАТТАГЫСЫ!

Ел үтеп бара, үткәнгә таба тәгәри, хатирәләр акрынлап үз киштәсенә урнаша – кем өчендер бик күңелле булгандыр ул, кем өчендер юк, ә кем өчендер, бәлки, үз гомерендәге иң яхшысы да! Ничек кенә булмасын, календарьларда «2016» саны астында теркәлеп, шактый авыраеп барган еллар копилкасына күтәренке рух булып кереп өстәлде агымдагы ел. Яхшы вакыйгаларга бай булганга, инде узып баруын тою бераз гына күңелсез, билгеле. Хәер, вакытның, таныш җырда җырланганча, һава торышыныкы кебек үк, начар чагы юк ла ул – дөнья икътисадында ниләр генә булып бетмәсен, янәшәбездә һәрчак дусларыбыз, гаиләбез бар бит. Һәм – куанычка – яулап алынган уңышларыбыз да! Алар, һичшиксез, 2016ны кичеп, 2017гә дә безнең белән бергә атлап керәчәкләр. Тормышыбыздагы 365 көн белән исәпләнгән бу елның кайсы өлешләрен хәтеребездә сакларбыз, анысын бары үзебез генә хәл итә алабыз, әлбәттә. Тормышыбызны яхшырак, йә булмаса начаррак итә алу көченә башкалар ия түгел бит. Бары үзебез генә. Һәм уңыш та тик үзебезнең теләк-омтылышлардан, кәефебездән һәм көчебездән генә тора. «Минем 2017 нче елым» проектына без аларны сарыф итәргә әзердер бит?

Яңа ел белән, татарстанлылар!
Яңа бәхет белән!

СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фарит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе:
864 сум 24 тиен

КАЗАН. КҮРЕНЕКЛЕ ТАТАР ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ, ЯЗУЧЫ САДРИ МАКСУДИ.

Фото: Ната Смирнова

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Кайсы ишеккә иртә дә, кич тә шакырга мөмкин. Җинаятьләрне ачарга ярдәм итүче торак турында

8. Максатлар һәм чаралар. Кино, сулыкларны саклау һәм онкологик авыруларны профилактикалау елы нәрсә белән истә калды

16. Милли кадрлар мәсьәләсе. Йолдызлар ни өчен читкә атыла

20. Безне сокландырган кешеләр. «Татарстан» журналы версиясе буенча 2016 ел лауреатлары

24. Хакимият: яхшыдан – шәпкә. Чиновникны нәтиҗәле эшләргә ничек өйрәтергә

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

50. Кече ватан патриотлары. Күлле Кимегә – Сибгат Хәким янына

56. Яңа ел раритетлары. Чыршы уенчыгы ничә ел яши

60. Яңа ел маҗаралары. Фильмның сценарие язылган дияргә була

66. Кыш Бабай көчтәнәче. Яңа ел табынына улниләр әзерли

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:

www.protatarstan.ru

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

74. Дөньядагы иң гүзәл урын. Нью-Васюкины ни өчен Тәтеш дип атамаганнар?

80. Татарстан салалары. Яман бай авыл кайда урнашкан

83. Татарстан салалары. Атаклы чыптачылар авылы

86. Тарих сәхифәләре. Серле болгар калалары

90. Разил Вәлиев. Үз биеклегеңдә калу

94. Китап киштәсе. Вакыт шавы, яки Тарихи ретроспектива

104. Яман урын. Хәзинә эзләүче 77 кеше кайда үлгән

PRESSA.RU

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

26.11

Джанни Инфантино, ФИФА президенты – Татарстан башкаласында, Конфедерацияләр кубогы – 2017 гә җирәбәгә салу тантанасыннан соң:

– Татарстан – дөньяның энергия һәм футболга мәхәббәт белән янып торган төбәге. Монда күп милләт халыклары дуслыкта һәм татулыкта яши. Мин Казанны яратам! Мин Татарстанны яратам! Монда булу минем өчен фантастика белән бер.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

7.12

Вадим Поляков, WorldSkills 2016 Европа чемпионы – «Татарстан» журналына биргән интервьюсында:

– Җиңә алуыбызга әлегәчә ышанып җитә алмыйм! Көндәшләр бик тә көчле иде бит – аларны узуыма шаккатам. Чемпионатта барысыннан да авыры инструментка ияләшү булды. Бу минем өчен яңалык иде. Әмма үз-үземне кулга алуым ярдәм итте: тынычландым, вакытны дөрес бүлдем һәм, нәтиҗәдә, беренчелеккә чыктым. Минем «алтыным» – Татарстан хакына!

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

02.11

София Гобәйдуллина, композитор, – Казан ратушасында иҗат интеллигенциясе белән очрашуда:

– Мин җир йөзендә булган татарлыкны ана сөте белән сеңдердем диярге була… Миллилек тә табигать тарафыннан бирелгән иде. Һәм, әлбәттә, этнос минем әсәрләремдә әнә шул тирәннән килгән, тамырлардан иңгән кайтаваз рәвешендә яисә хәтта мелодиянең үзе аша ук чагыла. Әмма мин, сөт, тәрбия аша салынганнарга гына бәйле булып калмас өчен, эшчәнлегемдә һәрвакыт үзаңымны киңәйтергә омтылдым. Яңа киңлеккә чыгарга. Ни салынган булса, шуны активлаштырырлык итеп эшләргә. Безнең бит барыбызда да табигатьтән бирелгән нәрсәдер бар – ата-анадан, яшьлегебездән, ә нәрсәдер – мөмкинлек буларак бирелә…

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

КАЙСЫ ишеккә иртә дә, кич тә шакырга мөмкин

Үткән ел **НӘРСӘ** белән истә калды

Йолдызлар **НИ ӨЧЕН** читкә атыла

Безне **КЕМНӘР** сокландыра

Чиновникны нәтиҗәле эшләргә **НИЧЕК** өйрәтергә

PRESSA.RU

... Гомуми белем бирү мәктәпләре белән тәэмин итү Сыер абзарларын капиталь төзекләндерү Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү Балалар бакчалары төзү Яшүсмерләр клубларын капиталь ремонтлау Спорт мәйданчыклары төзү «Уңайлы мохит» программасы Социаль хезмәт күрсәтү стационар оешмаларын капиталь ремонтлау Балалар сәламәтләндерү лагерьларын капиталь төзекләндерү **Участковый йорты** Мәдәният объектларын капиталь ремонтлау ФАПлар төзү, сәламәтлек саклау объектларын капиталь ремонтлау Ветеринария хезмәте күрсәтү биналарын төзү Ветеринария берләшмәләрен һәм авыл хуҗалыгы идарәләрен капиталь төзекләндерү Участок ветеринария пунктларын төзү һәм капиталь төзекләндерү Силос-сенаж траншеяләрен төзү Яшелчә саклагычларын капиталь ремонтлау Тузган торак Социаль ипотека Күп балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү...

ПРЕЗИДЕНТ ПРОГРАММАЛАРЫ. НӘТИҖӘЛӘР

24 СӘГАТЬЛЕК ЭШ

Мал-мөлкәте юкка чыкса да, өйдә тавыш-гауга купса да... авыл халкы беренче булып участок полиция хезмәткәренең номерын җыя. Алар тәүлекнең теләсә кайсы вакытында килеп җитәргә әзер. Участковыйларны халыкка тагын да якынайту максаты белән 2013 елдан республика программасы буенча махсус йортлар – административ-торак комплекслар төзелә башлады. Бер түбә астында – 95 квадрат метр мәйданда участковыйның эш урыны да, торак йорты да урнашкан.

Автор:
Линар Закиров

ҖИНАЯТЬ КОДЕКСЫНЫҢ КИРӘГЕ ЧЫГА

Участковыйларның торак шартлары һәм эш тәртибе белән танышу өчен Апас районының Урта Балтай һәм Борнаш авылларына юл тоттык.

Илфат Нургалиев яши дә, эшли дә торган ипле генә участковый йорты әллә каян күренә. Элмә тактада аның кабул итү көннәре һәм вакыты язылган, кесә телефонының номеры да күрсәтелгән.

– Халык ял иткәндә, без эшлибез. Кеше эшләгәндә, киресенчә, ял итәбез, – дип елмайды Илфат. Ул 15 авылга күз-колак булып йөри, йорты Урта Балтай авылында урнашкан. Тумышы белән Апас районы Каратун авылыннан. Әңгәмәдәшем бу вазыйфага ике ел элек керешкән, аңарчы Мамадыш районында сак хезмәтендә эшләгән. Былтыр Яңа елны өендә каршылау бәхете тәтегән, авыл халкы бәйрәмне тыныч кына уздырып җибәргән. Сабантуйда да тәртипсезләнеп йөрүче булмаган.

Участковый йорты ике өлешкә бүленгән: бер ягында – эш урыны, икенчесендә – торак бина. Кабул итү бүлмәсендә заманча компьютер тора, диварга җитәкчеләрнең фотолары эленгән, ә шкаф киштәсендә төрледән-төрле кодекслар тезелгән.

– Кайсысы белән ешрак эш итәргә туры килә? – дип сорадым.

– Административ кодекс белән, тик кайвакыт Җинаять кодексына да мөрәҗәгать итәргә туры килә. Тормыш булгач, төрле хәлләр була. Башка авыллардагы участковыйлар белән үзара дус-тату без. Җинаять очраклары булганда, бер-беребезгә ярдәм итәбез, берүзеңә авыргарак туры килә бит, – дип сөйләде ул.

Урта Балтай авылы район үзәгеннән 20 километр ераклыкта урнашкан. Шуңа да карамастан, барлык участковыйларны көн саен иртән Апаста җыеп, киңәшмә үткәрәләр.

Әңгәмәдәшебез әйтүенчә, һәр авылда беркайда да эшләмичә, эчеп һәм башкаларны тынгысызлап йөрүчеләр бар. Андыйлар аерым контрольгә алына. Баксаң, «яшел елан» белән дуслашып йөрүче хатыннар да очрый икән.

– Кайвакыт халык атна буе шалтыратмый, ә кайбер атналарда шикаятьләр өсте-өстенә килә. Эшебезнең уңай ягы шунда: көне буе компьютер алдында утырмыйча, кеше арасында йөрибез, – дип сөйләде әңгәмәдәшебез.

Күптән түгел бер хуҗалык фермасыннан бозауларны урлап чыкканнар. Андый чакта участковый беренче булып җинаять урынына барып, шундагы кешеләр белән сөйләшә. Бозауларны эзләп табу өчен, Илфат Нургалиев авыл тирәсендәге юлларда, кибетләрдә урнаштырылган камераларның видеоязмаларын карап чыккан. Бер ай дигәндә кыңгыр эшнең очына чыканнар. Терлекне урлауда район кешеләре белән бергә читтән килүчеләр дә катнашкан. Угрылар мал-туарның бер өлешен суярга да өлгергән булган.

Фото: Александр Эшкинина

ӨЧ ТЕЛЕФОНЛЫ УЧАСТКОВЫЙ

Урта Балтай авыл җирлеге башлыгы Рифкать Хәбибуллин әйтүенчә, аларда Казахстаннан, Үзбәкстаннан килеп, гражданлык алмыйча яшәп ятучылар да бар.

– Тырыш кеше кайда да эшли, яши ала. Читтән килүчеләрнең күбесе аракы белән мавыга. Ялгыз яшәүчеләр дә бар. Әйтик, бер хатын-кыз, авылда буш йорт сатып алып, Казанда яшәгән абыйсын шушында алып кайтты. Ә абыйсының шәһәрдәге фатирында хәзер үзе яши. Авыл кешеләре арасында, «читтән килүчеләрне җибәрегез», дип әйтүчеләр дә бар, әмма мин аларга карата бер чара да куллана алмыйм. Тормыш һәр нәрсәне үзе урынына куя ул. Чегәннәр дә килеп маташты. Берара көтүчебез юк иде. Шулчак бер хатын-кыз эш сорап килде. Чегән икәнлеген белгәч, алмаска булдым.

– Хатын-кызның көтүче булып эшлисе килдеме?! – дим.

– Әйе, хатын-кыз көтүчеләр дә бар. Алар хәзер яңалык түгел инде, – диде ул.

Рифкать әфәнде әйтүенчә, полиция йортының Урта Балтайда урнашуы аңа да, авыл халкына да зур бәхет. Элек участковый халыкны 80нче елларда төзелгән клуб бинасында кабул иткән.

– Биредә еш буласызмы?

– Сирәгрәк булырга язсын. Ә шулай да участковый белән һәрвакыт элемтәдә, миндә аның өч номеры да бар, – диде авыл җирлеге башлыгы.

Илфат яшелчә үстерү белән мавыкмый, бакчасын чыршылар гына бизәп тора.

174 УЧАСТКОВЫЙ ЙОРТЫ

РЕСПУБЛИКАНЫҢ БАРЛЫК РАЙОННАРЫНДА ТӨЗЕЛГӘН (ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ БЕЛӘН БАЛТАЧ РАЙОНЫННАН КАЛА)

	2013	2014	2015	2016
Никадәр участковый йорты төзелгән:	83	40	39	18*
– республика бюджеты хисабына:	41	20	18	10
– җирле бюджет хисабына:	42	20	21	8
Бер йорт төзү күпмегә төшкән:	2,5 млн сум	2,5 млн сум	2,6 млн сум	3,7 млн сум

* 2016 елда Татарстанда участковыйлар өчен 18 йорт төзү планлаштырылган. 2016 елның 25 ноябренә 12 йорт кулланышка тапшырылган.



ГАЕПЛЕ КЕШЕ БЕРЕНЧЕ БУЛЫП ШАЛТЫРАТА

Райондагы икенче участковый йорты – Апастан 40 километр ераклыкта урнашкан Борнаш авылында. Илшат Мөһәмов, мәктәп укучылары сыман, тормышындагы яңа сәхифәне быел 1 сентябрьдә ачып җибәргән – участковый булып эшли башлаган. Аңа кадәр тикшерү-оператив төркемендә машина йөрткән.

Авылга тәртип сакчысы итеп теләсә кемне куймыйлар, моның өчен махсус югары белем кирәк. Илшат читтән торып Казанның социаль-юридик институтын тәмамлаган. Апас районының Шыгай авылында туып-үскән.

– Ник туган авылыгызда участковый булып урнашмадыгыз? – дип күңел кылларын тарткаларга булдым.

– Үз җирлегеңдә эшләү кыенрак, барысын да беләсең бит. Ә таныш булмаган кешеләр белән эш җиңелрәк бара. Монда урнашкач, тугыз авылны да йөреп чыгып, барысы белән таныштым, визиткамны калдырдым. Көндез дә, төнлә дә шалтыраталар. Төнлә уятсалар: «Мин йоклыйм, бераздан шалтыратыгыз», – дип әйтә алмыйм. Киенәм дә чыгып китәм. Әллә нинди куркыныч хәлләр килеп чыгарга мөмкин бит, – диде әңгәмәдәшебез.

Аның сүзләреннән аңлашылганча, күрше-тирә авылларда яшәүче гаиләләрдә тавыш чыкмый калмый. Ир белән хатын мөнәсәбәтен җайларга да участковыйны чакырталар. Илшатка еш кына психолог булырга да туры килә.

– Кайвакыт ике күрше җир бүлешә алмый. Тәҗрибә күрсәткәнчә, гаепле кеше беренче булып шалтырата, – дип елмайды участковый. – Ызгышкан кешеләрне килештерергә тырышам, сүземә колак салалар.

– Ә үзегезнең абруегыз зурмы авылдашлар арасында? – дидем.

– Ул сайлауларда күренә торгандыр. Безнең җирлектә халык сәяси чараларда актив катнаша, 100 процент күрсәткечнең дә булганы бар. Үзара салым буенча референдумга халык әйбәт караштa. Шактый эшләр эшләнде. Былтыр да, быел да кеше башыннан 500 сум җыелды. Зуррак сумма булган саен, зуррак эшләр башкарырга була. Борнашта баш бәласе булырлык проблемалар юк, юллар әйбәт, су килә. Узган ел чишмәне төзекләндердек..

ЭТ БЕЛӘН ТӘЛИНКӘ

Йорт ишегалдында бертуктаусыз зур эт эреп тора. Ул хуҗалыкны гына саклый, Илшат аны үзе белән алып чыкмый. Өйнең бакчага карап торган ягына зур спутник тәлинкәсе эленгән.

– Әллә телевизор карарга да вакыт каламы? – дим, гаҗәпләнеп.

– Бу тәлинкә эш өчен кирәк, без бит электрон документ әйләнеше белән эш итәбез. Шуңа да интернет сигналы әйбәт булырга тиеш, – дип, тел төбемне абайлап алды әңгәмәдәш.

Илшатның хатыны эштә иде, шуңа күрә йортның торак өлешен гаилә башлыгы үзе күрсәтеп чыкты. Шыгайдан әти-әнисе дә килеп караган, Коръән ашы уздырганнар.

Нинди генә кешеләр белән эш итәргә туры килми участковыйларга. Күрше Әҗем авылында Илшатка көненә 25–30 тапкыр шалтыратучы бер пенсионер яши. Аның өенә, янәсе, гел кемдер керә, кибеткә чыккан арада, киемнәрен алып чыгалар да яңадан кертеп бирәләр, имеш.

– Аның янына барып килмичә, шалтыратудан туктамый, – дип Әҗем кешесенең сәерлеге турында сөйләде Илшат Мөһәмов. – Бер-ике көнгә туктый да яңадан шалтырата. Берүзе тора, кайвакыт туганнары кайта. Район үзәгенә барганда авыл юл өстендә кала, киткәндә-кайтканда аның янына керми китмим.

Әлмәндәр авыл җирлеге башлыгы Рамил Җәләлиев яшь участковыйны уңай яктан гына телгә алды.

– Кайчан шалтыратсаң да, килеп җитә. Авылда полиция хезмәткәрләренең абруе зур, – диде ул.



Илдар Халиков,
ТР Премьер-министры:

– Авыл җирлегендәге участковый – хокук саклау органы гына түгел, тулы бер хакимиятнең: Президентның, Хөкүмәтнең һәм барлык федераль структураларның вәкиле. Халык аңа шундый мөнәсәбәттә. Участок полиция хезмәткәре тәртип урнаштыра һәм үз вәкаләтләренә кермәгән башка күптөрле эшләрне дә башкара. Һәрвакыт шулай булган.

Артем Хохорин,
ТР эчке эшләр министры:

– Полиция участковые халык белән тыгыз бәйләнештә тора. Аның бурычы – кешеләрне саклау. Хакимият вәкиле буларак, участковыйның үз хезмәтен нинди шартларда башкаруы һәм яшәве бик тә мөһим. Мондый йортлар кирәкле элемтә, җиһазлар, транспорт белән тәэмин ителгән. Участковыйга да, авыл халкына да уңайлы. Хәзер алар полицияне кайдан эзләп табарга кирәклеген белә.

Рәдиф Садыйков,
Апас районы буенча полициянең вәкаләтле участковыйлары бүлеге башлыгы:

– Апас районында участковый йортлары икәү. Алар 2013 елның декабрендә төзелгән. Программаның максаты буенча, административ-торак комплекслар район үзәгеннән ераграк булган авылларда салына. Һәр участковыйның эш машинасы бар (күпчелек очракта – «Нива»), ел башында сим-карталар тараттык.

PRESSA.RU

2016:

СУ САКЛАУ ЗОНАЛАРЫ, КИНО ҺӘМ ОНКОЛОГИЯ ПРОФИЛАКТИКАСЫ

2016 ел татарстанлыларның хәтерендә су саклау зоналары, кино һәм онкологик авыруларга каршы көрәш елы булып калды. Өч юнәлештә тырышып эшләү үз нәтиҗәләрен дә бирде, бүген «Татарстан» шулар турында бәян итәчәк.



СУ САКЛАУ ЗОНАЛАРЫ ЕЛЫ САННАРДА:

Узып баручы ел Татарстанда Су саклау зоналары елы дип игълан ителгән иде. Киң колачлы эш программасы үз эченә берьюлы берничә мөһим юнәлешне сыйдырды: яр буйларын һәм пляжларны төзү, елга ярларын ныгыту һәм чистарту, яклауга мохтаҗ дип табылган табигый зоналарны игътибарда тоту. Профильле ведомстволар үз эшләре турында киләсе елда гына хисап бирәсе булсалар да, инде хәзердән үк якынча нәтиҗәләр чыгарырга мөмкин.

ЯР БУЙЛАРЫ ҺӘМ ПЛЯЖЛАР – БӨТЕН КЕШЕ ӨЧЕН ДӘ

21 объект
Татарстанның 20 муниципаль берәмлегендәге әнә шулкадәр объект төзекләндерү программасына кертелде. Аларның күбесе инде кулланышка тапшырылган, кайберләрендә эшләр әле дәвам иттерелә. Киләчәктә тормышка ашырылачаклары арасында Кабан күлен тәртипкә китерү дә каралган. Күл территориясендәге проект эшләре быелгы кышта башланачак. Инде кулланышка тапшырылган проектлар арасында – нефть башкаласындагы шәһәр пляжы, Лениногорскидагы яр буе һәм башка эшләр.

КҮБРӘК АЧЫКЛАНА БАШЛАДЫ...

536 – 2015 елның 10 ае дәвамында

1599 – 2016 елның 10 ае дәвамында

Су объектларын саклау өлкәсендәге закон бозуларның саны

9,3 млн сум – су объектларын саклау өлкәсендә закон бозу очраклары өчен салынган штрафларның гомуми суммасы.

ЕЛГАЛАРНЫ КОТКАРЫП...

276 объект,
ел башыннан алып, төбәк әһәмиятендәге су объектларына керүне чикләгәнгә күрә, сүттерелде. Аерым алганда, төрле урыннарда Иделгә, Казансуга һәм Ноксага, Богородское һәм Кабан күлләренә юлны япкан коймалар алынды.

387 чикләү очрагы
2016 елның 10 ае дәвамында Татарстан елга һәм күлләренә килүне чикләгән очракларның шулкадәр саны теркәлде.

3 млн сум – республиканың елга һәм күлләренә керүне чикләгән өчен юридик һәм физик шәхесләргә салынган штрафларның гомуми суммасы шундый.

ТЕМАНЫ ДӘВАМ ИТЕП

Ел чараларын Татарстанның су объектларындагы экологик вазгыятьне яхшырту юнәлешендә эшләнгән әле беренче генә адымнар дип исәпләргә мөмкин. Бу фикерне ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов белдерде. Шуңа күрә 2017 ел Татарстанда Экология һәм җәмгыять урыннары елы дип игълан ителде дә, бу Парклар һәм скверлар елының (2015) һәм Су саклау елының (2016) мантыйкый дәвамы булып тора. Шунысын да билгеләп үтик, 2017 ел Россиядә Махсус саклана торган табигать территорияләре елы булачак.

Чыганаклар: ТР Экология министрлыгы һәм ТР Төзелеш министрлыгы белешмаләре

ОНКОЛОГИК АВЫРУЛАРГА КАРШЫ КӨРӘШ ЕЛЫ САННАРДА:

ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы инициативасы белән 2016 ел республикада Онкологик авыруларга каршы көрәш һәм аларга профилактика елы дип игълан ителгән иде. Россиянең башка төбәкләре белән чагыштырганда, Татарстанда онкологик ярдәм күрсәтү структурасы нәтиҗәлерәк булуын исәпкә алганда хәлдә дә, министрлык онкологик авырулар белән авырып китүчеләрнең һәм шулардан үлүчеләрнең саны елдан-ел артуын таный.

«Татарстан» журналына Сәламәтлек саклау министрлыгының матбугат хезмәте хәбәр итүенә караганда, онкологик авыруларга каршы көрәш елына нәтиҗәләр 2017 елның февралендә ясалачак. Шуңа күрә без укучыга бүгенге көндә актуаль булган статистика белән танышырга тәкъдим итәбез.

Ел саен онкологик авыруларның **16 меңнән** артык яңа очрагы ачыклана

Татарстанның **91 меңнән** артык кешесе онкологик исәптә тора

АВЫРЫП КИТҮНЕҢ ИҢ ЮГАРЫ НОКТАСЫ НИЧӘ ЯШЬКӘ ТУРЫ КИЛӘ?



Яман шеш барлыкка **килүләрнең ешлыгы** арту инде 40 яшьтән соң ук күзәтелә

РЕСПУБЛИКАДА ОНКОЛОГИК АВЫРУЛАР СТРУКТУРАСЫ



Узган ел Татарстанда рактан үлү **8%**ка **диярлек артты.**

Белгечләр авырып китүнең үсеш темплары гомер озынлыгының артуы һәм медицинаның диагностик мөмкинлекләре киңәюе белән бәйле дип аңлаталар. Онкология белән авырып китүнең иң түбән проценты диагностика дәрәҗәсе түбән булган Африка илләрендә исәпләнә.

ДИСПАНСЕРИЗАЦИЯ РАКНЫ ИРТӘРӘК АЧЫКЛАРГА ЯРДӘМ ИТӘ!

Диспансеризация үтүчеләрдә ракның башлангыч формаларын **ачыклау проценты югарырак – 75,7%:**

44% ракны соңгы баскычта ачыклау

56% **ракның беренче һәм икенче** баскычтагы башлангыч формаларын ачыклау

58% **башлангыч стадияләрдә** (1нче һәм 2нче баскыч) онкологиядән терелү проценты

иртә ачыклаганда, рактан **үлүнең 30%** ка якынын булдырмый калырга мөмкин

Чыганаклар: ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы, Республика клиник онкология диспансеры белешмәләре

КИНО ЕЛЫ САННАРДА:

2016 ел рәсми рәвештә «Россия киносы елы» дип игълан ителгән иде. Максаты – илебез кинематографына, аның проблемаларына һәм казанышларына игътибарны җәлеп итү. Инде бүген үк, якынча нәтиҗәләр ясаганда, Татарстанда Кино елы, «сәнгатьнең иң мөһимнәреннән берсенә» яңа үсеш импульсы биреп, уңышлы үтте дияргә була.

TATLLYWOOD – АВАНГАРДТА:

2 урынны Татарстан
Россия төбәкләрендәге кинематография торышы рейтингында яулады. 1 урынга – Санкт-Петербург, 3 урынга Свердловск өлкәсе чыкты. Шулай итеп, без кино җитештерүдә тарихи традицияләре булган шәһәрләр белән беренче позицияләрне бүлештек. Бу саннар Уфада, РФ Мәдәният министрлыгының мәдәният буенча Координация советында игълан ителде.

САННЫ – СЫЙФАТКА:

3 **рус** телендә

5 **татар** телендә



Номер әзерләнгән вакытта Татарстан кинематографистлары берьюлы сигез тулы метражлы тасма өстендә эшли иде. Өч фильмны – рус телендә, бишесен татар телендә төшерәләр.

500 меңнән 4 млн сумга кадәр

2016 елда Татарстанда төшерелгән тулы метражлы уен фильмнарының бюджеты шул сумманы тәшкил итте. Алар арасында: маҗаралар, мюзикл, комедия, мелодрама һәм хәтта ужастиклар да бар.

ДӘҮЛӘТ ЯРДӘМЕ:

1 **анимация**

4 **документаль**

4 **уен**



9 фильм
Татарстанда 2016 ел ахырында дәүләт ярдәме белән булдырылачак.

7 дән 9 млн сумга кадәр

акчаны республика ел саен фильмнар төшерү өчен бүлеп бирә.
Чагыштыру өчен: Россиянең 49 төбәгендә дәүләт ярдәме бөтенләй күрсәтелми.

ДЕБЮТ ПРОКАТЫ:

1 үзебездә җитештерелгән тулы метражлы уен фильмы киң кинопрокатка чыкты. Бу «беренче карлыгач» Алексей Барыкин төшергән «Гаилә мәшәкатьләре» комедиясе иде. Татарстан уен киносы тарихында әлеге хәл тәүге мәртәбә булды.

1,2 млн сум тасманың бюджеты шул сумманы тәшкил итте.

КАДРЛАР БАРЫСЫН ДА ХӘЛ ИТӘ:

149
белгечне 2016 елда Казан дәүләт мәдәният институтының Кино һәм телевидение институты әзерләп чыгарды

50
Татарстан кинематографистлар союзында шуның кадәр әгъза бар. Быел аның яшьләр секторы булдырылды

35
киностудия Татарстанда бүгенге көндә шәхси эшкуарлык һәм КБО нигезендә эшли

ДӘҮЛӘТ ПРОКАТЫ СИСТЕМАСЫ:

10 муниципаль кинотеатр федераль өстәмә түләү ярдәмендә заманча кино җиһазлары белән тәэмин ителә. Аларның 4 се – Буада, Тәтештә, Әгерҗедә һәм Менделеевскида – үз эшләрен башлады инде.

Дәүләт прокаты системасы:
1 дәүләт һәм 9 муниципаль кинотеатр, 34 кино залы, 27 кино күчерелмәсе

100 дән артык фильмны ел саен, Яр Чаллыдагы һәм Бөгелмәдәге ике филиалын да кертеп, «Татаркино» учреждениесе сатып ала.

ХАЛЫКАРА МӨСЕЛМАН КИНОСЫ ФЕСТИВАЛЕ САННАРДА:

XII Халыкара мөселман киносы фестивале, 2016 ел: катнашу өчен 50дән артык илдән 700дән артык гариза кабул ителде.
I Халыкара мөселман киносы фестивале, 2005 ел: дөньяның 12 иленнән 40 кино эше тәкъдим ителгән иде.

Чыганаклар: ТР Мәдәният министрлыгы, Казан мәдәният институты, КМФМКның Оештыру комитеты белешмәләре

PRESSA.RU

2017: ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ УРЫННАРЫ ЕЛЫ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов указы буенча 2017 ел республикада Экология һәм җәмәгать урыннары елы дип игълан ителде.

«Без шәһәр һәм авылларыбызны яшелләндерүне, сулыкларны төзекләндерүне дәвам итәчәкбез... – дип билгеләп үтте Татарстан Президенты Дәүләт Советына үзенең еллык Юлламасында. – Уртак тырышлык белән 2015–2016 елларда бөтен Татарстан буенча 183 парк белән сквер төзедек һәм тәртипкә китердек. Моннан тыш, республиканың 20 районында су буенда ял итү өчен яңа урыннар барлыкка киләчәк...»



ӘЛМӘТТӘГЕ ПЛЯЖ

ЭШЛӘНГӘН:
Ап-ак комлы пляж, балалар өчен уен урыннары, пляж волейболы өчен мәйданчык, баулы парк, көймә һәм катамараннарны прокатка биреп тору пункты, кафе, ачык һавадагы бассейн, сауна, скалодром, суда йөрү юллары һәм Европа дәрәҗәсендәге вейкпарк.

ЭШЛӘНӘЧӘК:
Күлнең каршы як ярын, амфитеатрны төзекләндерү, янәшәдәге территорияне туристик-ял итү зонасы буларак үстерү.

КАЗАНДАГЫ «ЧЕРЕК КҮЛ» ПАРКЫ

ЭШЛӘНГӘН:
Гашыйклар аркасы реставрацияләнгән, барлык керү юллары һәм баскычлар реконструкцияләнгән, пандус төзекләндерелгән, парк үзәгендәге ачык мәйданда ак төстәге агач мөнбәр барлыкка килгән, чәчәклек белән агач чатыр урнаштырылган, өстәмә сукмаклар салынган, балалар өчен күпер, скалодром һәм таганнар белән мәйданчык, шулай ук воркаут зонасы төзелгән.

ЭШЛӘНӘЧӘК:
Паркның көнбатыш өлешен төзекләндерү: күлнең үзен реставрацияләү һәм суга төшү юлларын тәртипкә китерү, киләчәктә ресторан, кафе һәм балалар клубы урын алачак агач биналарны реконструкцияләү, биналар арасындагы агач мәйданчыкта җәйге янкорма төзү планлаштырыла.

PRESSA.RU

КУКМАРАДАГЫ
НУРМА ЕЛГАСЫ ЯР БУЕ

ЭШЛӘНГӘН:
Җиңү паркы янында Нурма елгасы буйлап түбән яр буе төзелгән. Елганың тау бите үсенте һәм чүп-чардан чистартылган, ә ярлары габион ярдәмендә ныгытылган. Төшү өчен өч юл, пандус, амфитеатр һәм терраса төзелгән, җәяүлеләр күпере төзекләндерелгән. Парк белән янәшә урнашкан мәйданда сәхнә һәм мөнбәр, йозаклар өчен «Мәхәббәт агачы» һәм йолдызлык билгеләрен гәүдәләндерә торган агачтан ясалган 12 сын куелган.

ЭШЛӘНӘЧӘК:
Югары, Урта һәм Түбән Нурманы җәяүлеләр өчен төзелгән күперләр каскады ярдәмендә тоташтыру, суга төшәр өчен баскычлар түшәү планлаштырыла. Агачтан ясалган яр буе стадион һәм тау чаңгысы комплексын тоташтырачак.

ТҮБӘН КАМАДАГЫ
«ГАИЛӘ» ШӘҺӘР ПАРКЫ

ЭШЛӘНГӘН:
Карагачтан йөрү юллары челтәре булдырылган. Каенлыкта яктырту җайланмалары куелган, наратлыкта тиеннәр өчен зур вольер төзелгән. Велосипедчылар өчен озынлыгы 3,5 км га сузылган юллар төзелгән, спорт мәйданчыклары төзекләндерелгән, балалар өчен мәйданы 2800 кв. метрга җиткән спрей-парк һәм коры фонтанлы Татарстандагы иң зур уен комплексы, «Сыерчык оясы» дип аталган күпфункцияле павильон, гигант фонтанлы мәйдан, амфитеатр һәм сәхнәле калкулык төзелгән.

ЭШЛӘНӘЧӘК:
Йога белән шөгыльләнү өчен мәйданчык һәм башка мәйданчыкларны төзекләндерү.

ТЕЛӘЧЕДӘГЕ
ТЮЛЯЧКА ЕЛГАСЫНЫҢ ЯР БУЕ ТЕРРИТОРИЯСЕ

ЭШЛӘНГӘН:
Елга тугае чүп-чардан һәм ләмле утырмалардан чистартылган, су дәрәҗәсен күтәрү һәм аны һава белән тукландыру өчен ташлардан буалар буылган, ярлар таш һәм су-сазлык үсемлекләре белән ныгытылган. Парк аша елга тугаена ташуның күтәрелү дәрәҗәсеннән өстәрәк булган яңа җәяүлеләр юлы салынды, халыкның мобиль булмаган өлеше өчен уңайлы мохит каралган. Ике яңа күпер, спорт, балалар һәм парад мәйданчыклары төзелгән. Яңа коймалар корылган.
Паркка керү җирле һөнәрне символлаштыра торган мичкә рәвешендә эшләнгән, кечкенә архитектура формалары, шул исәптән, кондызларның скульптура группасы да куелган.

ЭШЛӘНӘЧӘК:
Амфитеатр төзергә, иҗади белем бирә торган укыту зонасы булдырырга һәм анда парк тематикасы буенча арт-объектлар урнаштырырга планлаштырыла.



КАЗАНДАГЫ
УРИЦКИЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ПАРК

ЭШЛӘНГӘН:
Сулыкның төбе торгызылган, су төбе аэраторлары куелган, җәяүлеләр өчен күперләр реставрацияләнгән, алар астында «су коюю» системасы оештырылган. «Мәскәү» мәдәният һәм спорт үзәге янындагы пирс ныгытылган, яңа койма корылган, агачтан ясалган суга төшү юллары төзекләндерелгән, күлдә үрдәкләр өчен агач өй барлыкка килгән. Туй йозаклары өчен «Мәхәббәт дивары» ясалган. Чыгыш ясау өчен ябык сәхнә һәм амфитеатр, балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары, шулай ук этләр йөртү өчен мәйданчыклар төзелгән. Җылылык челтәрләре торбалары өстеннән җәяүлеләр өчен үтеп йөрү юллары салынган.

ЭШЛӘНӘЧӘК:
«Мәскәү» мәдәният һәм спорт үзәге бинасына капиталь ремонт, паркның ерактагы өлешен төзекләндерү һәм коры фонтан урнаштыру.



PRESSA.RU



ЙОЛДЫЗЛАР ЧИТКӘ АТЫЛА

Эт өрә, кәрван бара, дигәндәй, ил җитәкчелеге, алтынга тиң сәләтле белгечләрне үзебездә калдырырга кирәк, дип күпме генә борчылып сөйләсә дә, вундеркиндларыбыз чит илләргә һаман да кәрван-кәрван булып китүне карый. Татарстанда акыллыбашларның миграциясенә киртә кую өчен, 2015–2020 елларга исәпләнгән Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү дәүләт программасы эшләп килә, аңа ел саен 100 миллион сум бүленә.

Автор:
Линар Закиров

АЗНАКАЙ ЯШЬЛӘРЕ НИК КАЙТА?

Сәләтле белгечләрнең чит-ят кыйтгаларга китүе турында күптән түгел республиканың Хөкүмәт йортында узган Икътисадый совет утырышында борчылып сөйләштеләр. Президент Рөстәм Миңнехановның киләчәк буынның башка төбәкләрдә-илләрдә белем алганына бер дәгъвасы да юк, әмма алар соңыннан кайтмыйм, беркем дә бу мәсьәләне күз уңында тотмый, диде.

– Җирле предприятиеләрнең республикадан читтә укучы студентларның исемлеге булырга, без аларны эшкә үзебез чакырырга тиеш. МДУ, Губкин исемендәге Россия дәүләт нефть һәм газ университеты, МГИМО кебек атаклы югары уку йортларында белем алучы студентлар үзләре дә: «Без кече ватаныбызда берәрсенә кирәкме соң?» – дип сорый. «Әлбәттә, барыгыз да кирәк», – дибез. Иннополис, «Алабуга» махсус икътисадый зонасы, «Татнефть», энергетика бар, – диде Президент.

Район башлыкларына да эләкте. Алар үз җирлекләренә фәлән-фәлән белгечләр кирәк, дип «целевиклар» исемлеген әзерләп, яшьләрен вузларда белем алырга җибәрә дә, шуның белән вәссәлам. Кемнең кайда укыганын оныталар. Хәтерләре кыска.

– Башлыклар студентларны җыярга, кемнең кайда укыганын белергә тиеш. Бу бигрәк тә авыл хуҗалыгы районнарына кагыла, – дип мөрәҗәгать итте Рөстәм Миңнеханов катнашучыларга.

Азнакай җитәкчелеге, башкалардан аермалы буларак, үз яшьләренең кайда һәм хәтта ничек укыганнарыннан хәбәрдар. Районда ун еллап 50/50 программасы эшли. Бу, нигездә, медицина белән мәгариф өлкәсенә кагыла. Шушы юнәлештә белем алучыларның ел саен уку өчен түләүнең ярты өлешен җирле бюджет күтәрә. Моның өчен студент һәр уку елы ахырында районга сессияләрне уңышлы тапшыруы турында белешмә белән кайтырга тиеш. Компенсация фәкать шул очракта түләнә. Тик мондый ярдәм һәркемгә дә тәтеми. Кемне программа нигезендә җибәрәсен районның мәгариф идарәсе җитәкчесе белән баш табибы җитәкчелегендәге махсус комиссия хәл итә.

Фото: Александр Эшкинин архивыннан, president.tatarstan.ru

Татарстанның 96 махсус урта белем бирү йортында 67 мең кеше укый. 61 вуз һәм аларның филиалларында 163 мең студент белем ала. ТР мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов әйтүенчә, техник белгечлекләр буенча урыннар арткан, гуманитар юнәлештә, киресенчә, кыскартыла. Рөстәм Миңнеханов сөйләвенчә, бүген 35 мең вакансиянең яртысы төзелеш һәм эшкәртү җитештерүенә туры килә. Шунлыктан гуманитарийларның яртысы диярлек үз белгечлеге буенча эш таба алмый.

Азнакай районы Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Дамир Гыйләҗев сөйләвенчә, читтәге яшьләрнең укуын контрольдә тотучы махсус комиссия төзелгән. Ун ел эчендә 50/50 программасы ярдәмендә район 30 яшь белгечкә «баеган».

– Укуларын тәмамлап бетерә алмаучылар да бар. Әйтик, шундыйлардан берсе: «Белем алу шулкадәр катлаулы булыр дип уйламаган идем», – дип аңлатып, башка төрле юнәлеш сайлавын әйтте. Әгәр студент программа шартларын үтәми, ягъни укуын тәмамлап, бездә, ким дигәндә, өч ел эшләми икән, ул район биргән акчаны кире кайтарырга тиеш була, – дип аңлатты «Татарстан»га Дамир Гыйләҗев.

ТЕОРИЯ БЕЛӘН ПРАКТИКА АРАСЫНДА – УПКЫН

Президент эшче һөнәрләргә өйрәтә торган ресурс үзәкләре җитәкчеләрен дә утлы табада биетте. Уку йортлары – бер әйбергә төшендерсә, эш бирүчеләр яшь белгечләрдән бөтенләй башканы таләп итә икән. Теория белән практика арасында зур упкын бар, дигән сүз. Моның сәбәпләрен Татарстанның мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов әйтте. Беренчедән, укытучыларның белем бирү сыйфаты канәгатьләндерерлек түгел. Икенчедән, уку стандартлары белән эш стандартлары туры килми. Өченчедән, чыгарылыш студентларын бәяләү системасын камилләштерү таләп ителә.

Казан моторлар җитештерү берләшмәсе генераль директоры Дамир Кәримуллин сөйләвенчә, белем бирү йортларында практика белән шөгыльләнүче мөгаллимнәр юк. Шуның аркасында предприятиегә Дементьев исемендәге Казан авиация-техника көллиятен тәмамлап чыккан белгечләрнең 62 процентын яңадан укытырга туры килә. Рөстәм Миңнеханов бу сүзләргә битараф кала алмады, әлбәттә.

– Ни өчен без ресурс үзәкләрен, кирәкле белгечләр әзерләү өчен, предприятиеләр карамагына тапшырмыйбыз? Ресурс үзәкләре бер генә юлдан барырга тиеш, дип уйлыйсызмы? Сезгә кешеләр конкрет бурыч белән килә икән, аларга кирәгенчә эшләгез! Ә сез үзегез белгәнне генә өйрәтәсез. Кемгә кирәк андый белгечләр. Вузлар белән дә шул ук хәл. Бюджет акчаларын студентлар киләчәктә икътисадны тәэмин итә алыр өчен бүлеп бирәбез. Тик бюджет хисабына төзелгән ресурс үзәкләрен тәмамлап чыккан белгечләрне киредән өйрәтергә туры килә, – дип канәгатьсезлеген белдерде республика башлыгы.

Акыллыбашларны хәлдән килгәнчә үзебездә калдыру максаты белән, 2014 елда ТР Министрлар Кабинеты талантлар белән идарә итүне күздә тоткан һәм Россиядә тиңдәше булмаган дәүләт программасын кабул итте. Ул балаларга, яшьләргә республикада интеллектуаль һәм иҗади үсеш мөмкинлекләрен популярлаштыруны, үзләре һәм аларның әти-әниләре белән нәтиҗәле коммуникация булдыруны күздә тота. 2020 елга Татарстанның шактый предприятиеоешмасы бу агымга кушылырга тиеш булачак. Биш еллык программаны тормышка ашыруга 600 миллион сум бирелә. Әлеге программа кысаларында төрле чаралар үткәрелә.

Бу елның октябрендә Казан шәһәренең 2030 елга кадәр исәпләнгән үсеш стратегиясе кабул ителде. Аны әзерләүдә бер меңгә якын белгеч катнашкан.

Мэр Илсур Метшин әйткәнчә, Казан бүген Россиянең креатив шәһәрләр исемлегенең башында тора. Башкалабыз туристик яктан да күпләргә кызыклы. Биредә тормыш дәрәҗәсе югары, халык, бигрәк тә студентлар актив, сәнәгать предприятиеләре шактый. Ләкин булганына шөкер итеп кенә калмыйча, яңа үрләргә дә талпынырга кирәк.

Үсеш стратегиясен әзерләгән белгечләр Казанның тискәре якларын да аерып чыгарган: беренче чиратта, белем бирү белән хезмәт хакларының чагыштырмача түбән булуы. Шуның аркасында акыллыбашлар, бәхет һәм акча эзләп, читкә талпына да инде. Татарстан башкаласының үсешен тоткарлый торган факторлардан тагын менә ниләр бар: инженер инфраструктураның тузганлыгы, Казанның халыкара транспорт челтәренә җәлеп ителмәве, бизнесның дәүләт ярдәменә бәйле булуы, югары административ киртәләр һәм җәмгыять белән хакимиятнең уртак тел табып бетерә алмавы. 2030 елга бу җитешсезлекләр юк ителергә тиеш.

PRESSA.RU



ТОТРЫКЛЫЛЫК КИРӘК

Вундеркиндларыбыз ник читкә китә? Аларны үзебездә ничек калдырып була? Бу сорауларга Татарстан Дәүләт Советы депутатлары да җавап табарга тырышты. Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты рәисе урынбасары Марат Галиев әйтүенчә, «тимер чаршау» җимерелгәч, акыллыбашлар шунда ук читкә агыла башлаган. Совет чорында мондый зур күченешнең берничә этабы булган. Хәзер миграциянең тагын бер дулкыны күзәтелә. Депутат моның сәбәбе читкә китүчеләрнең үз илендә перспективалар күрмәвендә, дип исәпли.

– Моның белән нишләргәме? Әкренләп кенә хокукый дәүләткә әйләнергә. Үзгәртеп кору чорыннан соң 25 ел буе ил сәясәте аңлаешсызрак алып барылды. Киләчәктә нәрсә булачагын да фаразлап булмады. Россиядә берничә, хәтта ун елдан соң да нинди юлдан барачагын чамалаган һәм куелган бурычлар төгәл үтәлгән очракта гына, кешеләр монда калачак. Бүтән төрле могҗизалы рецептлар юк. Россиянең һәр субъекты нәрсәдер эшләргә тырыша, әмма аларның да мөмкинлекләре чикле, – диде Марат Галиев.

ҮГЕТ-НӘСЫЙХӘТ ҺӘМ АКЧА КИРӘК

ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев фикеренчә, Казандагы югары уку йортлары яхшы белгечләр әзерләп чыгара. Шулай булмаса, аларны чит илләрдә ике куллап кабул итмәсләр иде.

– Әзерлекле белгечләребезне үзебездә калдырырга телибез икән, хезмәт хакларын күтәрергә тиешбез. Кайда күбрәк түлиләр, алар шунда бара. Социаль мәсьәләләрне хәл итмичә генә, бу проблема да урыныннан кузгалмаячак. Әйтик, Төркия табибларының уртача хезмәт хакы, безнең акчага күчереп исәпләгәндә, 220 мең сум. Ә республикабызда алар күп дигәндә 40–45 мең сум ала. Югыйсә, Төркияне Россиядән бик үк алга киткән ил дип атамас идем, – диде депутат.

Шушы ук комитет әгъзасы, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров яшьләрнең чит илләргә китүенә бер дә каршы түгел. Дөньяга чыкмасалар, укымасалар, үсеш булмас иде. Татарстан бит бөтен дөньяга ачык. Әмма бердәнбер шарт – китүчеләр кире кайтсын, ди ул.

– Ата-аналарның үз баласына нинди тәрбия, үгет-нәсыйхәт бирүеннән дә күп нәрсә тора. Чит илдә белем алып, үз төбәгенә хезмәт итәргә атлыгып торган баланы ничек җибәрмисең инде. Әгәр, чит илдән башка яхшырак тормыш юк, дип аңы формалашкан бала, чит мәмләкәткә китеп, шунда хезмәт итәргә әзер булса, бу инде тискәре күренеш. Әлеге мәсьәлә күпкырлы, монда бер катлы гына чишелеш юк. Республиканың шушы өлкәдәге сәясәтендә ата-аналар да,

Республикада вундеркиндлар саны артканнан-арта. Моны саннар теле белән дә дәлилләп була. 2009 елдан бүгенге көнгәчә бөтенроссия олимпиадаларда җиңү яулаган укучылар саны 2,5 тапкырга күбәйгән (58 кешедән 141 гә кадәр). Мәскәү белән Санкт-Петербургтан соң Татарстан өченче булып бара. 2015–2016 уку елында республиканың җыелма командасы россиякүләм олимпиадада 141 призлы урынга ия булды. Узган сезонга караганда, бу 32 урынга күбрәк. Олимпиада йолдызларының 70 проценты Мәскәү, Санкт-Петербург якларына, чит илләргә «атыла» да... кире кайтырга ашкынып тормый.

укытучылар да бер карашта булырга тиеш, – дип, үз позициясен белдерде Ринат Закиров.

Бөтендөнья татар конгрессына килсәк, алар чит илләрдәге татар яшьләренә республикабызга килеп, белем алырга мөмкинлек бирә. Әмма туган җиреннән зур өметләр белән җибәрелгән яшьләрнең кайберләре, укып бетергәч, кайтырга ашкынмый. Соңгы вакытта Казанга Кытайдан, Урта Азия илләреннән: Казахстаннан, Үзбәкстаннан, Азәрбайҗаннан яшьләр күп килә.

– Безгә бит аларның татар илендә формалашып, туган якларына кайтып, татар халкын татар итеп яшәтүләре кирәк. Килгән 100 кешенең барысы да кайтып китәргә тиеш, дигән сүз түгел. Абсолют саннар белән фикерләү дөрес булмас иде. Тормыш бит бу: кемдер гаилә кора, кемдер биредә башка төрле сәбәп белән кала. Әгәр килүчеләрнең яртысы гына да туган ягына кайтып, милләтебезгә хезмәт итәргә алынса, моны казанышыбыз итеп кабул итәргә була, – диде депутат.

ПАТРИОТИК ХИСЛӘР КИРӘК

ТР Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе урынбасары Татьяна Воропаева, үзен Татарстанның патриоты дип атап, мәсьәләнең шушы ягына игътибар итте. Аны заманында республикадан читкә эшкә күп чакырсалар да, һәр кеше үз җирлегендә кадерле, дип, туган ягында каласы иткән.

– Бүген яшьләрнең сайлау хокукы барлыкка килде, элеккеге чакларга караганда, аларның мөмкинлекләре дә күбрәк. Россиядән китүчеләр дә кайвакыт ялгыш адым ясый. Туган якка кайта алмыйча, бүген чит илдә кыен хәлдә калган бер кызны беләм. Шуңа күрә ашыгырга кирәкми. Төрле өлкәләрдә үзеңне күрсәтү өчен үзебездә дә мөмкинлекләр җитәрлек. Россиядә тугансың һәм Хөкүмәт синең үсешкә акча тоткан икән, син дә, милләтпәрвәр буларак, илне башкалар белән бергә үстерергә тиеш, – диде әңгәмәдәшебез.

Татьяна Воропаева 2008–2014 елларда Зәй районын җитәкләгән иде. Яшьләрне район үзәкләрендә калдыру бик авыр, ди ул. Бүген Зәйдә сәнәгать тә үсеш кичерми, эшсезлек күрсәткече дә югары. Район балалары, мәктәпне тәмамлаганнан соң, йә көллияттә, йә техникумда гына белем ала алган. Әмма соңгысын күптән түгел япканнар да куйганнар.

– Югары белем алуны беренче планга куюлары белән килешеп бетмим. Яшьләр зур шәһәрләргә китә дә кайтмый. Зәйгә кайтучыларның күбесе – энергетик белем алып, җирле ГРЭСка эшкә урнашучылар. Хәзер ул да торгынлык кичерә, анда реконструкция кителә. Яшьләрне якын-тирәдәге Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама үзенә «йота». Ул шәһәрләрдә хезмәт хаклары да югарырак. Мәскәүдә, эшкә барып җитәр өчен, ике сәгать бөкедә утырып чыгасың, ә Зәйдән күрше шәһәргә бермә-бер тизрәк барып җитәсең, – диде Татьяна Воропаева.

«КЫЗЫЛ КЕЛӘМ» ҖӘЯРГӘМЕ?

Республикада яшь белгечләргә чит илдә белем алырга мөмкинлек бирә торган «Алгарыш» программасы эшли. Тик кайбер хәйләкәрләр, Хөкүмәт акчасына укып, кире кайтмый, читтә төпләнеп калуны кулайрак күрә.

Ә менә өч ел дәвамында «Алгарыш» буенча Бөекбританиянең Ньюкасл университетында, соңыннан дүрт ел үз хисабына Кембридж университетында укыган Эмиль Булатов 2015 елда ватанына кайта. Бүген ул Казан федераль университетында химик биология төркемен җитәкли.

– «Алгарыш» турында туганнан-туган апамнан белдем. Ул шушы грант буенча Америкада укып кайткан иде. 2008 елда, «Алгарыш»ның башланып кына киткән чагы, сайлап алу әллә ни катлаулы, кеше дә күп түгел иде. Ул елны Ньюкасл университетына минем белән бергә ун кешене җибәрделәр. Бу илне сайлауда «Алгарыш» программасы хезмәткәләре ярдәм итте, ул вакытта мин чит илдәге мәгариф белән таныш та түгел идем. Ньюкасл университетында, чыннан да, югары дәрәҗәдә белем бирәләр, – диде Эмиль.

Әңгәмәдәшем сөйләвенчә, ул яңа җирлеккә, андагы кешеләргә, гореф-гадәтләргә тиз ияләнгән. Ике атна дигәндә үзен өйдәге сыман хис итә башлаган.

Бөекбританиянең мәгариф системасы мөстәкыйль белем алуга корылган, ди Эмиль. Андагы китапханәләрдә искиткеч уңайлы шартлар тудырылган, тәүлек буе утырсаң да була. Яшь галим фикеренчә, Россиядә дә шундый шартлар тудырылса, илдәге белем бирү дәрәҗәсе яңа югарылыкка күтәрелер иде.

– Эмиль, чит илгә китеп, һәм шунда калган сәләтле белгечләргә сез нинди мөнәсәбәттә?

– Аларның бу адымын аңлыйм һәм гаепләмим. Грант ярдәмендә читтә укып, Татарстанга кайткан, әмма үз мөмкинлекләрен тормышка ашыра алмаган кешеләрне дә күп беләм. Нәтиҗәдә, бер-ике елдан соң алар йә чит илгә, йә Мәскәүгә китә. Шул ук вакытта, республикага әйләнеп кайтуга, «Алгарыш» программасы аша үткән белгечләр алдына «кызыл келәм җәеп», аларны шунда ук җылы урынга эшкә урнаштырырга кирәк, дигән фикер белән дә килешмим. Алар да югары хезмәт хакы түләнә торган эш урыннары өчен көрәшергә тиеш, – дип җавап бирде яшь галим.



Фатыйх Сибагатуллин, Россия Дәүләт Думасы депутаты:

– Сәләтле, акыллы яшьләрнең читкә китүе-бөтен Россия өчен бәла. Элек, геологлар Себергә дә, башка җирләргә дә, акча өчен түгел, романтика эзләп китәләр, дип әйтә идек. Хәзерге яшьләр чит илләргә хезмәт хаклары әйбәтрәк булганга юл тотадыр. Әмма бу мәсьәлә акчага гына кайтып каладыр, дип уйламыйм. Бүген бөтен кешенең дә югары белем аласы килә, тик аннан соң үз белгечлекләре буенча эшкә урнаша алмый йөриләр.

2019 елда Казанда үтәчәк «Ворлдскилс» эшче һөнәрләр буенча дөнья чемпионаты сәләтле яшьләрне үзебезгә җәлеп итүгә бер этәргеч булыр, дип ышанам. Иннополис шәһәренең булуы да киләчәккә карап эш итү. Башка төбәкләргә караганда, Татарстанда яшьләргә уку һәм эшләү өчен яхшырак шартлар тудырылган, әмма җитәрлек дәрәҗәдә түгел.

PRESSA.RU



2016 ЕЛ ЛАУРЕАТЛАРЫ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ

Декабрь – нәтиҗәләр ясау һәм иң яхшыларны билгеләү ае. Узып баручы елның авырлыкларын үткәндә калдырыр алдыннан, иң әүвәл, кичәге вакыйгалар агышын тагын бер кат барлыйсы килү бер дә гаҗәп түгел. Быел тормышыбызда булган иң истә калырлык вакыйга, иң шәп уңыш, иң үтемле проект дип нәрсәләрне атап була? 2016 елда безне кайсы шәхесләр аеруча рухландырган, шатландырган һәм гаҗәпләндергән? Шуларның барысын да берәм-берәм ачыкларга булдык.

Иң яхшыларны төрлечә билгеләргә мөмкин. Үз-үзенә нык ышанган «Тайм» һәм башка төр басмалар «Ел кешесе»н сайлаганда, редакция хезмәткәрләренең тар даирәсе карары белән генә чикләнә. «Татарстан» журналы исә 2016 ел лауреатларын демократик юл белән сайлады. Без укучыларга төрле номинацияләрдә катнашучылар өчен protatarstan.ru сайтында яки телефон аша тавыш бирергә тәкъдим иттек. Шул ук вакытта безнең экспертлар да, иң яхшыларны билгеләгәндә, беренче чиратта, укучылар арасында үткәрелгән сораштырулар нәтиҗәләренә таянды. Йомгаклау исемлегендә бер генә очраклы кеше дә юк иде. «Татарстан» журналы версиясе буенча 2016 елның барлык лауреатлары – лаеклылардан лаеклылар!

Иң өстенлекле «Ел кешесе» номинациясендә Анжела Вавилова исемендәге фонд идарәсе рәисе Владимир Вавилов җиңүче булды. Аның өчен журнал укучылар арасындагы сораштыруда катнашучыларның 46 проценты тавыш бирде (чагыштыру өчен: икенче урынны алган, Бөгелмәдә туып-үскән космонавт Сергей Рыжиков 33 процент тавыш җыйды, ә композитор София Гобәйдуллина – 18 процент). «Татарстан» укучыларының иң беренче чиратта, әүвәлгечә, игелеклелек һәм шәфкатьлелекне югары бәяләүләре сөендерә.

Журнал версиясе буенча «Ел җитәкчесе» булып Горький исемендәге заводның генераль директоры Ренат Мистахов танылды. Бу җиңүне ул үзе кебек үк нәтиҗәле эшләүче сәләтле җитәкчеләр – Рәфкать Кантюков (Трансгаз Казан газпромы) һәм Тимур Шәһивәлиев («Алабуга» МИЗ) белән «көрәшеп» яулады. Яшел Үзәндә эшләнгән, дошманнарны гаҗәеп төгәллек белән «утка тоткан» хәрби кораблар судно төзүче предприятиенең топ-менеджеры файдасына кире кагылмаслык дәлил булды – сораштыруда катнашучыларның яртысы диярлек аны беренче урынга куйды.

Җиңүчеләрне котлыйбыз!

«Татарстан» журналы версиясе буенча 2016 ел лауреатларының тулы исемлеге белән protatarstan.ru сайтында таныша аласыз. Редакция шулай ук лауреатлар исемлеген киләсе елның беренче санында бирергә планлаштыра.

«КАЗАНКА» СУ СИПТЕРҮ МАШИНАСЫ: ИМПОРТНЫ АЛЫШТЫРУ – ГАМӘЛДӘ!

«Татарстан» журналы версиясе буенча, Казан сугару техникасы заводы «Импортны алыштыра торган продукция» номинациясендә 2016 ел лауреаты булды. Тулысынча безнең республикада эшләнгән әйләнмәле «Казанка» су сиптерү машинасының Россиядә тиңдәшләре юк, һәм ул чит ил җайланмаларыннан байтакка арзанрак. Аны җитештерүдә нигездә Россиядә ясалган детальләр файдаланыла. Канәгать кулланучылар «Казанка»ның өстенлекләрен бәяләп өлгергән инде, ә без үз сферасында уникаль бу машинаның ничек пәйда булуы турында сөйләп бирербез.

«Быел «Идел буенда халыкара Кыр көннәре» күргәзмәсендә эшләп торучы «Казанка» җайланмасы тәкъдир ителде. Форумда катнашучылар һәм барлык кунаклар машинаның җыелу сыйфатын, детальләренең эшләнешен, аның нәтиҗәлелеген үз күзләре белән күрә һәм бәяли алды. Сезон башында аны кукуруз сугарырга куйганнар иде, күргәзмә вакытына кадәр үсемлекләрнең буе ике метрдан артты!» – дип сөйләделәр безгә «Казан сугару техникасы заводы» белгечләре.

«Казанка» җайланмасын куллану беренче чиратта уңышны сакларга, шулай ук аны берничә тапкыр арттырырга мөмкинлек бирә. Әйтик, кәбестә, су сиптерелмәгәндә, гектарыннан 300 центнер уңыш бирә, бу җайланма белән сугарганда исә әлеге сан гектарыннан 1000 центнерга җитә, һәм бөтен культуралар белән дә шундый нәтиҗә күзәтелә. Сугару җайланмасының төп заказчылары – яшелчә һәм терлек азыгы үстерү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләре. Тәүге канәгать клиентлардан инде киләсе елга да заявкалар килә башлаган.

Аны эшләүчеләр әйтүенчә, яңа су сиптерү машинасы базар ихтыяҗын канәгатьләндерү максатыннан җитештерелә башлаган. Россия сумының хәзерге халәтендә импорт аналогларның бәясе бик кыйммәт, ә запас частьларны кайтарып җиткерү вакыты уртача 45–90 көн тәшкил итә, бу исә уңыш күләмен киметергә мөмкин. Үзебезнең илдә җитештерелгән җайланма белән мондый проблемалар килеп чыкмаячак.

Кулланучы өчен файдалы бәяне җайланманың 70 процентын республикада җитештерү хисабына саклап була. Машина өчен металл эшләнмәләр предприятиенең үз мәйданчыкларында җитештерелә, җайланма «Ак Барс Металл» базасында цинк белән каплана, торбаларны «Әлмәт торба заводыннан» кайтарталар, авыл хуҗалыгы шиннары Түбән Камада һәм Белоруссиядә җитештерелә. Технология һәм логистика линияләрен грамоталы урнаштыру да вакытны һәм акчаны янга калдыру мөмкинлеген бирә.

«Казанканы» кулланучылар гына мактап калмый, аны республика Хөкүмәте, ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы, РФ Авыл хуҗалыгы министрлыгының мелиорация департаменты да югары бәяли. Мәскәүдәге «Алтын көз» агросәнәгать күргәзмәсендә җайланма «Импортны алыштыра торган иң яхшы проект» номинациясендә алтын медаль яулаган.

Тәҗрибәле һәм инициативалы коллективка таянып, предприятие ирешелгәннәргә генә канәгать булып калмый. «Казан сугару техникасы заводы» планнарында – барабан тибындагы сугару җайланмалары җитештерүен эшләтеп җибәрү һәм төрле типтагы сугару җайланмалары өчен дизельле насос станцияләре эшләү, җыю юнәлешен булдыру.

Якындагы өч елда елына 300 «Казанка» җайланмасын җитештерү проект куәтенә чыгу планлаштырыла.

Нәрсәдән башланган иде

«Татмелиотехсервис» компаниясенә 2010 елда нигез салына һәм ул сугару техникасын кайтарту, монтажлау, аларга сервис һәм гарантия хезмәте күрсәтүдә махсуслаша.
5 ел эшләү дәверендә республикага 500 данәдән артыграк техника, шул исәптән дизельле насос станцияләре, барабан тибындагы җайланмалар һәм киң колачлы сугару җайланмалары кайтартыла.
Биш елда тупланган тәҗрибәгә, бу сферада Россия җитештерүчеләренең булмавына, шулай ук техниканың бу төрենә югары ихтыяҗга таянып, 2015 елда Татарстан Республикасы территориясендә үз җитештерүләрен булдыру турында карар кабул ителә. 2016 елда ук инде «Казан сугару техникасы заводы» кырларга үзенең 14 җайланмасын урнаштыра. 2016 елда «Казанка» җайланмасы сынауларны уңышлы үтә һәм Таможня Берлегенең һәм ГОСТ-Рның туры килү сертификатларын ала.

Реклама

PRESSA.RU

«ЛУЖНИКИ» СТАДИОНЫНЫҢ ИКЕНЧЕ СУЛЫШЫ

«Ел проекты» номинациясе: «Казан Гипронииавиапромы» АҖ катнашында «Лужники» Зур спорт аренасын реконструкцияләү проекты.

Мәскәүнең атаклы «Лужники» Зур спорт аренасы тарихы 1954 елдан башлана. Ул чакта СССР Хөкүмәте илдә спортны үстерүгә тәгаенләнгән гаять зур спорт комплексы төзү турында карар кабул итә. Стадион тантаналы рәвештә 1956 елның 31 июлендә ачыла.

60 ел дәверендә стадион берничә тапкыр реконструкцияләнә, шуларның иң зурысы 1980 елгы җәйге Олимпия уеннарына үзгәртеп кору була.

Ил белән бергә спорт комплексы да авыр еллар кичерә. 1990нчы елларда ул хосусыйлаштырыла һәм базарга әйләндерелә. Спорт корылмасы статусы аңа җәмәгатьчелек басымы астында 2003 елда гына кире кайтарыла.

Бүген «Лужники» ЗСА реконструкцияләүнең төгәлләнү стадиясендә.

«Лужники» спорт комплексының Зур спорт аренасын реконструкцияләүнең максаты – 2018 елда футбол буенча дөнья чемпионаты матчларын (финал уенын да кертеп) үткәрерлек стадион төзү. Моннан тыш, илнең төп аренасы күпфункциялегә әйләнәчәк, ул мөһим спорт ярышларын гына түгел, бәлки әһәмиятле мәдәни чараларны да үткәрерлек итеп үзгәртеләчәк. Шул ук вакытта стадионның тарихи йөзе дә сакланып калырга тиеш.

Проектлаучыларга берничә катлаулы бурычны хәл итәргә кирәк иде. Аерым алганда, шундый вариант тәкъдим итү соралды: объектның гадәти күренешен саклап калып, аны ФИФАның катгый таләпләренә җавап бирерлек һәм абсолют заманча корылмага әйләндерү зарур. Шул ук вакытта бинаның тарихи диварларын һәм түбәнең терәк конструкцияләрен саклап калу таләп ителә – тышкы колонналар, матчалар, аскы һәм өске терәк бөҗралар һәм хәтта баскычның гранит басмаларына кадәр үзгәртелмәскә тиеш.

Башка мәҗбүри шартлар арасында – җанатарлар өчен уңайлы шартлар тудыру. Бу бурычны да берничә принципиаль чишелеш хисабына уңышлы хәл иткәннәр. Яңа трибуналар кырга максималь якынайтылган, стадион тәлинкәсенең геометриясе үзгәртелгән, йөгерү юллары алынган. Моннан тыш, трибуналар контуры тагын да «турыпочмаклыракка» әйләнгән, аларның авышлыгы үзгәртелгән, ике ярус өстәлгән. Әлеге үзгәрешләр ФИФА таләбенә – стадион 81000 тамашачыны сыйдырырга тиеш – һәм тарихи фасад белән түбәне саклап калу зарурлыгына бәйле.

Яңа стадионның үзенчәлеге – кырның инженер-техник тәэмин итү системасы (дренаж, җылыту, су сиптерү, агротехника характеристикалары мониторингы, хезмәт күрсәтүне автоматлаштыру һәм диспетчерлаштыру) булдырылган табигый катламы.

«Лужники» ЗСА реконструкцияләү проектында «Мирас» режимы өчен дә чишелешләр чагылдырылган. «Мирас» режимы ФИФА, ЛОК административ биналары буларак файдаланылган мәйданнарны, шулай ук стюардлар, волонтерлар бүлмәләрен, матбугат үзәген чемпионаттан соң коммерция мәйданнарына үзгәртеп коруны күздә тота.

Реконструкцияләүнең мондый катлаулы бурычларын берничә проектлау оешмасы, генераль проектлаучы һәм объект төзелеше өчен дә җаваплы «Мосинжпроект» АҖ, «СПиЧ» ҖЧҖ, «Метрополис» ҖЧҖ, безнең «Казан Гипронииавиапромы» АҖ, «КИТ» ҖЧҖ һәм башкалардан торган иҗади коллектив хәл иткән.

Реклама

Спорт корылмалары проектларын эшләү безнең коллектив өчен яңалык түгел. «Казан Гипронииавиапромы» белгечләре хисабында – «Ракета» стадионын реконструкцияләү, табигый катламлы кыры белән «Рубин» ФК спорт базасы, «УНИКС» спорт-тренировка базасы, Казан Олимпия резервлары училищесы, «Авиатор» БЯСМ спорткомплексы, Ваһапов урамындагы спорт-тренировка ябык шугалагы. Бу шулай ук 2013 елгы Универсиаданың мөһим объектлары – Су спорт төрләре сарае, «Акчарлак», «Бустан», «Олимп», «Буревестник» бассейннары, Яңа Чишмәдәге һәм Аксубайдагы бассейннар, Чистайдагы «Восток» стадионын реконструкцияләү дә.

Үзгәртеп корыла торган «Лужники» ЗСА өчен безнең белгечләр архитектура бүлегенең эш документациясен, конструктив, технология һәм генераль планын, шулай ук ике вертолет мәйданчыгын эшләде.

Металл конструкцияләр Tekla («Текла») программасында, архитектурасы һәм конструктивы Revit («Ревит») программасының бер үк BIM (БИМ) моделендә эшләнде, бу чиктәш бүлек сызымнарындагы төгәлсезлекләрне максималь киметү мөмкинлеген бирде.

Миңа, проектның баш инженеры буларак, үзебезнең белгечләрнең югары грамоталылыгына, иң катлаулы мәсьәләләрне хәл итә алу сәләтенә, кызыклы чишелешләр таба алу осталыгына тагын бер тапкыр инанырга туры килде!

Г.Никитин, Г.Уткузова, Л.Березина кебек проектлау «зубрларын» кабат билгеләп үтәсем килә. Һәм алардан бер дә калышмаучы яшьләрне – Р.Сафиуллин һәм Т.Максутовны да мактау зарур – алар 25 кешелек конструкторлар коллективы белән җитәкчелек итте һәм бик кыска вакыт эчендә конструктив өлешне эшләп өлгертте. Проектның баш архитекторы Р.Ибраһимов һәм аның ярдәмчеләре – архитекторлар Р.Вәлиев, Б.Блинов, Т.Ганина, Р.Галләмов, Ф.Хисаметдинов, О.Григорьеваны, яшь, өметле архитектор Л.Ульянова һәм генпланчы Д.Гарифуллинны, технологлар Д.Есин, А.Салихова, Р.Юсупов, Г.Степанованы, шулай ук корылманың бөтен технологик аспектларын хәл иткән Т.Краснованы («Татьяна» ҖЧҖ) да мактау урынлы булыр.

Безнең проектлаучыларыбыз, кайбер кыенлыкларга, вакыт азлыгына һәм эшнең зур күләменә карамастан, үз бурычларын уңышлы үтәде – нәкъ Мәскәү шәһәре төзелеш департаменты билгеләгән вакытка өлгертте. «Лужники» Зур спорт аренасы 2017 елда Конфедерацияләр кубогы һәм 2018 елда футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрүгә әзер булачак.

420127, Казан шәһәре, Дементьев урамы, 1 йорт. Тел. (843) 571-95-48, Факс (843) 571-96-56

«Казан Гипронииавиапромы» АЖ проектлары баш инженеры
Гайсина Гүзәлия Тәбриз кызы.

PRESSA.RU

ХАКИМИЯТ: ЯХШЫДАН – БИК ШӘПКӘ

«Әгәр сез фил ашарга җыенасыз икән, аңа артык озак карап торырга кирәкми», – диләр КФУның Дәүләт һәм идарә югары мәктәбендә һәм шунда ук аны ничек тә тизрәк һәм нерв системасына зыян китермичә ашау буенча конкрет киңәшләр дә бирәләр. Чөнки бу очракта «фил» ул – берничек тә чишелмәслек булып тоелган бик катлаулы мәсьәлә.

Автор:
Катерина Котова

НӘТИҖӘЛЕЛЕК ӨЧЕН

Яңа ел – нәтиҗәләр ясар вакыт. Хәер, бу мәктәптә нәтиҗәләрне елына бер тапкыр гына түгел, ә күпкә ешрак ясыйлар. Шулай ук бу дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең ихтыяҗларына оператив рәвештә җавап кайтарырга гына түгел, бәлки яңа заман таләпләренә ярашлы рәвештә үзгәрергә дә мөмкинлек бирә.

– Татарстанның югары үсеш темпларыннан артта калмас өчен, дәүләт хезмәткәрләренең беренче звеносыннан алып югары вазыйфаи затларга кадәр һәркайсына үзләрен даими тонуста тотарга кирәк, – дип раслый Дәүләт һәм идарә югары мәктәбе директоры Игорь Привалов. – Урыннарда табигый сайланыш бара. Әгәр син көн саен камилләшмисең икән, кайсыдыр этапта сине узып китүләре бар.

Бу җәһәттән 2017 елда Мәктәп иң уңышлы программаларны гына гамәлгә кертергә планлаштыра. Алар арасында – яңа эшли башлаган хезмәткәрләр өчен база программалары, эшчәнлекнең конкрет спецификасына басым ясалган тармак программалары, шулай ук җитәкчеләр өчен махсус квалификация күтәрү курслары. Быел, мәсәлән, башкарма комитет җитәкчеләре өчен модуль нәтиҗәле үткән. Авыл җирлекләре башлыклары өчен проблематикага «чуму» программасы тагын бер уңышлы проект булган. Киләсе елда Мәктәптә тыңлаучыларның бу категориясенә берничә бик кызыклы тренинг курсы тәкъдим итәчәкләр.

«ФИЛ» ТУРЫНДА, ЯКИ КАЙРОСНЫ НИЧЕК ТАБАРГА?

«Әгәр сезгә филне ашарга кирәк икән, йотлыкмас өчен, аз-азлап чеметеп кенә кабу яхшырак». Бу сәер киңәш – тайм-менеджментның төп кагыйдәсе икән, «фил» исә – зур, катлаулы эшне аңлата торган метафора. Вакыт белән идарә итү – яңа буын белгечләренең «фишка»ларыннан берсе.

Дәүләт хезмәткәренең эшчәнлеге шактый катгый регламентланган. Шул ук вакытта көн саен билгесезлек белән бәйле бик күп хәлләр килеп чыга, минут саен яңа таләпләр туа. Хронометраж көчсез чакта эш вакытыңны ничек планлаштырырга соң? Мәктәптә вакытның кадерен белергә генә түгел, аның белән идарә итәргә дә өйрәтәләр.

– Без үз алдыбызга тыңлаучыларыбызда зирәклек формалаштыру бурычын куябыз, – дип сөйли Мәктәп директорының беренче урынбасары Галина Маштакова. – Аларны үз вакытларын дөрес планлаштырырга өйрәтәбез: конкрет бурычларны календарьга катгый бәйләп куярга түгел, бәлки аларны башкару өчен уңайлы вакыт табарга. Тайм-менеджментта бу «кайрос» дип атала.

«Вакыт белән идарә итү» – Мәктәп үзенең база белеме бирү программаларын тәмамлый торган дүрт тренингның берсе. Хәер, тыңлаучыларга сайлап алу өчен башка кызыклы темалар да тәкъдим ителә: «Нәтиҗәле коммуника-

Реклама

циялəр», «Стресс белән идарә итү» яки «Презентацияләр әзерләү».

– Без тренингларны шул рәвешле төзедек ки, алар нәкъ менә безнең дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләребез өчен программаларыбыз контекстында файдалы булырга, димәк, алар эшенең спецификасын тулысынча күздә тотарга тиеш, – дип басым ясый Галина Маштакова.

БАШЛЫК ӨЧЕН МӘСЬӘЛӘ

Андрей Вадимовичны югарырак урынга күтәргәннәр. Уңышлы башкаручы булырга күнеккән кеше башлыкка әйләнүенең беренче көннәрендә үк көтелмәгән проблемаларга юлыгуын яшерми. Үзенә буйсынучыларның эшен ничек дөрес планлаштырырга? Алар алдына нинди максат һәм бурычлар куярга? Һәм, иң мөһиме, персоналның «стахановча» эшләвенә ничек ирешергә? Шул сорауларга җавап эзләп, Мәктәпкә килгән ул.

– Быел без «яшь сугышчы курсын» – яңа эшли башлаган җитәкчеләр өчен велкам-тренингны гамәлгә кертә алдык, – дип сөйли юнәлешнең кураторы, Мәктәп директоры урынбасары Наталья Аксенова. – Инде берничә төркем чыгарырга өлгердек. Нәтиҗәләр искиткеч! Яңа эшли башлаган җитәкчеләр һәрвакыт булачак, димәк, бу курс та үзенең актуальлеген югалтмаячак.

Программа 36 сәгатькә исәпләнгән. Инде үзенең нәтиҗәлелеген әллә ничә кат раслаган тренинг форматында яңа билгеләнгән җитәкчеләргә нәтиҗәле коммуникацияләр, сөйләшүләр һәм киңәшмәләр әзерләү күнекмәләрен сеңдерәләр, шулай ук персонал белән идарә итүнең кызыклы технологияләре белән таныштыралар. Әйе, нәкъ менә шулар ярдәмендә Андрей Вадимович үз кул астындагыларны хезмәт батырлыкларына илһамландыра алачак.

– Тренинг процессында без башлыкка буйсынган кешенең мотивация ноктасын эзләргә һәм, шуңа таянып, бурыч куярга тиеш, – дип аңлата Наталья Аксенова. – Беләсезме, мотивация һәрвакытта да матди булмый ул. Һәм бу мөһим дә! Дәүләт хезмәткәрләренең эш хакы иң зурдан түгел, әмма без алар арасында бик теләп эшли торган кешеләрне беләбез. Менә, бар бит шундыйлар да, эшлиләр һәм үз эшләреннән рәхәтлек табалар! Димәк, алар өчен уңайлы мохит булдырылган – яхшы коллективлар, җитәкчелекнең дөрес линиясе... Чын күңелдән хезмәткә бирелгәнлек шулай формалаша да инде. Нәкъ менә шушылай итеп әлеге мохиттәге булачак җитәкчеләр үзләренә буйсынган хезмәткәрләрдә лояльлекне ничек формалаштырып булуны аңларга тиеш.

БАШЛЫК ӨЧЕН БАШВАТКЫЧ

– Крестьян-фермер хуҗалыклары – яхшы тема. Әмма яңа КФХның мөлкәте һичшиксез авылда теркәлсен, югыйсә салымнары сездән «агып китәчәк», – дип, үзенең кыйммәтле киңәшләрен бирә ТР Муниципаль берәмлекләре Советы вәкиле. Мәктәптә яңа программа – анда авыл җирлекләре башлыклары катнаша.

– Бүген бу кешеләрнең җилкәсенә хуҗалыкка караган гына түгел, һәм икътисадый, һәм юридик мәсьәләләр, стратегик планлаштыру, оештыру эше дә өелә – нюанслар шулкадәр күп ки, хәтта тәҗрибәле идарәчеләр дә югалып калырга мөмкин! – ди Галина Маштакова. – Алар үз проблемалары белән ялгыз калмасын өчен, без махсус курс эшләдек. Ул искиткеч уңышка иреште. Башлыклар республика Президенты исеменә рәхмәт хаты юллап, бу программаны 2017 елга да калдыруларын үтенделәр. Әлбәттә, без аны үз планнарыбызга керттек.

Курс форматын моңарчы күрелмәгән дип әйтеп була – ул тыңлаучылар өчен генә түгел, авторларның үзләре өчен дә чын ачышка әйләнде. Күп сәгатьлек «акыл атакасы» шулай оештырылган ки, кайвакыт анда катнашучылар арасында синергия искиткеч куәтләнеп китә.

Программаның тагын бер үзенчәлеге – анда чакырылган экспертларның (республика министрлыклары һәм ведомстволары, Президент Аппараты һәм ТР Дәүләт Советы вәкилләренең) күп булуы.

– Бу программага тиңнәр юк! – ди Галина Юрьевна. – Нибары ай ярым вакыт эчендә без 300 җирлек башлыгын укытырга өлгердек! Кешеләр тулысынча ачылды, күп кадагындагы сорауларны бирә һәм шунда ук, үз коллегалары һәм белгечләр белән бергә, аларга җавап эзли башлады. Гомумән, алар өйләренә яңа белем белән илһамланып кына түгел, ә бәлки авыл проблемаларын хәл итүнең конкрет ысуллары белән дә коралланып кайтып киттеләр.

КИЛӘЧӘККӘ ПЛАННАР

Камиллеккә чик юк – бирелә моны белеп кенә калмыйлар, практикада да кулланырга омтылалар. Сүз уңаеннан, Мәктәптә практика – иң яраткан шөгыль. Нәкъ менә ул дәресләрнең күләме һәм форматына кагылышлы үзгәрешләргә сәбәп булачак та инде: 72 сәгатьлек курслар компактлы 50 сәгатьлеккә әйләнәчәк, программалар тәртибендә ерактан торып (дистанцион) укыту модуле пәйда булачак.

– Без традицион лекция форматыннан бераз китәргә булдык. – дип сөйли Наталья Аксенова. – Эш шунда ки, бүген бөтен мәгълүматны интернеттан табып була. Аны эзләү вакытын киметү өчен, 22 сәгатьлек дистанцион курслар эшләдек, аларны база программаларына кертергә планлаштырабыз. Бик тиздән Мәктәп сайтында мөстәкыйль өйрәнү өчен актуаль материаллар, норматив актлар җыелмалары һәм видеороликлар пәйда булачак.

Дистанцион укыту модулен керткәннән соң, биредә онлайн-тест үткәрүне дә башларга җыеналар. Аның нәтиҗәләре өлгерешне бәяләгәндә исәпкә алыначак.

– Бер яктан караганда, без шул рәвешле кызыксыз лекцияләр форматыннан китәргә телибез, икенче яктан – дәресләрне максималь нәтиҗәле итәсебез килә, – ди Наталья Аксенова. – Әйтик, быел без укытуның кейс ысулын сынап карадык. Әзер белем генә бирмичә, конкрет ситуацияләрне бергәләп тикшерү һәм проблемаларны хәл итү юлларын эзләү өчен, аны безнең барлык программаларыбызга диярлек кертергә җыенабыз.

2016 елда Мәктәптә 5700 кеше укыган. Киләсе елга планлаштырылган эшләр күләме дә шаккатырлык. Әмма бу хисап саннары артына тагын да күбрәк нәрсә яшеренгән, чөнки аларның һәркайсы Татарстан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең нәтиҗәлелеген, димәк ки, республикабызның муллыгы артуын да күрсәтә.

PRESSA.RU

ГАМӘЛДӘГЕ ЭНЕРГИЯ

«Татэнергосбыт» АҖ РФнең иң нәтиҗәле гарантия белән тәэмин итүче лидерлары исәбенә керә. Хезмәтләрендә елдан-ел югары нәтиҗәләргә ничек ирешә алулары турында компания директоры Рифнур Сөләйманов сөйли.

Рифнур Сөләйманов, «Татэнергосбыт» АҖ директоры, ТР Дәүләт Советының бишенче чакырылыш депутаты.

– Рифнур Хәйдәрович, 2015 ел нәтиҗәләре буенча компания «Базар советы КБП» Ассоциациясенең «Сату компанияләре: базардагы нәтиҗәлелек» рейтингында икенче урынны яулады. Быел «Татэнергосбыт» шулай ук «Россиянең иң яхшы энергия сату компаниясе» дип аталган VI Бөтенроссия бәйгесенең җиңүчесе дә булды. Компания эшчәнлеге нинди күрсәткечләр буенча бәяләнде?

– «Базар советы КБП» Ассоциациясе рейтингы буенча, Россиянең һәрбер сату компаниясенең позициясе эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге һәм ышанычлылыгы буенча бәяләнде. Рейтинг лидерлары исәбенә керү өчен компания кумәртәләп сату базарында электр энергиясен һәм егәрлекне үз вакытында һәм тулы күләмдә түләргә, электр энергиясен ваклап сату базарында эшнең югары нәтиҗәлелеген күрсәтергә, иң яхшы ликвидлыкка, рентабельлелеккә ия булырга, ә менә конфликтлылык күрсәткечләре буенча түбәндә торырга тиеш. «Татэнергосбыт» АҖ инде берничә ел дәвамында энергетика тармагы компанияләренең динамик үсешенә кирәкле барлык критерийларга да туры килә. «Россиянең иң яхшы энергия сатучы компаниясе» бөтенроссия бәйгесенә килсәк, бәйгенең биш номинациясендә 39 төбәктән 48 компания катнашты. 2015 елдагы эш нәтиҗәләре бәяләнде. «Татэнергосбыт» барлык бәйге номинацияләренә дә тәкъдим ителгән иде, һәм ул аларның һәрберсендә дә югары нәтиҗәләр күрсәтте. «Клиентларга максималь якын килә торган энергия сатучы компания» номинациясендә безнең компания беренче урынны алды. Биредә юридик һәм физик затларга хезмәт күрсәтү тәҗрибәсе һәм база принциплары бәяләнде. Шулай ук «Энергия сату + энергия саклау» номинациясендә дә компаниябез җиңүче булды. Компаниянең энергия нәтиҗәлелеге һәм энергия саклау өлкәсендә күрсәткән хезмәтләре спектры да иң югары бәягә лаек булды.

– Сезнең компаниянең клиентларга юнәлгәнлеге турында сөйләшик әле. Клиентларга хезмәт күрсәтү процессында үз алдыгызга нинди максатлар куясыз?

– «Татэнергосбыт» компаниясе максималь дәрәҗәдә ачык булуны максат итә. Без клиентларга якын килү өчен хезмәт күрсәтүнең стандартларын яхшырту һәм яңа карарлар эзләү юнәлешендә даими эш алып барабыз.

Аерым алганда, хәзер бөтен Татарстан буенча тугыз филиал, клиентларга хезмәт күрсәтү буенча 56 офис эшли. Клиентларга юнәлдерелгән расланган сәясәт буенча, без кулланучыларның төрле категорияләре белән эш процессларын бердәм нормага китерергә, читтән торып һәм дистанцияле сервисларны үстерергә планлаштырабыз.

– Сервис ягыннан соңгы вакытта сезнең компания физик затлар өчен нинди яхшы үзгәрешләр кертте?

– Бүгенге көндә без 850 меңнән артык физик затка хезмәт күрсәтәбез. Уңайлылык өчен компания белгечләре «Татэнергосбыт» АҖнең «Шәхси кабинеты» мобиль кушымтасын эшләде, аны Windows Phone, Android һәм iOS операция базасындагы смартфон ияләре файдалана ала.

Бүгенге көнгә «Шәхси кабинет»та 121 меңнән артык файдаланучы теркәлгән. Билгеле, бу очраклы хәл түгел – без гади һәм уңайлы интерфейс, тәүлек буена керү мөмкинлеге тәкъдим итәбез бит. Клиентларыбызның барлык теләкләрен дә истә тотабыз. Биредә шәхси счет торышын карарга, исәпләү приборлары күрсәткечләрен тапшырырга, квитанцияләрне бастырып алырга, комиссиясез генә онлайн-түләү башкарырга мөмкин. Шулай ук электр энергиясе бәясе калькуляторыннан файдаланырга, мөрәҗәгатьләр белән идарә итәргә, документларның күчермәләрен җибәрергә, компания белгеченең җавап шалтыратуына заказ бирергә мөмкин.

– «Татэнергосбыт» АҖ быел юридик затларга хезмәт күрсәтү өлкәсендә нинди яхшы яңалыклар кертте?

– Хәзерге вакытта без 33 меңнән артык юридик затка хезмәт күр-

Реклама

сәтәбез. Аларга хезмәт күрсәтү уңайлы булсын өчен агымдагы елның сентябрендә «Татэнергосбыт» АҖ белгечләре компаниянең рәсми сайтында электр энергиясе бәясенең яңартылган калькуляторын тәкъдим иттеләр. Калькулятор кече бизнеска файдалы – максималь егәрлеге 670 кВт ка кадәр булган бик зур булмаган кулланучыларга, мәсәлән, сәгатьләп исәпләү приборларын кую зарурлыгын ачыкларга ярдәм итә. Эре кулланучылар калькулятор ярдәмендә оптималь бәя категориясен билгеләп кенә калмыйча, электр куллануның нинди графигы бәяне төшерүгә ярдәм итәчәген дә аңлый ала. Калькулятор яңа гына үз бизнесын башлап җибәрүчеләр өчен дә файдалы. Ул электр энергиясенә булачак чыгымнар дәрәҗәсен ачыкларга ярдәм итә.

– Рифнур Хәйдәрович, электр энергиясе өчен соңгы бәя ничек формалаша, һәм аның өлешләренә нинди факторлар йогынты ясый? Шуның турында тулырак сөйләгез әле.

– Безнең компаниянең төп бурычларының берсе, мин моның турында әйтеп узган идем инде, кулланучылар алдында мәгълүмати хәбәрдарлык һәм исәпләрнең үтә күренмәлелеге. Юридик затлар өчен соңгы бәяләрне, халык өчен куелган бәядән тыш, гарантия тәэминатчылары мөстәкыйль рәвештә исәплиләр. Әлеге исәпләүләр катгый законнар буенча, ваклап сату базарында бәя формалаштыру өлкәсендәге норматив-хокукый актларга туры китереп тормышка ашырыла. Ахыргы бәя төп өч өлештән тора: күмәртәләп сату-алу базарында сатып алу бәясе һәм инфраструктура түләүләре, электр энергиясен тапшыру буенча челтәр хезмәтләре һәм гарантия тәэминатчыларының сату өстәмәсеннән тора. Бәя ясалу мәсьәләләре буенча безнең компаниянең үз кулланучылары белән эшлекле сөйләшүгә һәрвакыт ачык булуын һәм барлык кызыксындыручы сораулар буенча аңлатмалар бирергә әзер булуын да әйтеп китәргә кирәк.

– Компания энергия саклаудагы тәртип моделен популярлаштыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыра. Аларны компания ни өчен тормышка ашыра, һәм бу нинди проектлар?

– Формаль мантыйк күзлегеннән караганда, энергия сатучы компания куллануны, безнең очракта электр

энергиясен, максимальләштерүгә омтылырга тиеш. Ә без, киресенчә, ресурсларны нәтиҗәле куллануырга өндибез. Әйе, безгә электр энергиясен сатуны арттыру файдалы, әмма клиентларыбыз хисабына түгел, ә аларның санын арттыру, Татарстанда җитештерү һәм икътисадны үстерү хисабына. Шуңа күрә компаниядә тормышның энергия саклау рәвешен пропагандалау буенча төрле чаралар уздырыла. Мәсәлән, без традиция буенча энергия саклау темасына «Кояш куянчыгы» дип аталган балаларның иҗади эшләре республика бәйгесен оештырабыз. Сүз уңаеннан, ул ENES 2015 федераль бәйгесендә иң яхшы төбәк проекты дип табылды. Агымдагы елда без «Бергә яктырак» бөтенроссия фестивалендә актив катнаштык, ә республиканың 65 мәктәбендә компания белгечләре энергия саклау темасына дәресләр уздырды.

– Компаниянең үсеше буенча киләсе елга планнарыгыз белән дә уртаклашыгыз әле.

– Агымдагы елда без, беренче чиратта, сатулар күләмен саклау һәм арттыруга һәм безнең кулланучыларның эше өчен тагын да уңайлы шартлар булдыруга, шулай ук клиентлар белән электрон хезмәттәшлекне киңәйтүгә юнәлдерелгән проектларны эшләтеп җибәрдек. Электрон документ әйләнешен кертү безгә вакыт, кеше һәм финанс чыгымнарын шактый киметергә мөмкинлек бирә. Без клиентларыбызны – юридик затларны актив рәвештә килешүләр, түләү һәм хисап документларын электрон рәвештә алмашу практикасына җәлеп итәргә планлаштырабыз. Планлаштырылган барлык проектларның да югары профессиональлек һәм җаваплылык белән үтәләчәгенә нык ышанам, чөнки безнең компаниянең моның өчен иң әһәмиятле өлеше – гомуми максатлар һәм уңышлы эш тәҗрибәсе белән берләшкән югары профессиональ белгечләрнең оешкан командасы бар.



ТАТЭНЕРГОСБЫТ
Тормыш энергиясе

«Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыяте
(843) 567-70-59, факс: (843) 567-70-15
www.tatenergosbyt.ru

PRESSA.RU

КИЛӘЧӘК ЭНЕРГИЯСЕ ЧЕЛТӘРЛӘРЕНДӘ

2016 елда «Челтәр компаниясе» ААҖ Бигештә 220 кВ лы подстанция төзү һәм файдалануга тапшыру буенча чираттагы гаять зур проектны тормышка ашырды. Узып бара торган елда компаниянең республика халкы һәм Татарстанның барлык энергетика тармагы өчен кызыклы һәм мөһим тагын нинди проектларны гамәлгә кертүе турында «Татарстан» журналына техник директорның эксплуатация һәм ремонт буенча урынбасары Дмитрий Фамин һәм бүлү челтәрләре хезмәте башлыгы Дмитрий Шаповалов сөйләде.

Дмитрий Фамин

Дмитрий Шаповалов

– Нефть-химия сәнәгате предприятиеләренең тулы бер кластерын энергия белән тәэмин итә торган «Бигеш» заманча подстанциясенең перспективалары күзгә күренеп тора. Ә менә берничә дистә еллык объектларның хәле ничек?

Дмитрий Фамин:

– Быел система хасил итүче ике подстанцияне – 500 кВ лы «Бөгелмә» ПС һәм 500 кВ лы «Киндери» ПС модернизацияләүне дәвам итте. Бу подстанцияләрнең зур һәм данлыклы тарихы бар, аларны төзү Татарстан энергетика системасы үсеше тарихындагы мөһим вакыйгалар белән бәйле. 1954–1964 елларда 500 кВ лы «Бөгелмә» ПС төзү ул чорда актив үсештәге «Татнефть» җитештерү берләшмәсенең нефть чыгару комплексы объектларын энергия белән тәэмин итү зарурлыгына бәйле. 2400 МВт куәтле Зәй ГРЭС ын төзү белән бер үк вакытта, Казан энергетика узелы предприятиеләрен энергия белән тәэмин итү һәм Европа энергосистемасының Урал һәм Себер системалары белән тотрыклы электр бәйләнешен булдыру максатыннан, Зәй – Киндери һава линиясе һәм 220/110/10 кВлы Киндери подстанциясе (1963 елда файдалануга тапшырылган, 1970 елда 500 кВ лы көчәнеш классына күчерелгән) дә төзелә. Файдалануга тапшырылган вакытта ике подстанция дә техниканың ул замандагы таләпләренә җавап бирә. Әмма хәзер бу җиһазлар физик һәм мораль яктан искергән, күптән җитештерүдән алынган, алардан файдалану ресурсы бетә язган… 2011 елда Казан энергия районы электр челтәрләре комплексын масштаблы реконструкцияләү башланды, шул исәптән 500 кВ лы «Киндери» подстанциясен дә. 500 кВ лы «Бөгелмә» ПС этаплап реконструкцияләү 2014 елда башланды.

– Кагыйдә буларак, компания үзенең барлык объектларын билгеләнгән вакыттан иртәрәк файдалануга тапшыра. Моның өчен нинди дә булса махсус оештыру технологияләре кулланыламы?

Дмитрий Фамин:

– Энергетика объектларын вакытында файдалануга тапшыру – беренче чиратта, компания белгечләренең, проектлаучыларның, җиһаз китерүчеләр белән төзү-монтаж оешмаларының көйле эше нәтиҗәсе ул. Әлеге нәтиҗәгә ирешү максатыннан, эре объектлар өчен компаниядә штаблар институты уңышлы гамәлгә кертелә – һәр аеруча җаваплы объектка идарә яки филиал аппараты җитәкчеләреннән берсе персональ беркетелә. Ул көн саен объекттагы вазгыятьне, җиһазлар әзерләү һәм китерү, аны монтажлау срокларын тикшереп тора. Практика күрсәткәнчә, кул режимындагы һәм реаль вакыттагы мондый идарә – «оештыру технологияләре»нең идеаль формасы. Безнең подрядчылар һәм тәэминатчыларның барлык кирәкле лицензияләре, персоналы һәм махсус техникасы булган ышанычлы һәм еллар буена сыналган компанияләр булуы да эшләрнең оператив, сыйфатлы һәм үз вакытында башкарылуына ярдәм итә.

– Бүлү челтәре объектларын реконструкцияләгәндә компания нинди яңа технологияләр куллана?

Дмитрий Шаповалов:

– Бүлү челтәрләре объектларын реконструкцияләүне һаман да изоля-



Реклама

циялe үткәргечләр һәм Скандинавия илләрендә үзләрен яхшы күрсәткән, файдалануда отышлырак булган агач баганаларны кулланып дәвам итәбез.

Фин коллегаларыбыз тәкъдиме буенча, линия объектларын реконструкцияләгәндә 2014 елдан бирле ике перспективалы юнәлештән файдаланабыз.

10 кВ лы озын тармакланган һава линияләре электр тапшыргыч фидерларында «Энсто» фин компаниясе җитештергән Augusto («Аугусто») элегаз бак йөкләнеш өзгечләрен куябыз. Инновацион җиһазларны челтәрнең аеруча проблемалы участокларына урнаштырып, без автомат рәвештә, санаулы минут эчендә, зыян килгән участокны ачыклый һәм кулланучыларның күбесен электр белән тәэмин итүне саклап кала алабыз, шулай ук ремонт бригадасына зарарланган участокны төгәл күрсәтеп, зыян күргән урынны эзләп табуга киткән чыгымнарны киметәбез. Хәзерге вакытта инде шундый 146 өзгеч Әлмәт, Буа, Алабуга, Түбән Кама, Идел буе һәм Чистай челтәрләренең аеруча проблемалы линияләрендә урнаштырылган. Булу челтәрләре линияләрен мондый өзгечләр белән тулысынча тәэмин итү буенча бишьеллык программа формалаштырылган, бу киләчәктә кулланучыларыбызны электр энергиясе белән тәэмин итү сыйфатын тагын да яхшырту мөмкинлеген бирәчәк.

– Ә икенче юнәлеш?

Дмитрий Шаповалов:

– Ул 0,4 кВ лы электр тапшыру линияләренә кагыла. Без түбәндәге проблемага тап булдык – кулланучыларның тормышы яхшырган саен, йорт хуҗалыкларындагы электр алгычлары саны да арта, һәм, нәтиҗә буларак, алар кулланган электр энергиясе күләме дә арта. Нәтиҗәдә тузендыру үзәгеннән ераграк урнашкан кулланучылар челтәрендә көчәнеш кими. Мондый линияләрне реконструкцияләгәнче, аларда вольт өстәгечле трансформаторларны (ВТД) урнаштырабыз, алар линиянең буеннан-буена көчәнешне «тигезли». Челтәрдәге бу объектны реконструкцияләү чираты җиткәч исә, ВДТ сүтеп алына һәм башка проблемалы объектка күчерелә.

Моннан тыш, тирән кертү челтәрләрен булдыру эшен дәвам итәбез – бу очракта кулланучы 6/10 кВ лы линиягә турыдан-туры шәхси баганалы трансформатор аша кушыла. Республика буенча кайбер проектлар инде уңышлы гамәлгә кертелгән, хәзерге вакытта безнең бирем буенча Алтай трансформатор заводы (Алтранс) баганалы берфазалы трансформаторлы подстанция конструкциясен эшләде, без аны киләчәктә булу челтәрләрен тирән кертү ысулы белән реконструкцияләгәндә кулланырга планлаштырабыз.

– Мөгаен, челтәрләрне модернизацияләү компаниядән шактый ресурслар файдалануны таләп иткәндер. Ә бит шул арада кыш якынлаша, димәк, линияләрдә бозлавык куркынычы туа.

Дмитрий Фамин:

– 2016–2017 елларның көз-кыш шартларында компаниянең эшкә әзерлеген РФ Энергетика министрлыгы комиссиясе тикшерде, әзерлек паспортын алдык. Линияләрдә бозлавык куркынычы буенча шуны әйтә алам: 2010 елның декабрендәге «бозлы яңгырдан» килеп чыккан гадәттән тыш хәлдән соң без тиешле нәтиҗәләр ясадык. Хәтерләсәгез, ул чакта безнең бригадалар подрядчылар белән бергә 10 тәүлек дәвамында зыян килгән йөзләрчә километрлы электр тапшыру линияләрен торгызган иде. Шуннан соң без югары хәвефләр режимында эш регламентларын расладык. Авария-торгызу эшләрен үткәрү турында подрядчы оешмалар белән килешүләр имзаланды. Материаллар, җиһазлар, баганаларның авария запаслары булдырылды. Аварияләрне булдырмау һәм бәла-казалардан соң торгызу эшләрендә үзара хезмәттәшлек турында Федераль Челтәр компания, «Башкирэнерго» ҖЧҖ белән килешүләр төзелде, шул исәптән авария запаслары һәм аларның номенклатурасы турында мәгълүматлар тапшырылды.

– «Узып китеп» эшләү сезнең өчен инде күптән традиция түгел, бәлки стратегия. Профильләрне үзгәртү һәм квалификацияне күтәрү программаларының интенсив үсеше дә стратегик юнәлешме?

Дмитрий Шаповалов:

– Компаниядә ел саен персоналны кабат укыту һәм квалификациясен күтәрүгә шактый акча тотыла, подрядчылардан да «тонуста» булуларын таләп итәбез, сатып алулар стадиясендә үк подрядчының тиешле квалификация белешмәләренә ия квалификацияле персоналы булуына игътибар бирәбез. Җиһаз җитештерүчеләр белән эшче һәм белгечләрне практик эш күнекмәләренә өйрәтү буенча «үзебезнең территориядә» семинарлар оештырабыз.

Безнең стратегик максатларны күздә тотуыбыз да дөрес. Мәсәлән, 2014 елдан бирле үзебезнең электромонтерларны көчәнеш астында эшләү методларына өйрәтәбез. Хәзерге моментта бригадаларны җиһазландыру һәм комплектацияләү, практик күнекмәләргә өйрәтү чыгымлы нәрсә, электр бирүне туктатып башкарыла торган классик методка караганда, эшләр күбрәк хезмәт куюны таләп итә. Әмма без, клиентлар мәнфәгатен кайгыртучы компания буларак, кулланучыларыбызның уңайлылыгы әлеге чыгымнардан өстенрәк, дип саныйбыз. Һәм әгәр Россия Европа илләре мисалында кулланучыларны электр челтәреннән өзгән өчен штраф салуны законлаштырса, без инде моңа әзер булачакбыз.

– Россиядәге энергетика җиһазлары базары тармак ихтыяҗлары артыннан өлгерәме?

Дмитрий Шаповалов:

– Россия җиһазларының 80 процентка якыны чит илдәге аналогларына тәңгәл килә. Тик менә, мәсәлән, көчәнешнең югары классларына үлчәгеч трансформаторларны, 110 кВ лы һәм югарырак көчәнешкә махсуслаштырып тегелгән полиэтиленнан кабель муфталарын әле бездә җитештерергә өйрәнмәделәр. Хәзер без тагын бер нәрсәне ачыкладык – Россиядә бер генә тәэмин итүче дә безгә көчәнеш астында эшләр өчен кирәкле машиналар, кораллар һәм саклану чараларын җитештерми икән.

Дмитрий Фамин:

– Ягъни катлаулылык шунда – көчәнеш астында эшләү юнәлешендә без Россиядә әлегә бердәнбер компания. Әйтик, кирәкле махсус техника җитештерү өчен прототиплар, тәҗрибә җитештерүе кирәк. Шунлыктан без көчәнеш астында эшләгәндә кулланыла торган вышкаларны хәзер АКШ та сатып алабыз. Аннан вышкаларның комплектацияләрен алып кайтып, аларны КАМАЗда әзерләнгән шассига урнаштырырга планлаштырабыз. Пионер булу җиңел түгел, әмма безнең тармак авангардында буласыбыз килә. Башка компанияләрнең безгә тәҗрибә уртаклашу өчен елдан-ел күбрәк мөрәҗәгать итүе позициябезнең дөреслеген раслый. Безнең тәҗрибә – уникаль ул.

СЫЙФАТ БИЛГЕСЕ

«Сыйфат билгесе» проекты кысаларында «Татарстан» журналы дәрәҗәле премияләрнең җиңүчеләре һәм дипломантлары булган иң яхшы предприятиеләр, иң яхшы җитәкчеләр, иң яхшы товарлар һәм хезмәтләр турында сөйләвен дәвам иттерә.

«Россиянең иң яхшы 100 товары» Бөтенроссия бәйгесе

Бәйге ел саен менә 19 ел рәттән уздырыла инде. Ул РФ Дәүләт стандартлаштыру һәм метрология комитеты, «Сыйфат проблемалары академиясе» Төбәкара иҗтимагый оешмасы һәм «Стандартлар һәм сыйфат» журналы редакциясе, Росстандарт ведомствосына караган оешмалар – стандартлаштыру һәм метрология үзәкләре тарафыннан оештырыла. Россиядә барлыгы шундый йөз үзәк бар. Алар метрология, стандартлаштыру һәм сынау эшләре белән шөгыльләнә, бу исә турыдан-туры товарларның, эшләр һәм хезмәтләрнең сыйфатына һәм куркынычсызлыгына йогынты ясый. Үзәкләр санына карап, бәйге дә «Россиянең иң яхшы 100 товары» дигән исем алды.

Узган еллар эчендә ул үзәктә һәм төбәкләрдә уздырыла торган шуңа охшаш бәйгеләр арасында югалып калмады гына түгел, ә үз йөзен дә булдырды. Төп бурычын тулысынча үти ул – предприятие һәм оешмаларны Россиядә җитештерелгән продукция һәм хезмәт күрсәтүнең сыйфатын һәм көндәшлеккә сәләтлелеген күтәрүгә этәргеч бирә, шул ук вакытта Росстандартның территориаль бүлекчәләрен генә түгел, ә төбәкләрдә дәүләт идарәсе органнарын, контрольдә тотучы һәм иҗтимагый оешмаларны, массакүләм мәгълүмат чараларын һәм гади кулланучыларны дә җәлеп итә.

«Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәт күрсәтүләре» республика бәйгесе

«Россиянең иң яхшы 100 товары» Программасының төбәктәге бер этабы сыйфатында 13 нче ел рәттән уздырыла – бу исә аның дәрәҗәсе һәм абруе турында сөйли. Шушы вакыт эчендә бәйгедә дүрт меңгә якын товар һәм хезмәт күрсәтү төре катнашты. Лауреат исеменә 1300дән артык катнашучы лаек булды.

2016 елда 203 предприятиедән 447 товар һәм хезмәт күрсәтү төре катнашты. Шуларның 83е лауреат, 300 дән артыгы дипломга лаек булды. «Россиянең иң яхшы 100 товары» бәйгесенең федераль дәрәҗәдәге этабында Татарстаннан катнашкан 177 продукция һәм хезмәт күрсәтү төренең 59ы лауреат исеме алды.

Бәйге нәтиҗәләре буенча республикада импортны алыштыру эше актив рәвештә һәм уңышлы итеп алып барыла, инновацияле проектлар гамәлгә кертелә, югары сыйфатлы продукциянең яңа төрләрен җитештерү үзләштерелә, кирәкле хезмәтләр күрсәтү өлкәсе үсеш ала.

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат премиясе

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат премиясе – ачык бәйге. Бу анда Россия Федерациясенең башка төбәкләреннән компанияләргә дә катнашу хокукы бирә.

Быел бәйге ике номинациядә уздырыла: «Эшлекле камиллек» һәм «Җитештерү системалары». «Эшлекле камиллек» номинациясендә катнашучылар Россия Федерациясе Хөкүмәте премиясе критерийларына, шулай ук Европа сыйфат менеджменты фонды (EFQM) тарафыннан оештырылган Европа сыйфат өлкәсендәге премия критерийларына нигезләнеп бәяләнә. «Җитештерү системалары» номинациясе сакчыл җитештерү принципларына нигезләнә. Премия ел саен бәйге нигезендә предприятие һәм оешмаларга продукция һәм хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын күтәрү, аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү, шулай ук идарә итүдә югары нәтиҗәле ысуллар куллануда зур уңышларга ирешкән өчен бирелә.

ТР ХӨКҮМӘТЕНЕҢ СЫЙФАТ ПРЕМИЯСЕ

XII РЕСПУБЛИКА БӘЙГЕСЕ ҖИҢҮЧЕЛӘРЕН БҮЛӘКЛӘҮ ТАНТАНАСЫ

Судан уңга: Максим Протасов, «Россия сыйфат системасы» АКБО җитәкчесе, Илдар Халиков, ТР Премьер-министры, Альберт Кәримов, ТР Премьер-министры урынбасары – ТР сәнәгать һәм сәүдә министры.

2016 ЕЛДА ТР ХӨКҮМӘТЕНЕҢ СЫЙФАТ ПРЕМИЯСЕ БӘЙГЕСЕНЕҢ «ЭШЛЕКЛЕ КАМИЛЛЕК» НОМИНАЦИЯСЕНДӘ СОВЕТ КАРАРЫ БУЕНЧА ҖИҢҮЧЕЛӘР БУЛЫП ТАНЫЛДЫЛАР:

Михаил Швецов, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖнең Бөгелмә механика заводы директоры, Бөгелмә шәһәре



Леонид Анисимов, «Грань» ҖЧҖнең генераль директоры, Казан шәһәре

СОВЕТ КАРАРЫ БУЕНЧА, «ҖИТЕШТЕРҮ СИСТЕМАЛАРЫ» НОМИНАЦИЯСЕ ДИПЛОМАНТЛАРЫНЫҢ БЕРСЕ БУЛЫП ТОРА:

Әнвәр Яруллин, «ТМС групп» ҖЧҖнең Идарәче компаниясе директоры

СОВЕТ КАРАРЫ БУЕНЧА «ЭШЛЕКЛЕ КАМИЛЛЕК» НОМИНАЦИЯСЕ ДИПЛОМАНТЛАРЫНЫҢ БЕРСЕ БУЛЫП ТОРА:

Николай Курчаткин, «Авангард» ҖЧҖнең генераль директоры

PRESSA.RU

«КВАРТ» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕНДӘГЕ ЭНЕРГЕТИКА МЕНЕДЖМЕНТЫ СИСТЕМАСЫ

«КВАРТ» АҖ Россиядә резина-техника тармагы предприятиеләре арасында иң эреләрдән санала. Һәм 7000нән артык төрдә продукция чыгара. 2017 елның гыйнварында заводның 75 яшьлек зур юбилее!

Рафаэль Галимов,
«КВАРТ» АҖ генераль директоры.

Резина катнашмалар җитештерү линиясе.

75 ел дәвамында предприятиедә җитештерү технологиясе даими рәвештә камилләшеп тора. Ел саен энергетика чыгымнарын киметү буенча чаралар күрелә. 2004 елдан 2016 елга кадәр түбәндәгеләрне исәпләп уза алабыз:

1. Технологик җиһазларны техник су белән суыту системасы йомык циклда башкарылган. Кирәкле температураны тотып тору артезиан суы ярдәмендә тормышка ашырыла. Яңа җиһазлар куелган үзгәртеп корылган цехларда җирле суыту җайланмалары (чиллерлар) куела.

2. Җитештерүне кысылган газ белән тәэмин итүне децентрализацияләү тормышка ашырыла. Һәр җитештерү цехына һава белән суытыла торган винтлы компрессор җайланмалары эзләп табып урнаштырыла. Җылыту чорында компрессор җайланмасыннан җибәрелә торган җылылык биналарны җылыту өчен өстәмә чыганак булып тора.

3. Җылыту вакытында пар кулланучы җиһаздан җибәрелә торган конденсат суны җылыту өчен кулланыла, аннан соң ул Казан ТЭЦ-1 гә әйләнеп кайта. Тышкы һаваның температурасы түбәнрәк булганда суны җылыту өчен турыдан-туры пар бәрдерә торган УМПЭУ пар-инжектор корылмасы кулланыла.

4. Исәпкә алу, тикшерү һәм анализ өчен барлык цехларда да су, электр һәм җылылык энергиясе счетчиклары куела.

6. Җылылык энергиясен нәтиҗәле файдалану өчен барлык пар кулланучы җиһазларга да конденсатны читкә җибәрүче җайланмалар куела.

7. Энергия саклый торган яктырткычлар кулланып, эчке һәм тышкы яктырту системасын яңарту буенча эш алып барыла.

Күрелгән чаралар белән бәйле рәвештә соңгы ун ел эчендә еллык су чыгымы 414,0 мең $м^3$дан 116,3 мең $м^3$га кадәр, җылылык энергиясе 54,827 мең Гкал дан 35,713 мең Гкал га кадәр, электр энергиясе 17442,4 мең кВт сәгатьтән 13028,9 мең кВт сәгатькә кадәр кимеде, бу 36,7 млн сум акчаны янга калдырырга мөмкинлек бирде. Ягулык-энергетика ресурсларына бәяләрнең даими артып торуы шартларында энергия куллану белән тотрыклы идарә өчен җиһазлар алу һәм аларны модернизацияләү белән бәйле чаралар җитәрлек түгел. Энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өчен ISO 50001 стандарты нигезендә энергия файдалану һәм куллану системасын эшләү зарури. Энергетика менеджменты системасын кертү һәм аны эшли торган хәлдә тоту – предприятиенең иң мөһим бурычларыннан берсе. Системаны кертүнең төп максаты – предприятие җитештергән товар продукциясенең үзкыйммәтендә энергия чыгымнарын киметү. Энергетика чыгымнарын кыскарту максатыннан ЮНИДО Халыкара сәнәгать хезмәттәшлеге үзәге белән берлектә 2015 елның февраленнән энергетика менеджменты системасын кертү башланды. ЮНИДО җитәкчелегендә «КВАРТ» АҖ белгечләре эшләгән программа буенча системаны кертү этаплап башкарылды. Проектның бурычы – чыгымсыз һәм аз чыгымлы чаралар ярдәмендә энергия ресурсларын (электр энергиясе, җылылык энергиясе, су) куллануны киметү максатыннан энергия куллану белән тотрыклы идарә итәргә өйрәтү.

Реклама



1 нче рәсем. «ОГЭ» программасы.

Системалы юл иң яхшы халыкара тәҗрибәгә һәм ISO 50001 энергия менеджменты буенча халыкара стандарт таләпләренә нигезләнә. ЮНИДО методологиясе буенча су, электр һәм җылылык энергиясен куллануга анализ ярдәмендә, җитештерүнең технологик процессы үзенчәлекләрен исәпкә алып, бөтен предприятие буенча да, шулай ук һәрбер цех буенча да аерым энергия ресурслары чыгымына тәэсир итүче факторлар ачыклана. Энергия ресурслары чыгымына йогынты ясаучы төп факторлар булып түбәндәгеләр тора: электр энергиясе буенча – эшкәртелгән чимал микъдары, файдаланылган вакыт, көн озынлыгының дәвамлылыгы, тышкы һава температурасы; җылылык энергиясе буенча – тышкы һава температурасы, чимал чыгымы, су буенча – тышкы һава температурасы, эш вакытының исәбе һәм озынлыгы.

Энергетика менеджменты системасын кертү өчен түбәндәге эшләр башкарылды:

1. Энергетика сәясәте эшләнде, кертелде һәм эшли торган хәлендә тотыла.

2. Җитәкчелек вәкиле билгеләнде һәм ЭнМС (энергетика менеджменты системасы) буенча эшче төркем төзелде.

3. Энергия системасында катнашучыларның барысы да һәр аерым катнашучының бурычы билгеләнгән һәм расланган «рольләр һәм җаваплылыклар» таблицасы белән таныштырылды.

4. Предприятие белән автоматлаштырылган идарә итү системасы бүлеге (ОАСУП) инженерлары тарафыннан көн саен энергия ресурсларын (пар, электр энергиясе, су) исәпкә алырга, анализларга һәм тикшерергә мөмкинлек бирә торган «ОГЭ» программасы (1 нче рәсем) эшләнде.

5. Һәрбер технология линиясе буенча көндәлек рәвештә анализ алып барыла торган әһәмиятле энергетика кулланучылары ачыкланды.

6. Һәр цех буенча электр һәм җылылык энергиясе чыгымына тәэсир итә торган факторлар ачыкланды.

7. Ай саен баш инженер тарафыннан киңәшмә уздырыла. Биредә һәр цех җитәкчесе ай дәвамында эшләнгән һәм планлаштырылган эш һәм энергия саклау буенча ирешелгән нәтиҗәләр турында мәгълүмат бирә (2 нче рәсем). Әлеге системаны кертү предприятиегә 2015 елда:

– җылылык энергиясен – 961,2 мең сумга 712 Гкал не;

– электр энергиясен – 2014,0 мең сумга сәгатенә 136,0 т. кВт ны;

– суны – 617,9 мең сумга 31,4 мең м^3 ны янга калдырырга мөмкинлек бирде.

Барлыгы 3593,1 мең сум янга калдырылды.

2016 елның 10 ае эчендә:

– җылылык энергиясе – 4951,2 мең сумга 4569 Гкал не;

– электр энергиясе – 2426,1 мең сумга сәгатенә 709,8 мең кВт ны;

– су – 387,3 мең сумга 25,2 мең м^3 ны янга калдырылды.

Барлыгы 7764,6 мең сум экономияләнде.

2 нче рәсем. «Кварт» АҖндә энергетика менеджменты системасы схемасы (планлаштыру – башкару – тикшерү – гамәл).

Әйләнешле су белән тәэмин итү системасы.

PRESSA.RU

ЮГАЛТУЛАРСЫЗ БУЛГАН ЮГАРЫ СЫЙФАТ

Узган гасырның 50–60нчы елларында СССРда Урал–Идел буе нефть чыга торган урыннар актив эшкәртелде, нефть һәм газ таба торган предприятиеләр булдырылды, нефть-химия комплекслары, газ эшкәртү заводлары төзелде. Ул вакытларда төзелгән газ эшкәртүче заводларның күбесе бүгенге көндә дә уңышлы эшли. Әмма бик сирәкләре генә, составына хәзер Миңнебай газ эшкәртү заводы да кергән В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖнең «Татнефтегазпереработка» идарәсе (ТНГПИ) кебек, елдан-ел яхшыра баручы күрсәткечләргә ирешә ала.

– Бүген, газ эшкәртү заводының 60 еллык юбилее алдыннан, идарә хөрмәткә лаек нәтиҗәләргә иреште. Иярчен нефть газын (ИНГ) файдалы кулланунын коэффициенты 2016 елда «Татнефть» буенча 96% тан артыграк булды, бу – Россия нефть табу компанияләре арасында иң яхшы күрсәткечләрнең берсе. Узган елда соңгы 20 ел эчендә ИНГ җыюның максималь дәрәҗәсенә ирешелде – 899,5 млн кубометрдан артык газ чыгарылды.

Бүген без, моннан 20 ел элеккеге белән чагыштырганда, 223 млн кубка артыграк газны эшкәртүгә тапшырабыз, – дип сөйли идарә башлыгы Илшат Шәрипов. – Мондый нәтиҗәләргә ирешү өчен идарәнең үз территориясендә чималны эшкәртүнең тулы циклын башкарырга һәм чималны табу, транспортлау һәм эшкәртү вакытында югалтуларны кыскартырга мөмкинлек бирә торган югары үсешкә ия инфраструктурасы бар.

Бу инфраструктураның нигезе 60нчы елларда ук салынган. 1956 елда Миңнебай мәйданында нефть скважиналарыннан ИНГ эшкәртү продукциясенең беренче партиясе алынган Миңнебай газ-бензин заводы хәзерге вакытта яңа үсеш этабын кичерә. Бүген предприятие «Татнефть» нефть компаниясенең 84 чыганагыннан ИНГ җыю һәм эшкәртүне тормышка ашыра. Газ җыю системасы һәм нефтьне комплекслы әзерләү вакытында алына торган продукт – җиңел углеводородларның киң фракциясе составына республиканың көньяк-көнчыгышындагы алты газ цехы, шулай ук сыек углеводородларны җыю, транспортлау һәм саклау цехы керә. Газүткәргечләрнең озынлыгы 2 мең километрдан артыграк, продукт үткәргечләрнеке – 360 мең км.

2010 елда ТНГПИ коры бензиннан арындырылган газны тирәнтен эшкәртү буенча Россиядә бердәнбер криоген җайланмасын эксплуатациягә кертте. Әлеге җайланма балласт газ азотны чыгарырга, ИНГнан максатчан компонентларның максималь микъдарын алырга мөмкинлек бирә һәм Татарстан өчен стратегик чимал булган этанны эшләп чыгаруны арттыра. Идарә составына керә торган производстволарның техник җиһазланышы газ эшкәртүнең югары сыйфаты белән һичшиксез аерылып торган продуктларының бөтен төрен чыгарырга мөмкинлек бирә.

– Бүген без сыегайтылган газлар (пропан, бутаннар) фракцияләрен, бензинлы фракцияләрне, газсыман этан, коры бензиннан арындырылган газны, техник (газ) күкертен җитештерәбез, – дип сөйли Илшат Шәрипов. – Әлеге яңа фракцияне «Казаноргсинтез»га, сыеклаштырылган углеводород һәм стабиль газ бензинын – Россия, якын һәм ерак чит ил предприятиеләренә, коры бензиннан арындырылган газны – Татарстан һәм якында урнашкан регионнарга җибәрәбез. Күкертне Россиянең иң олы химия предприятиеләренең берсе булган Л.Я.Карпов исемендәге химия заводына озатабыз. Болардан тыш, газсыман кислород һәм азот җитештерәбез. Без аларны үз ихтыяҗыбызга тотабыз һәм кулланучыларга сатабыз. ТНГПИ продукциясенең югары сыйфаты төрле региональ һәм федераль бәйгеләрендә алынган бүләкләр белән даими расланып тора. Быел ПА, ПБА, ПТ, ПБТ, БТ маркалы углеводородлы сыегайтылган ягулык газлары «Россиянең иң яхшы 100 товары» бәйгесенең «Җитештерү-техник билгеләнешендәге продукция» номинациясендә җиңү яулады. Шул ук номинациядә предприятие тагын бер продукциясе – коммуналь-көнкүреш кулланышы өчен углеводородлы сыегайтылган газлар өчен дә диплом алды.

– Газ ягулыгы кулланунын төп критерие – анда химик кушылмаларның булмавы, туклыклылыгын һәм составын тәэмин итү һәм ГОСТ таләпләренә тулысынча туры килү. Әлеге күрсәткеч күбесенчә беренчел чималның составына бәйле, ләкин иң сыйфатлы газ да чистарту һәм эшкәртүнең күп баскычлы системасын үтәргә тиеш. Бездә ул гамәлдә камиллеккә җиткерелгән, – дип сөйли углеводород чималын эшкәртү буенча идарә җитәкчесе Җәүдәт Сәйяров. – Безнең идарә даими рәвештә алга бара. Бүген без газүткәргечләр төзибез һәм сепарациянең яңа пунктларын

Реклама

«ГФУ – 300».

газ җыю системасына тоташтырабыз, газ кулланучы җайланмаларны нефтьле газдан табигый газга күчерәбез, күкертле водородтан күкерт алуның яңа технологияләрен һәм компрессорлы станцияләр торбаүткәргеченнән газ рециркуляцияләү системасын кертәбез. Иярчен нефть газын әзерләү объектларын техник яктан яңадан җиһазлау һәм реконструкцияләү нәтиҗәсендә соңгы 14 ел эчендә идарә аны җыю күләмнәрен 28,3%ка арттырды (елына 203,0 млн куб. м). Югары күкертле карбон нефтьләрен чыгару, югары күкертле нефть газын утилләштерү һәм җитештерүдә аны максималь дәрәҗәдә куллану белән бәйле булган техник, экологик мәсьәләләр комплексы чишелде. Нефть газын факелларда яндыруны бетереп, җир асты һәм җир өсте суларының чисталыгын, җир ресурсларын саклап, «Татнефтегазпереработка» идарәсе лаеклы рәвештә табигатьне саклаучы предприятиенең төбәк статусына ия.

– Безнеке кебек шундый масштаблы һәм югары технологияле комплексның нәтиҗәле эшчәнлеге квалификацияле белгечләрдән башка мөмкин түгел. Гаять тирән белемгә ия, үз эшенең остасы булган кешеләр – безнең иң кыйммәтле ресурсыбыз, – дип билгеләп үтте Илшат Шәрипов. – Шунысы куанычлы: безнең хезмәткәрләр арасында күбесе яшь белгечләр. Аларның шактые – 50–60нчы елларда беренче газ җыю һәм газ эшкәртү объектларында эшли башлаганнарның балалары һәм оныклары. Традицияләргә тугрылык, буыннар алмашы, фәнни-тикшеренү, инновация эшчәнлеге һәм технологик базаны даими камилләштерү, процесслар нәтиҗәлелеген тәэмин итү һәм җитештерү куркынычсызлыгын көчәйтү – безнең компаниянең, аның бүгенге һәм киләчәктәге уңышларының нигезе шушылар.

УТНГП-2016 һөнәри осталык конкурсында җиңүчеләр.

PRESSA.RU

ЭНЕРГИЯ БЕЛӘН ТОТРЫКЛЫ ТӘЭМИН ИТҮ – ҖИТЕШТЕРҮНЕҢ НИГЕЗЕ

Әлеге сүзләр территориясендә җитештерү һәм эшкәртү тармакларының гигант предприятиеләре эшли торган Татарстан Республикасы өчен аеруча актуаль. Бу предприятиеләрнең күбесендә комплекслы энергетика сервисын тәэмин итү белән «ТаграС-ЭнергоСервис» ҖЧҖ белгечләре шөгыльләнә.

«ТаграС-ЭнергоСервис» ҖЧҖ – Татарстан Республикасының энергетика тармагында эшли торган иң эре предприятиеләрнең берсе. Компаниянең төп ресурслары – ул 30 еллык эш тәҗрибәсе, фәнни-техник инновацияләр һәм квалификацияле белгечләр. Оешма коллективында 2 меңнән артык хезмәткәр исәпләнә.

Татарстан Республикасының барлык нефть регионнарында энергетика объектларын төзи һәм ремонтлый, аларга хезмәт күрсәтә торган сервис бүлекчәләре булдырылган. Алар заманча техника белән җиһазландырылган һәм энергетика буенча башыннан алып азагына кадәр ремонтлау комплексының төрле хезмәтен, шул исәптән металл конструкцияләрен һәм электротехник эшләнмәләрне эшләп чыгаруны да тормышка ашырырга әзер.

«Татнефть» компанияләр берлеге һәм кече нефть табу компанияләре белән даими хезмәттәшлек итүдән тыш, «ТаграС-ЭнергоСервис» ҖЧҖ планлы рәвештә үз хезмәт тармагын киңәйтү буенча эш алып бара. Нәтиҗәсе – «Транснефть» АК» ААҖ, «Бердәм энергетика системасы» Федераль челтәр компаниясе» ААҖ, «Тепло Тюмени» АҖ, «Ямалкоммунэнерго» АҖ, «ЮКОЛА-нефть» ҖЧҖ, «Белкамнефть» АҖ, Пермь краендагы Суд департаменты идарәсе һәм Россия Федерациясенең башка предприятиеләре объектларындагы проектларны тормышка ашыру.

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Сыйфат өчен» премиясен яулау өчен үткәрелгән бәйгедә компаниянең әле бу көннәрдә генә региональ диплом белән билгеләп үтелгән уңышлары өч төп факторга нигезләнә. Беренчесе – энергетика җиһазына хезмәт күрсәтү һәм ремонтлауга комплекслы якын килү («бер тәрәзә» принцибы). Икенчесе – компаниянең сервис бүлекчәләренең Татарстан Республикасындагы барлык нефть табу регионнарында да урнашуы. Өченчесе – аларның һәрберсендә хезмәтләрнең (проектлау, диагностика, хезмәт күрсәтү, энергетика объектын төзү, ремонтлау һәм эксплуатациягә тапшыру, шулай ук электротехник эшләнмәләрнең металл конструкцияләрен әзерләү) тулы җыелмасы туплану.

Энергетик яктан нәтиҗәле комплекслы карарларның мөһимлеге, шулай ук «ТаграС-ЭнергоСервис» ҖЧҖндә импортны алыштыру юнәлешен үстерү үзләренең электротехник продукциясен җитештерү күләмен арттыруга китерде. Бүген предприятие 13 мең берәмлектән артыграк җиһаз, шул исәптән комплектлы трансформатор подстанцияләре шкафлары, идарә станцияләре (ешлыклы-көйләнә торган электроприводлы станцияләрне дә кертеп), траверслар, 6 (10) киловольтлы саклагычлар, светодиодлы яктырткычлар, баганалы комплектлы трансформаторлы подстанцияләр өчен конструкцияләр һ.б. эшләп чыгара.

«ТаграС-ЭнергоСервис» ҖЧҖ партнерларының географиясе, шуның белән бергә яңа технологияләр һәм хезмәт күрсәтүләр исемлеге дә даими киңәеп тора. Ә бу, үз чиратында, компаниягә нефть табучы һәм башка зур энергия сыешлы предприятиеләрнең электр һәм җылылык энергетикасы инфраструктурасын булдыру һәм үстерүдә актив катнашучы дигән дәрәҗәсен ныгытырга ярдәм итә.

Реклама

КАДРЛАРГА ИНВЕСТИЦИЯ ЯСАУ – ТАБЫШЛЫ ЭШ

Көндәшлеккә сәләтен саклау өчен теләсә кайсы предприятие югары технологияле стандартларга җавап бирергә, хәзерге заман техникасына, нәтиҗәле идарәгә ия булырга тиеш. Ләкин компаниянең уңышын һәм рентабельлелеген боларның барысын да үзләштерергә сәләтле булган квалификацияле кадрлар тәэмин итә. Бу бигрәк тә җитештерү тармагына кагыла.

2011 елдан башлап ел саен «Татнефть» ААҖнең Кадрлар әзерләү үзәге (КӘҮ) Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Сыйфат өчен» премиясе дипломанты була. Быелгы 2016 ел да искәрмә түгел. КӘҮ – яңадан конкурс лауреатлары исәбендә.

Үзәкнең тарихы сугыштан соңгы елларда башланып китә, бу вакытта Татарстанда эре нефть чыга торган урыннар ачылу белән бәйле рәвештә квалификацияле кадрларга ихтыяҗ туа. 1951 елда СССР нефть җитештерү министрлыгы боерыгы белән «Бораулау мастерлары, бораулаучылар һәм дизельчылар мәктәбе» (соңыннан Бораулаучы кадрлар мәктәбе) «Волгодонразведка» тресты составыннан «Татнефть» берләшмәсенә тапшырыла. Укытучылары, барлык җиһазлары һәм хәтта курсантлары белән бергә. «Татнефть» ААҖнең горурлыгы булган, югары дәүләт бүләкләре һәм мактаулы исемнәр яулап, предприятие, цех, бригада җитәкчеләренә кадәр үсә алган күп кенә ветераннар өчен Бораулаучы кадрлар мәктәбе чын тормыш һәм һөнәр академиясе булды.

Үзенең белем бирү эшчәнлеге алып барган елларында КӘҮ күптөрле үзгәртеп корулар, исем алмаштырулар һәм үзгәрешләрне кичерде. 2015 елның 10 декабреннән, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» федераль законы таләпләре буенча, «Татнефть-КӘҮ» дәүләтнеке булмаган белем бирү учреждениесенең атамасы «Татнефть-КӘҮ» Өстәмә һөнәри белем бирү шәхси мәгариф учреждениесе дип үзгәртелде. Әмма үзәкнең төп бурычлары элеккегечә калды. Бу – технологик җитештерүләр өчен эшчеләр өйрәтү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү; сәнәгать куркынычсызлыгы һәм хезмәтне саклау өлкәсендә предприятие һәм оешмаларның җитәкчеләрен һәм белгечләрен әзерләү һәм аттестацияләү. КӘҮ укытучылары белем бирү процессының өстенлекле якларын түбәндәгедә күрә: курс тыңлаучылар нефть сәнәгатенең барлык циклларында – бораулаудан башлап скважиналарны капиталь ремонтлауга кадәр – кулланыла торган материал һәм җиһазларда уку һәм практика узу мөмкинлегенә ия булырга тиеш. КӘҮнең барлык уку биналары да күрсәтмә әсбаплар, җиһазлар һәм инструментларның чын үрнәкләре белән җиһазландырылган. Җитештерү буенча дәресләр гамәлдәге заманча җиһаз урын алган укыту-җитештерү остаханәләрендә һәм укыту-өйрәтү полигоннарда алып барыла.

Болар барысы да бар яктан үсеш алган җитештерүнең заманча шартларына яраклашырга сәләтле белгеч тәрбияләргә ярдәм итә. «Татнефть-КӘҮ» ӨҺББ ШМУндә эшче һөнәрләргә өйрәнү өчен заманча җитештерү процесслары белән идарә итү каралган «табигый» пульт һәм постлар белән җиһазландырылган компьютерлаштырылган тренажер-имитаторлар кулланыла. Хәтта тавышлары да табигый ишетелә: бу укучылар хәтеренә технологик процессларны башкаруның психомотор күнекмәләрен сеңдереп калдыра.

Мониторда чагылыш таба торган параметрлар һәм процессларның барышы җитештерү буенча белем бирүче мастерга онлайн режимда укучылар алдына куелган бурычларның дөрес башкарылуын тикшерергә мөмкинлек бирә.

Тыңлаучылар җиһазларның принципиаль һәм технологик схемаларын укырга өйрәнсен, төп гамәлләрне этаплап эшләү күнекмәләрен үзләштерсен өчен, укытучылар компьютер программалары-симуляторлар куллана. Нефть хуҗалыгы, куркыныч булганга күрә, «җитештерү тармагында адаптация» төшенчәсен төшереп калдыруны таләп итә. Шуңа күрә, мисал өчен, авария ситуациясен китереп чыгарып, мастер шунда ук укучылар белән аны булдырмау буенча чаралар комплексын башкара. Укуның сыйфат дәрәҗәсен кулланучы билгели, диләр Кадрлар әзерләү үзәгендә. Тәкъдим ителгән хезмәтләрнең предприятиеләр тарафыннан куелган нигезле таләпләр белән ышанычларына туры килүен гарантияләп, белем бирүне максималь дәрәҗәдә җитештерү шартларына туры китерүгә басым ясыйлар. Кадрлар әзерләүгә тотылган акчаларны каплау мөмкин булсын, ә соңыннан алар икътисадый яктан нәтиҗә китерсен өчен дә.

Үзәк үз эшчәнлеген алып барган еллар дәвамында ТР һәм РФ нефть регионнары һәм чит ил компанияләре өчен 660 меңнән артык квалификацияле эшче һәм белгечләр әзерләп чыгара. Кадрлар әзерләү үзәге һөнәри һәм өстәмә белем бирү мәгариф программалары буенча укыту эшчәнлеген тормышка ашыру хокукы бирә торган ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының вакыты чикләнмәгән лицензиясенә ия.
Бүгенге көндә үзәкнең үзендә һәм аның Азнакай, Баулы, Бөгелмә, Җәлил, Алабуга, Лениногорск, Мактама һәм Нурлатта урнашкан сигез филиалында 273 һөнәр һәм 236 юнәлеш буенча белем бирү башкарыла.

«Татнефть-КӘҮ» ӨҺББ ШМУ турында тулырак мәгълүмат www.cpk.tatneft.ru сайтында.

Реклама

PRESSA.RU

«ТАТНЕФТЕПРОМ – ЗҮЗӘЙНЕФТЬ» АҖ: ИННОВАЦИЯЛӘРГӘ ЙӨЗ ТОТУ

Республикабызның нефть табу тармагына шактый өлешне кече нефть компанияләре дә кертә. Нефтьне рациональ, экологик рәвештә табуны оештыра торган кече нефть компанияләре рәтендә эшнең һәр этабында сыйфатка аерым игътибар бирә торган «Татнефтепром – Зүзәйнефть» АҖ компаниясе дә бар. Бу сүзләрне компаниянең 2016 елда ТР Хөкүмәтенең сыйфат өчен премиясенең «Эшлекле камиллек» номинациясендә лауреат булуы да тагын бер мәртәбә раслый.

Предприятие нефть сәнәгатендә Зүзәй чыганагында беренче нефть ятмалары табылганнан – 1986 елдан бирле эшли. Предприятие өчен соңгы еллар даими үсеш чоры булды. Бүгенге көндә ул авыр чыгарыла торган нефть ятмаларын чыгару һәм аларны эшкәртүдә махсуслашкан Татарстанның иң уңышлы нефть табучы компанияләрнең берсе булып тора. Предприятие ТР Нурлат районында урнашкан Зүзәй чыганагында нефть табу белән шөгыльләнә. Әлеге чыганакның үзенчәлеге шунда – биредә югары ябышкаклы запаслар тупланган.

НЕФТЬ ЧЫГАРУ МЕТОДЛАРЫН КАМИЛЛӘШТЕРЕП

Нефтьнең авыр чыгарыла торган запасларын табу – гаять катлаулы хезмәт, аның нәтиҗәләре беренче чиратта квалификацияле җитәкчеләккә һәм хезмәткәрләргә бәйле. Бер яктан, бу билгеле бер кыенлыклар белән бәйләнгән. Икенче яктан – алга барырга ярдәм итә. Бу исә җиңел юллар эзләүгә түгел, ә, нефть табу ысулларын камилләштерүгә игътибар биреп, процесска һәрьяклап якын килергә этәрә.

Компания горизонталь скважиналар һәм ян тармакларны бораулауда яхшы нәтиҗәләргә ирешә, бу скважиналарның дебитын арттырырга һәм үстерүгә кертелгән чараларның икътисадый нәтиҗәлелеген күтәрергә мөмкинлек бирде. Берьюлы аерым эксплуатацияләү (БАЭ) ысулы белән табу өчен җайланмалар да киң кулланыла һәм урнаштырыла. 2013 елдан актив рәвештә катламлы басымны тоту системасы гамәлгә кертелә.

ТАБУ – ӘЗЕРЛӘҮ – ТРАНСПОРТЛАУ

Компания эшчәнлеге эшләрнең тулы циклын колачлый – «Татнефтепром – Зүзәйнефть» АҖ составында нефть табу, әзерләү һәм суыртып агызу цехлары бар. Нефтьне әзерләү буенча цехта чимал дөнья стандартларына кадәр җиткерелә. Аннары нефть «Транснефть» АК магистраль нефть үткәргечләренә күчерелә. Шул ук вакытта Зүзәйнең нефтьне әзерләү һәм суыртып агызу егәрлеге башка компанияләр тарафыннан да сораула ия – ел саен алар аша миллион тоннага кадәр чимал уза. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, җитештерүнең барлык этаплары да диярлек – ә бу катлаулы технологик процесслар – реаль вакыт режимында тикшерелеп тора. Бу, үз чиратында, төрле тайпылышларга оператив рәвештә җавап кайтарырга мөмкинлек бирә.

ЭКОЛОГИЯНЕ КАЙГЫРТЫП

«Татнефтепром – Зүзәйнефть» АҖ эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләре рәтендә – әйләнә-тирә дөнья объектларына зыянлы тәэсир итү куркынычын киметү, җитештерүнең чисталыгын арттыру. Сүз уңаеннан, экологик куркынычсызлык – компания эшчәнлегенең мәҗбүри шарты. Расланган һәм хәзерге вакытта тормышка ашырыла торган экологик программа җир асты һәм өске суларны, туфрак һәм атмосфера һавасын даими рәвештә мониторинглауны үз эченә ала.

БЕР НЕФТЬ БЕЛӘН ГЕНӘ ТҮГЕЛ

Хәйриячелек эшчәнлеген дә истән чыгарырга ярамый. Компания җирле һәм республика берләшмәсенең социаль, мәдәни һәм спорт тормышында актив рәвештә катнашырга тырыша. Предприятие республиканың мәгариф, дини һәм башка учреждениеләренә, шулай ук фондларга, җирле администрацияләргә игәнә ярдәме күрсәтә.

«Татнефтепром – Зүзәйнефть» АҖ – социаль юнәлешле компания. Һәр нәрсәдән бары тик табыш алырга гына омтылуны биредә бөтенләй өнәмиләр. Соңгы елларда ирешелгән икътисадый үсеш дәрәҗәсе исә компаниягә югары мәдәниятле, экологик яктан имин, нәтиҗәле һәм хезмәт сыйфатына ия, үз хезмәткәрләренә социаль яклауны тәэмин иткән предприятие буларак, билгеләгән миссиясен башкарырга ярдәм итә торган базис булып тора.

Компания ирешкән уңышлар

- 2006 һәм 2007 елларда Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Сыйфат өчен» премияләре лауреаты.
- 2009 елда «Россия икътисады лидерлары» милли премиясе дипломанты.
- Финанс-икътисадый күрсәткечләр буенча товар һәм хезмәт сыйфаты Милли рейтингының «2016 елда Россиянең иң яхшы предприятиесе» мактаулы исеме иясе.
- «Бөтенроссия Бизнес-Рейтингы» сайлау нәтиҗәләре буенча «Чи нефть һәм иярчен газны табу» категориясендә «2016 елда Тармак лидеры» мактаулы исеме иясе.

Реклама

ЗУР БИЕКЛЕК КЕШЕЛӘРЕ

Менә инде 10 елдан артык Яр Чаллы шәһәренең «Монтаж «ЯЧКЗ» ҖЧҖ Татарстан, Россия, БДБ илләре һәм ерак чит илләрнең сәнәгать объектларында йөк күтәрү җиһазларын монтажлау һәм сафка бастыру-көйләү эшләрендә махсуслаша. Предприятиенең аеруча зур ихтыяҗга ия эшчәнлек юнәлешләреннән берсе – йөк күтәрү механизмнарын һәм кран юлларын ремонтлау, монтажлау һәм сафка бастыру-көйләү буенча хезмәтләр күрсәтү. Нәкъ шушы проектлар өчен «Монтаж «ЯКЧЗ» ҖЧҖ 2016 елда «Россиянең иң яхшы 100 товары» федераль конкурсы лауреаты исеменә лаек була да инде.

– Соңгы берничә ел эчендә йөк күтәрү техникасын җитештерүдә махсуслашучы Россия компанияләренең көндәшлеккә сәләтлелеге сизелерлек үсте. Шул ук вакытта кран җиһазларын ремонтлауга яки үзгәртеп коруга ихтыяҗ да саклана, – дип сөйли компания директоры Александр Швецов. – Ә без, үз чиратыбызда – проектны эшләүдән башлап, монтаж бригадасының эш урынына баруына кадәр – бу юнәлештәге хезмәтләрнең тулы спектрын күрсәтә алабыз.

Проектлау белән Яр Чаллыдагы конструкторлык бүлеге хезмәткәрләре шөгыльләнә. Әзерлек җитештерүе дә шушында ук урнашкан. Монтаж һәм сафка бастыру-көйләүне урынга барып эшләүче бригадалар башкара, андагы белгечләрнең аеруча куркыныч, техник яктан катлаулы һәм дәүләт серен эченә алган белешмәләрне куллануга бәйле проектларны да үз эченә алган уникаль объектларда эшләргә рөхсәтләре бар.

– Без базардагы өстенлекләргә клиентларга ориентлашкан мөнәсәбәт хисабына ирешәбез: безнең белгечләр объектларны зарури булганча бәялиләр һәм аннары заказчыга аеруча отышлы вариантны тәкъдим итәләр, – ди Александр Швецов. – Аны тормышка ашырганда, заказчы тиешле аңлатма һәм гарантия документациясен ала. Моннан тыш, үзебез ремонтлаган, монтажлаган яки яңартып корган техникага сервис хезмәте дә күрсәтә алабыз.

Компания базарда эшчәнлек алып барган 10 ел эчендә аның хезмәткәрләре Россия, Абхазия, Белоруссия, Казахстан, Төрекмәнстан предприятиеләрендә мең ярымнан артык уникаль объектны җыйган. Компаниянең агымдагы иң кызыклы проектларыннан берсе – Мисырдагы Евфрат ГЭСының кран хуҗалыгын үзгәртеп кору.

– Хезмәтне саклау нормаларын бозмауны, командировкада бригадаларның яхшы яшәү шартларын булдыруны, мобиль бригадаларны җиһазлар, эш кораллары, махсус киемнәр белән тәэмин итүне башыннан ахырынача башкарабыз. Бөтен җиһазларыбыз аттестацияләнгән, эш коралларын файдалану вакыты билгеләнгән, – дип сөйли «Монтаж «ЯЧКЗ» ҖЧҖ директоры. – Моннан тыш, без ел саен хезмәткәрләрне укыту һәм аттестацияләүгә акча бүләбез. Бу зарури, чөнки аларның – машина төзелешеннән башлап, тау эшләренә кадәр – сәнәгатьнең күп төрле өлкәләрендәге предприятиеләрендә эшләргә рөхсәтләре булырга тиеш. Югары технологияле сәнәгатьтә эшләү тәҗрибәсе ала торган яшьләрне үзебезгә вузлардан ук җәлеп итүгә зур игътибар бирәбез. Безнең коллективта уртача 30-40 яшьтәге хезмәткәрләр эшли.

Компаниянең статусы аның даими заказчыларының статусы белән дә раслана, алар арасында – «РТЮ» ААҖ, «ТАНЕКО» АҖ, «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ, «Автоваз» ААҖ, Казан вертолёт заводы, «Прогресс» Үзәк махсуслашкан конструкторлык бюросы, «Электрощит» Компанияләр төркеме (Самара), Курган кабель заводы, Технологик системалар һәм җиһазлар предприятиесе (Түбән Новгород өлкәсе), «РПС» АҖ елга порты (Сарапул), Төрекмәнабад тәҗрибә-ремонт предприятиесе һәм башка бик күпләр бар.

– Йөк күтәрү механизмнарын ремонтлау һәм яңартып корудан тыш та, без киң спектрда хезмәт күрсәтәбез, алар арасында – күтәрү корылмаларын монтажлау һәм сафка бастыру-көйләү (бу хезмәтләр быел шулай ук «Иң яхшы 100 товар һәм хезмәт күрсәтү» конкурсы дипломы белән бәяләнде), җир өстендәге һәм җирдән югарыдагы кран юлларын әзерләү һәм монтажлау, куркынычсызлык приборларын көйләү, төзәтү һәм сервис хезмәтен күрсәтү. Безнең предприятиенең Россия Су юлларының Елга регистры тарафыннан йөзмә краннарны ремонтлау һәм үзгәртеп кору эшләрен үткәрү таләпләренә туры килүен тануы турында таныклыгыбыз да бар. Без клиент таләпләренә ориентлашабыз, шуңа күрә безнең хезмәтләрнең исәбе даими рәвештә арта бара. Без яңа биеклекләрне яуларга һәрвакыт әзер, дип әйтергә мөмкин, – дип тәмамлады сүзен Александр Швецов сүзен шулай тәмамлый.

Реклама

PRESSA.RU

ХАЛИТ БИКМӨХӘММӘТОВ: – СӘНӘГАТЬ ТӨЗҮЧЕЛӘР ИЛЕБЕЗГӘ КИРӘК

«ВНЗМ АК» ГАҖ инде менә 60 елга якын нефть газ комплексында сәнәгать объектларын төзү белән шөгыльләнә. Еллык сораштыру нәтиҗәләре буенча, иң эре нефть-газ компания-заказчыларның берсе «Востокнефтезаводмонтаж» – «Нефть-газ эшкәртү объектларын төзү» номинациясендә беренчеләр рәтендә. Бүген тармактагы хәлләр турында «ВНЗМ АК» ГАҖ генераль директоры Халит БИКМӨХӘММӘТОВ сөйли.

Халит Габделсаматович, сез ике дистә елдан артык Хабаровскидан алып Кингисеппка кадәрге территориядә ил өчен бик мөһим булган сәнәгать объектларын төзи торган һәм коллективына биш мең кешене сыйдырган эре компанияне җитәклисез, Россиянең иң читтә урнашкан почмакларында буласыз. Сезнеңчә, хәзерге заман икътисадында төзүчеләр нинди урын алып тора?

– Россия төзүчеләре – иң киң таралган һөнәрләрнең берсенә карыйлар. Россия Төзелеш министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2015 ел азагына тармакта 1,8 млн га якын кеше эшләгән. Алар технологиясе буенча гаять катлаулы – аэрокосмиктан башлап, нефть химиясе өчен кирәк булган комплекслар, заманча уңайлы торак йортлар, социаль объектлар, юллар, күперләр дә төзиләр. «Сәнәгать» төзүчеләре, без дә алар исәбенә керәбез, сазлык, тундра, комлыклардагы төзелеш мәйданчыкларына килә. Авыр шартларда – эсседә һәм салкында – тир түгә, территорияне төзекләндерә, юллар сала, җитештерү өлкәләрен, соңыннан хезмәткәрләр белән тулачак офислар төзи. Ләкин, әлеге төзүчеләр булмаган да диярсең, алар җәмәгать игътибарыннан гадәттә читтә кала.

– Ник алай дисез?

– Әйтегез әле, ММЧ – басма матбугат, телевидение, электрон чаралар төзүчеләр турында еш сөйлиме? Ә бит ил буенча эре, күп очракта уникаль объектлар төзелә. Әмма телевидениенең барлык каналларында да популяр булган күпсанлы ток-шоуларда ни хакында сүз бара? Йолдызларның шәхси тормышы, җәнҗаллар, күп очракта сәләте шикле булган кешеләрнең үзара ярышы. Ә ни өчен әле үз эшенең остасы булган торак-йортлар, машина төзүчеләр, нефть эшкәртүчеләр, игенчеләр катнашында шоу оештырмаска?! Бүгенге көндә һәр темадан рейтинглы тапшыру ясарга була. Беләсездер, һәр һөнәрнең үз осталары бар! Һич арттырмыйча әйтәм, мәсәлән, монтажчының күз үлчәме – ул Ходай биргән сәләт.

Металлдан эшләнгән конструкция, күп тонналы колоннаны 100 метрлы биеклеккә нибары 2 мм тайпылыш белән урнаштыру – «Голос» лауреатының вокал буенча сәләтеннән дә уникальрәк булырга мөмкин...

Сүз уңаеннан шуны да әйтик: без мондый тапшыруны булдыруда катнашырга да әзербез. Аның күпләр өчен кызык, файдалы булуына һәм инициатив кешеләр, үз эшчәнлеген җитештерү тармагы белән бәйләргә тәвәккәлләгән кече эшкуарлык вәкилләренә көчләренә ышаныч бирәчәгенә иманым камил.

Һәм бу бер мәртәбә күрсәтеп үтә торган тапшыру гына булырга тиеш түгел. Кызыксынган тамашачы тапшыруның эфирга чыгарга тиешле көнен һәм сәгатен көтеп торырлык итеп әзерләргә кирәк аны.

Илдар Халиков, ТР Премьер-министры, һәм Владимир Рузанов, проект җитәкчесе – баш инженеры урынбасары «ВНЗМ АК» ГАҖ.

– Әмма мәсьәләнең чишелеше бит телетапшыруга гына бәйле түгелдер?

– Һичшиксез. Әмма хезмәт кешесенә карата мөнәсәбәтне үзгәртергә кирәк. Барлык дәрәҗәдә дә. Аерым алганда, илдәге һөнәри техник белем бирүне җимерү процессын туктатырга кирәк. Без балаларга кечкенәдән тормышка дөрес юнәлеш бирсәк һәм барлык тармакларны да хәзерге заманда бигрәк тә кирәк булган квалификацияләргә ия кадрлар белән тәэмин итсәк, ничек әйбәт булыр иде.

Реклама

Безнең искиткеч зур илебезнең иң мөһим мәсьәләләренең берсе – туучылар санының аз булуы. Ә бер төзелеш тармагында гына да – йөзләрчә мең нык егетләр һәм чая кызлар бит. Алар үзләренең алдагы көннәренә ышаныч белән карый ала икән, Россия киләчәге хакына балалар да тудырачак!

– Ә сезнең компания үзен хәзерге катлаулы икътисадый шартларда ничек саклап кала алды?

– ВНЗМ составында төрле профильдәге ике дистәдән артык предприятие эшләп килә. Кешеләргә ничек ярдәм итә алабыз? Тотрыклы эш, хезмәт хакы, төзелеш мәйданнарында тиешле көнкүреш шартлары белән. Һәрвакыт цивилизациянең барлык уңайлыкларыннан читтә булган төзелештә эшләүче төзүчебезнең шәһәрдәге заводта хезмәт итүче белән бер үк төрле шартларга ия булуы турында хыялллана идек. Хәзер объектларда барысы да бар – уңайлыклары булган яшәү шәһәрчекләре дә, сәламәтлек пунктлары да, профессиональ пешекчеләр эшли торган ашханәләр дә. Алар озак вакыт дәвамында үз өеннән аерылып торган кешеләрне бик тәмле аш-су белән сыйлый. Әмма әлеге барлык уңайлыклар булуына карамастан, командировканың 45–60 көне дәвамында төзүчегә иркен фатирдагы 12 квадрат метрлы мәйдандагы чикләнгән тирәлекне үзенең яраткан гаиләсе белән түгел, ә өч күрше белән бүлешергә туры килүен дә онытырга ярамый...

Безнең компания төзүчеләрнең квалификация дәрәҗәсенә катгый таләпләр куела торган эре объектларда эшли. Шуларга җавап бирергә тырышабыз. Агымдагы елдан башлап, Яңа Уренгой янындагы ике эре проектны тормышка ашырырга алындык. Безнең коллектив бик тәвәккәл: заказ барлыкка килдеме – җилкәгә рюкзагын аса да объектка таба юл ала.

Эшчәнлекнең яңа юнәлешләрен үзләштерәбез. Соңгы елларда Башкортостан – торак төзелеше темплары буенча алдынгылар рәтендә, һәм безнең компания әлеге юнәлешкә шулай ук үз өлешен кертә. Стәрлетамакта йортлар төзибез, республика башкаласының тарихи үзәгендә төзелешнең эшче проектын эшләүне алып барабыз.

Әңгәмәнең азагында тагын бер кат төп мәсьәләгә кайтасым килә әле. Төзү технологиясе буенча катлаулы булган нефть-газ эшкәртү объектларын торгызу төзүчеләрдән җитештерүне оештыру дәрәҗәсен даими рәвештә күтәрүне таләп итә. Проектлар белән идарә итү, мәйданнарда эшне оештыру, эретеп ябыштыру техникасын, йөк күтәрү механизмнарын, җиһазларны яңарту, техник документацияне җиренә җиткереп башкару, сыйфатны контрольдә тоту һәм башкалар – болар барысы да беренче планда.

Шуны ышанып әйтә алам, Россиянең төзүче-монтажлаучы компанияләре иң каттый заказчыларның таләпләрен дә канәгатьләндерә, моны чит ил белгечләре дә таный. Торак төзелеше алга таба шактый зур адым ясады. Нинди генә йортлар төзелми хәзер – искиткеч! Бу 60–80 нче еллардагы бер-берсенә охшаш биш катлы йортлар түгел инде!

Хәзерге заман төзүчесе ил икътисадында мөһим урын алып тора һәм аның хезмәт хакы күләме лаеклы булырга тиеш. Әмма, кызганычка каршы, төзелеш тармагында бәяләр билгеләү моны расламый. Объектка бәя куйган чакта заказчы, әлбәттә, аны, шул исәптән хезмәт хакы дәрәҗәсен, накладной буенча чыгымнар күләмен киметү һәм предприятиеләрне үстерү чараларын бөтенләй төшереп калдыру хисабына оптимальләштерергә тырыша. Биредә хуҗалык итә торган субъектлар арасында килеп туган бәхәс тә үзен сиздерә. Әмма аларның берсе эре структура булган очракта, икенчесен дәүләт якларга тиеш.

Төзелештә килеп туган хәлне тагын РФ Төзелеш министрлыгы тарафыннан билгеләп куелган накладной кәгазе буенча чыгымнарга киметелгән коэффициентлар да кискенләштерә. Хәзерге шартларда төзүчеләрнең накладной чыгымнары кискен рәвештә арта: төзелеш мәйданчыгында эшне оештыру, хезмәткәрләрнең эш урынына бару һәм кайтуын, анда торуын оештыруга, лизинг өчен чыгымнар, банк процентлары һәм башкалар. Нәтиҗәдә төзүчеләргә хәтта киметелгән коэффициенттан башка да (шул исәптән торак) накладной чыгымнарының билгеләнгән күләменә сыешып бетү мөмкин эш түгел. Ә киметә торган коэффициент исә төзүчеләрне тәмам зыянга эшләргә мәҗбүр итә.

Совет заманында шактый гына тармак төзелеш министрлыклары эшләп килгән: Монтажлау-махсус төзелеш министрлыгы, Сәнәгать төзелеше министрлыгы, Нефть-газ төзелеше министрлыгы... Төзелеш министрлыгы структурасында сәнәгать төзелеше мәсьәләләрен чишү белән шөгыльләнә торган хезмәт булдыру урынлы булыр иде.

Һәм тагын бер мәсьәлә. Россия Төзелеш министрлыгының төзелештә торак юнәлешен игътибар үзәгендә тотып, сәнәгать төзүчеләрен дә чит-ят итмичә – алар турында бәйрәм вакытында да онытмавын теләр идек. Илдәге торак төзелеше күләмнәрен берничә мәртәбә арттырырга кирәк. Һәм хәзер Россиядә халыкны торак белән тәэмин итү буенча алга киткән дәүләтләр дәрәҗәсенә ирешү өчен күп эш башкарыла.

Ә илнең яшәве, аның киләчәге икътисад дәрәҗәсе, оборонага сәләтлелеге белән билгеләнә. Моның өчен заводлар, фабрикалар, пароходлар төзергә, төзергә һәм төзергә кирәк.... Сәнәгать төзүчесе Россия өчен кирәк, бик кирәк.

PRESSA.RU

УРАЛ-ИДЕЛ БУЕ РФТҮ – ЕЛНЫҢ ИҢ ЯХШЫ СЫНАУ ЛАБОРАТОРИЯСЕ!*

Татарстанның Бөгелмә районында урнашкан Урал-Идел буе региональ фәнни-техник үзәге «Сыйфатлы продукция үсешенә керткән зур өлеше өчен» номинациясенең «ТР-2016ның иң яхшы сынау лабораториясе» кече номинациясендә җиңүче булды. «Урал-Идел буе региональ фәнни-техник үзәге» ҖЧҖ 2011 елда академик А. П. Крылов исемендәге «ВНИИнефть» ААҖнең Бөгелмә филиалы базасында оешкан.

XX гасырның 70нче еллар ахырында төзелгән Бөгелмә филиалының төп бурычы Татарстан Республикасындагы табигый битум ресурсларын актив эшкәртүгә кертү проблемаларын хәл итүдән гыйбарәт иде. Ә ахыргы максаты –Татарстанда нефть сәнәгатенә баш институтта уйлап табыла торган яңа, аеруча перспектив эшләнмәләрне карарга һәм гамәлгә кертергә сәләтле эре фәнни бүлекчә булдыру. Урал-Идел буе РФТҮ белгечләре тарафыннан табигый битум ятмаларын рентабельле эшкәртүнең төп принциплары нигезләнә. Хәзерге вакытта үзәк тарафыннан түбәндәге юнәлешләрдә хезмәтләр күрсәтелә: нефть һәм битум скважиналарын гидродинамик тикшерүләр; нефтьнең тирән һәм комбинацияләнмәгән үрнәкләрен сайлап алу; скважиналарны үзләштерү һәм свабирование ысулы белән скважина сыеклыгын чыгару; стандарт булмаган нефть промыселы җиһазларын проектлау һәм әзерләү. РФТҮнең активында нефть-газ сәнәгате өлкәсендә үз хезмәтләрен күрсәтүче дүрт фәнни-техник тикшерену лабораториясе һәм стандарт булмаган нефть җиһазлары әзерләүче эксперименталь-механик цех бар.

Әмма предприятиенең төп горурлыгы – Табигатьтән файдалануны экологик нормалаштыру һәм анализлау лабораториясе, ул «Татарстан Республикасының 2016 елгы иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» республика конкурсында «Татарстан Республикасының иң яхшы сынау лабораториясе» кече номинациясендә җиңүче дипломына ия булды. Бу турыда җентеклэбрәк сөйлик.

Лабораториянең төп эшчәнлеге катламлы флюидларның составын һәм үзенчәлекләрен тикшерүдән гыйбарәт. Аерым алганда, махсуслаштырылган урыннарда заманча җиһазлар ярдәмендә бер уңайдан табылучы газның күләмен, составын һәм үзенчәлекләрен, нефтьнең һәм бер уңайдан табылучы суның химик составын ачыклау үткәрелә.

Әлеге тикшеренүләр нефть ятмаларын эшкәрткәндә һәм углеводород запасларын исәплэгәндә нигез итеп алына, һәм шулай ук гамәлдәге нефть чыгу урыннарын эшкәртүне контрольдә тоту өчен актив кулланыла. Соңгы елларда скважина продукцияләре составын һәм үзенчәлекләрен тикшерүнең дөреслегенә аеруча катгый таләпләр куела. Персоналның югары квалификациясе, ачыклау методикаларын мәҗбүри үтәү һәм, әлбәттә, башкару дисциплинасы бу таләпләргә ярашу мөмкинлеген бирә.

Лаборатория соңгы биш елда ике тапкыр аккредитация процедураларын һәм ел саен Росаккредитация системасында компетентлыкка раслануларны үтте. Аккредитацияләнгән оешма статусы лабораториянең аккредитация критерийларына туры килүен гарантияли һәм сыйфат менеджменты системасының уңышлы эшләвен гарантияли.

Тикшеренүләрдән тыш, лаборатория хезмәткәрләре тарафыннан ачыклауларның яңа методикалары эшләнелә һәм гамәлгә кертелә, шушындый ук юнәлештәге лабораторияләргә консультацияләр үткәрелә. Моннан тыш, практикага нефть профилендәге вуз студентлары кабул ителә, ә бу югары квалификацияле кадрлар әзерләүне тәэмин итә.

Тәҗрибәле коллективка, перспективалы эшләнмәләргә таянып һәм динамик үсештәге предприятие буларак, «Урал-Идел буе РФТҮ» ҖЧҖ киләчәккә ышаныч белән карый!

Реклама

* «ТРның иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» конкурсы нәтиҗәләре буенча «Сыйфатлы продукция һәм хезмәт күрсәтүләрне үстерүгә зур өлеш керткән өчен» номинациясендә «ТРның иң яхшы сынау лабораториясе» кече номинациясендә.

ВАСИЛЬЕВО ПЫЯЛА ЗАВОДЫ: РОССИЯ БӘЯЛӘРЕ БЕЛӘН ДӨНЬЯ СЫЙФАТЫ

Россиядә үз тарихларын революциягә кадәрге вакытлардан алып килүче җитештерүләр әллә ни күп сакланмаган. Алар арасында үз куәтләрен саклап кына калмыйча, көндәшлеккә сәләтле һәм Россия үлчәмнәре буенча уникаль продукция тәкъдим итеп, үсешнең яңа баскычына чыга алганнары тагын да азрак. «Васильево пыяла заводы» АҖ Татарстан Республикасында шундый предприятиеләрнең берсе булып тора. Россиядә һәм чит илләрдә әлеге предприятие «VGP» сәүдә маркасы белән билгеле.

1945 елдан Васильево пыяла заводы химия, медицина, азык-төлек сәнәгатендә кулланыла торган термочыдам пыяла җитештерүдә махсуслаша. Хәзерге вакытта завод ризык пешерү, саклау һәм табын өчен термочыдам савыт-саба җитештерә.

Пыяла әйберләр җитештерү процессы – искитәрлек күренеш. Чималны эшкәрткәннән һәм шихтаны төзегәннән соң, пыяла массасын, безнеңчә әйткәндә, пешерү башлана. Утлы мичтән пыяла массасы тамчылап формаларга тапшырыла һәм пресслана, ут белән шомартыла, аннары яндыру мичендә озатыла. Зур хезмәт таләп иткән катлаулы һәм чын мәгънәсендә кайнар процесс.

Пыяла әйберләр җитештерүдә 240лап кеше эшли, күпчелеге – биредә яшәүчеләр. Шунысы игътибарга лаек, хәзер биредә төрле елларда шушы заводны төзегән, аякка бастырган кешеләрнең балалары, оныклары эшли. Алар – Корбановлар, Коньковлар, Гыйләҗевлар, Пикаловлар, Чеховлар һәм башка күпләрнең хезмәт династияләре вәкилләре.

Заводта җитештерелә торган продукция кулланучылар арасында тотрыклы ихтыяҗга ия. Чөнки предприятиенең продукциясе (кәстрүлләр, таба капкачлары, салат савытлары һ.б.) гигиеник яктан чиста, термик яктан чыдам. Үз илебезнең пыяла кайнатканда кулланыла торган сыйфатлы чималы ярдәмендә «VGP» сәүдә маркалы әйберләр төбәк һәм федераль дәрәҗәдәге конкурсларда һәрвакыт югары бәяләргә лаек була. Васильево предприятиесе продукциясе Россия Федерациясенең Табигать ресурслары һәм экология министрлыгы тарафыннан иң экологик һәм куркынычсыз товар дип танылган. Быел продукция төрләренең берсе (пешерү формалары җыелмасы) «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» конкурсының «Халык өчен сәнәгать товарлары» номинациясендә дипломант булган.

Шунысы сөенечле, предприятиенең яхшы уйланылган сату сәясәтенә бәйле рәвештә, Россия кулланучылары «VGP» сәүдә маркалы савыт-сабаны «Ашан», «Карусель», «Пятерочка», «ИКЕА», «Лента», «Эссен», «Магнит» һәм Россиянең башка шундый ук танылган эре челтәр кибетләрендә сатып ала алалар.

Хәер, товарларның тәкъдим ителү урыннары Россия белән генә чикләнми. Швеция, Швейцария, Польша, Германия, Япония, Нидерланд, Украина белән хезмәттәшлек итү җайга салынган. Бердәм Таможня союзы илләре – Белоруссия һәм Казахстан белән сәүдә элемтәләре эшләнгән.

– Без быел тагын бер перспективалы юнәлешне үзләштердек, – дип сөйли «Васильево пыяла заводы» АҖ генераль директоры Эдуард Ринатович Саттаров, – ризык пешерү өчен дүртпочмаклы формалар чыгарырга керештек. Ел ахырына кадәр яңа әйберләребезнең тагын дүрт төрен җибәрергә уйлыйбыз. Безнең өчен ассортимент сафын киңәйтү мөһим, химик-лаборатория савыт-сабасын җитештерүне яңарту планнарыбыз бар, әлек, кайбер сәбәпләр аркасында, ул чыгарылмый башлаган иде.

Заводның гомуми стратегиясе – Россия бәяләре белән дөнья дәрәҗәсендәге сыйфатлы савыт-саба. Без ышанычлы адымнар белән Европа базарына чыгарга өметләнәбез. Бу юнәлештә ТР Икътисад министрлыгы, анда Экспортка ярдәм итү үзәге кебек мөһим структура бар, һәм ТР Сәүдә-сәнәгать палатасы ярдәм итә. Монда сүз тышкы икътисадый эшчәнлек мәсьәләләре буенча киңәшләр турында да, чит илләрдәге потенциаль партнёрларга эшлекле миссияләр оештыру турында да, чит ил конференцияләрендә һәм башка чараларда безнең катнашуны оештырырга булышу турында да бара. Без ТР Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының ярдәмен дә бик югары бәялибез, асылда ул безнең предприятиегә шефлык итә.

Барлык серләрне дә ачып бетермибез, бары тик, җитәкче буларак, Эдуард Ринатовичның предприятие алга таба да уңышларга ирешсен өчен нәрсә эшләргә кирәклеге турында төгәл идеяләре барлыгын гына билгеләп үтәбез. Ул бүгенге көн чынбарлыгына яраклаша белә һәм агымдагы вазгыятьне ачык бәяли. Шунысын да өстик, заводның эшчәнлеге – ул әле Васильево халкының эш белән тәэмин ителеше, җирле бюджетка тотрыклы салым керемнәре дә, җирле халыкның сатып алу мөмкинлеге дә. Инде күптән Татарстан Республикасының танылган брендларыннан берсенә әверелгән бу күренекле предприятиенең киләчәктә дә үз аягында ышанычлы басып торачагына ихластан өметләнәсе килә, чөнки аның нигезе нык – гасырдан артык тарихы, традицияләре һәм белгечләре бар.

Васильево пыяла заводы җитәкчелегенең кыю планнары исәбендә – бөтен Европа базарын яулап алу. Уңышлар телик!

Реклама

PRESSA.RU

ЛЕНИНОГОРСК НЕФТЬ ТЕХНИКУМЫ ҺӨНӘРИ БЕЛЕМ БИРҮНЕҢ ДӘРӘҖӘСЕН КҮТӘРӘ

Сыйфатлы урта белем бирү елдан-ел зуррак популярлык казана. Лениногорск нефть техникумы – Татарстанда гына түгел, бөтен Россиядә нефть-газ табу сәнәгатенең әйдәп баручы белем бирү учреждениеләренең берсе. Ул, белем бирү хезмәтләре дәрәҗәсен туктаусыз камилләштерә һәм сыйфатын күтәрә барып, ихтыяҗга ия белгечләр әзерли. Бу профильле конкурслардагы күпсанлы җиңүләр белән дә раслана. Күптән түгел техникум ТР Хөкүмәтенең сыйфат өчен премиясе конкурсында дипломант булды.

Лениногорск нефть техникумы – нефть юнәлешендәге иң өлкән уку йортларының берсе. Техникум стеналарыннан аның бөтен тарихы дәвамында 22 000нән артык белгеч чыккан. Бүгенге көндә урта һөнәри белем бирү 10 төрле белгечлек буенча алып барыла, кыска вакытлы укытуның 30дан артык программасы тәкъдим ителә.

Биредә искиткеч традицияләр һәм тәҗрибә даими рәвештә камиллеккә ирешергә омтылу белән бәйләнгән. Техникумда күп нәрсәләр беренче тапкыр кулланыла. 2013 елдан техникумда Татарстанда бердәнбер булган бораулаучының эш урыны тренажёры һәм бораулау технологиясе буенча тренажёр классы эшли. Ә нефть промыселлары дисциплиналарын уку-укыту полигоны – Россиядә бердәнбер нефть табу, әзерләү, төяп җибәрүнең тулы циклын чагылдырган макет мәйданы.

Уку йорты, вакыт таләпләренә җавап бирү һәм үз-үзен сынау белән бергә, ирешелгәннәрдә туктап калмый. 2016 елда Лениногорск нефть техникумы ТР Хөкүмәтенең сыйфат өчен премиясе конкурсында катнашты.

Техникумның җитәкчесе Игорь Врублевский сөйләвенә караганда, конкурска үз материалларын тәкъдим иткән һәр оешма экспертлар төркеменең объектив бәясен алган. Үз хисабында техникум түбәндәге критерийлар буенча материаллар тәкъдим иткән: базарда ориентлашу, әйдәманлык, партнёрлыкны үстерү, кулланучылар һәм җәмгыять белән үзара бәйләнеш.

Конкурс өч этапта узган, аларның берсе – эксперт комиссиясенең оешманы турыдан-туры тикшерүе. Техикумның стратегик партнёры «Татнефть» ГАҖ белән үзара бәйләнеше һәм матди-техник базасының торышы эксперт комиссиясе тарафыннан аеруча югары бәяләнгән.

2016 елның 28 ноябрендә ТР Хөкүмәт йортында конкурс лауреатларын һәм дипломантларын бүләкләү тантанасы булып узды. Лениногорск нефть техникумы директоры Игорь Врублевскийга бүләкне ТР Премьер-министры Илдар Халиков тапшырды.

«Конкурста катнашу инновацион үсеш юнәлешен алырга ярдәм итте, нәтиҗәдә ул уку йортыбызның эшлеклелек имиджы һәм көндәшлеккә сәләтлелеге күтәрелүдә чагыла, һәм техникум хезмәт базарына иярергә генә түгел, аның ихтыяҗларын алдан фаразларга омтыла. Кулланучының теләкләренә, эш бирүченең һәм җәмгыятьнең таләпләренә юнәлеш тоту – менә безнең төп курсыбыз», – дип белдерде Игорь Врублевский.

Техикумның башка казанышлары:

- 2014 елда коллектив «Урта һөнәри белем бирүдә әйдәп баручы» Бөтенроссия конкурсында җиңеп чыга һәм «2014 елда Россия Федерациясенең иң яхшы техникумнары» рәсми реестрына кертелә.
- Россия һәм чит илләрдәге фәнни һәм белем бирү оешмаларында әзерлек, кабат әзерлек һәм стажировкага ТР Хөкүмәтенең «Алгарыш» грантлары.
- 2015–2016 уку елы нәтиҗәләре буенча техникум «Икътисадның реаль секторы» юнәлешендә Татарстанның 67 һөнәри белем бирү оешмасы арасындагы рейтингта 1 урынны ала.
- 2015 елда техникумга – ресурс үзәге статусы, 2016 елда геодезия юнәлеше буенча WorldSkils махсуслашкан компетенция үзәге статусы бирелә.

Реклама

Лицензия № 5987, 2015 елның 19 февраленнән ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан бирелгән.

ХАЛЫККА УҢАЙЛЫ БУЛСЫН ДИП ЭШЛИБЕЗ

«Дөньяда кешеләр өчен тамчы кадәр генә булса да изгелек эшләдем дип сөенүдән дә гүзәлрәк хис юк», – дип язып калдырган Лев Толстой. «Мәскәү районы ТКХ ИК» ҖЧҖ коллективының бөтен эшчәнлеге нәкъ менә шул хис белән сугарылган. Биредә шулай эшләгәндә генә идарә компаниясе белән торак йортларда яшәүчеләр арасындагы хезмәттәшлекнең югары нәтиҗәлелегенә ирешеп була, дип исәплиләр. Хезмәт күрсәтүнең сыйфаты һәм эшне оештыруга яңача якын килү халык һәм шәһәр җитәкчелеге тарафыннан югары бәяләнә. 2016 елда компания Татарстан Республикасының «Сыйфат өчен» премиясе конкурсының «Эшлекле камиллек» номинациясендә дипломант булды.

Мәскәү районы ТКХ ИК күпфатирлы йортлар белән инде ун ел дәвамында уңышлы идарә итә. Биредәге хәлләр ТКХ тармагы өчен бик үк гадәти түгел: шикаятьләр урынына күбрәк рәхмәт хатлары килә, чөнки компания тиешлесеннән һәрвакыт күбрәк эшли, халыкның тормышын уңайлырак һәм рәхәтрәк итәргә тырыша.

Хәер, компания эшен районда яшәүчеләр генә түгел, һөнәри берләшмә дә югары бәяли. Идел буе сыйфат үзәге экспертлары идарә компаниясенең икенче ел рәттән йортларга капиталь ремонт ясауны шәһәрдә беренче булып уңышлы төгәлләвеннән тыш, новаторлык тәкъдимнәре кертүен дә билгеләп үтә. Мәсәлән, керү юлларын биредә гадәти булмаганча итеп эшләделәр – алар шале стилендә башкарылды һәм чәчәкләр белән бизәлде, ишек яннарында велосипед кую урыннары булдырылды. Йортларның ал якларын буяганда пычрануга чыдам составлар кулланыла. Йортларда җылылык энергиясен экономияләү өчен капиталь ремонт барышында һава торышына карап көйләнә торган приборлар урнаштырыла, алар җылылык бирүне тыштагы һава температурасына карап көйләргә мөмкинлек бирә. Мондый приборлар 143 йортка куелган инде.

2015 елдан каты көнкүреш калдыкларын чыгару чыгымнарын экономияләү өчен пластикны аерым җыю тәртибе кертелде. Аныса да эшкә ярады: файдаланылган пластик әрҗә калдыклары ишек алларында кече архитектура формалары урнаштыруга китте.

Тагын бер мөһим әйбер – мәгълүмат ачыклыгы, шуның ярдәмендә халыкның идарә компаниясенә ышанычы арта. Аның рәсми сайтында теләсә кем фатирының шәхси исәбе буенча барлык кирәкле операцияләрне башкара, интернет-кабул итүдә үзен кызыксындырган сорауларны бирә ала. Компания җитәкчесе шәхсән үзе халык белән һәрчак аралаша ала, аның инициативасы белән Казан коммуналь хуҗалык колледжын тәмамлаучылар арасыннан сыйфат бүлеге гамәлгә кертелде. Бу бүлек бары тик җитәкче алдында гына хисап тота. «Ачык Казан» шәһәр программасы ярдәмендә халыкның агымдагы гаризаларын кабул итү һәм үтәү буенча эш тулысынча автоматлаштырылган. Һәркем телефон, интернет һәм смартфон ярдәмендә гариза бирә һәм аның үтәлешен тикшерә, исәпләү приборлары күрсәткечләрен тапшыра, үзе яши торган йортның техник торышы турындагы мәгълүматны карый ала.

Биредә кадрлар әзерләү – яшьләрме ул, тәҗрибәле, квалификацияле белгечләрме, – Казан коммуналь хуҗалыгы һәм төзелеше колледжы белән берлектә алып барыла. Мәскәү районы ТКХ ИК инициативасы белән, Татарстанда беренче буларак, колледжда күпфатирлы йортлар советларының рәисләренә торак законнары нигезләрен өйрәтү программасы старт алды.

Матди ярдәм күрсәтү һәм социаль эш Мәскәү районы ТКХ ИК эшчәнлегенең мөһим юнәлешләре булып тора. Биредә сукырлар оешмаларына һәм ДЦП белән авыручы инвалидларга ярдәм күрсәтелә. Идарә компаниясе, түләүле операцияләргә мохтаҗ булган балаларга булышу йөзеннән, «Чит кеше тормышы – вак-төяк түгел» акциясендә катнаша. Ел саен Бөек Ватан сугышы ветераннарының фатирларына ремонт ясау буенча өстәмә эшләр башкарыла.

Күп мәсьәләләр инде хәл ителгән, әмма эшләнәсе эшләр дә шактый әле, һәм компания коллективы үз өстенә алган йөкләмәләрне сыйфатлы итеп башкару һәм үзе хезмәт күрсәтә торган йортларда яшәүче халыкның тормышын чын-чынлап уңайлы итү өчен бөтен көчен куя.

Профильле конкурсларда җиңүләр:

- 2013 ел – «Торак фонд белән идарә итүче иң яхшы оешма» һәм «Халык фикере буенча иң яхшы ишек алды» (Декабристлар ур., 189нчы йорт) җиңүчесе.
- 2014 ел – ТР муниципаль районнарының халык социаль проектлары конкурсы лауреаты (Декабристлар урамы, 186нчы йорт ишек алды территориясен төзекләндерү проекты).
- 2016 ел – «Чәчәк атучы Казан» конкурсы җиңүчесе («Иң үзенчәлекле чәчәкле композиция» номинациясе).

Реклама

PRESSA.RU

«ШИФАЛЫ СУ – ИЖМИНВОДЫ»: СӘЛАМӘТЛЕКНЕҢ ТӘМЕ

Профсоюзларның шәхси дәвалау-савыктыру учреждениесе – «Шифалы су – Ижминводы» шифаханәсе – Татарстанның бик күптәнге һәм данлыклы дәвалану һәм ял итү урыны, республикабыз символларының берсе. Аның күпсанлы бүләкләре һәм исемнәренә быел тагын берсе өстәлде. Шифаханә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен премияләре конкурсы дипломанты булды.

Илдар Халиков, ТР Премьер-министры, һәм Роза Снадина, «Шифалы су – Ижминводы» шифаханәсе баш табибы

Айдар Садыйков, «Шифалы су – Ижминводы» шифаханәсе директоры

Татарстанның «Шифалы су – Ижминводы» курортларын чолгап алган гаҗәеп гүзәл манзара – Кама елгасы киңлекләре, ылыслы урманнар һәм су баса торган болыннар бөек рәссам Иван Шишкинның мәшһүр картиналарын хәтерләтә.

Биредә табигать үзе үк савыктыру сәләтенә ия, һәм аның төп байлыгы – составы уникаль үзлеккә ия булган су. Чишмәләре һәм кизләүләре ком-таш һәм известьташтан, кальцит, пирит, бакыр һәм кургаш катнашкан төрле балчыклардан торган чиксез зур җир асты сыемнарыннан, зәңгәрсу һәм яшькелт балчыклардан башлана. Бу катнашмалар суга үзенчәлекле төсмер биреп кенә калмый, аны төрле үзлекләр белән дә баета.

Химик составы буенча «Шифалы су» Европаның мәгълүм чишмәләре – Виша, Фахинген һәм Вильдунген суларын хәтерләтә.

Шифаханәнең үзенчәлекле сулары ашказаны-эчәк юллары авыруларыннан (гастрит, ашказаны һәм уникеилле эчәк җәрәхәте, гепатит, панкреатит, үңәч һәм эчәк авырулары) интегүчеләргә ярдәм итә. Биредә сулыш органнары һәм тире авыруларыннан, терәк-хәрәкәтләнү аппараты зарарланудан җәфа чигүчеләргә, шулай ук неврология, урология, гинекология өлкәсендә һәм мигрень белән көрәшүдә уңышлы ярдәм итәләр.

Шифалы су барлык дәвалау процедурларының нигезен тәшкил итә. Болар – минераль ванналар, су асты душы, минераль су һәм ләм белән дәвалану, мунча, массажлар, бассейн, спелеотерапия һ.б. Дәвалау процедураларының һәм төрле медицина хезмәтләренең (мәсәлән, УЗИ, ЭКГ) гаять киң булуы да җәлеп итә. Күптөрле тикшеренүләр үтү өчен махсус лаборатория дә бар.

Моннан тыш, шифаханәдә дәвалау процедуралары өр-яңа җиһазлар һәм җайланмалар куллану ярдәмендә үткәрелә (мәсәлән, умыртка сөяген су астында тарттыру өчен «Акватракцион» аппараты, кислород барокамерасы, карбокситерапия (углекислый газны тире астына җибәрү) һәм күп кенә башка җайланмалар).

Шифаханәдә яңа төр уникаль аппарат – «Магнитотурботрон» да бар. Организмның барлык күзәнәкләре электромагнит нурланыш һәм сигналларны актив кабул итүче булып тора. Шуның нәтиҗәсендә көчле магнит кырына урнаштырылган кеше электромагнит стресс кичерә башлый. Шундый бер дәвалау сеансы организмга гадәти электромагнит мохитендә чагында эчке мәгълүмат агымнарын кабат торгызырга ярдәм итә. Магнит кыры бөтен дөньядагы төрле дәвалау үзәкләрендә шактый киң кулланыла. Чөнки бу ысул күп кенә

Лицензия № ЛО-16-01-003331, 24 март, 2014 ел.
ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан бирелгән.

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ, НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

Реклама

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ, НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

белгечләр тарафыннан хуплау тапты. Әлеге аппараттан файдалану нәтиҗәсендә төрле диагнозлы озакка сузыла торган авырудан интегүче йөзләрчә кеше сәламәтләнде.

«Ижминводы» шифаханә комплексында күптән түгел файдаланыла башлаган тагын бер искиткеч яхшы методика – бөердәге ташларны лазерлы прибор ярдәмендә таркату. Ул – бөтенләй авыртусыз һәм куркынычсыз процедура. Лазер сиздерми генә эшли һәм ташларны акрынлап кына тарката, алар исә, вак комга әйләнеп, соңыннан организмнан табигый юл белән чыгарыла. Шул рәвешчә, бу хирургик ысулны алыштыручы менә дигән процедура булып тора.

Предприятиедә эшләүче 300дән артык хезмәткәр «Ижминводы» кунакларына барлык медицина хезмәтләрен тиз һәм сыйфатлы итеп күрсәтү өчен тырыша. Табиблар югары һәм беренче категорияләргә ия, һәрберсенең төрле авыруларны дәвалау өчен тиешле сертификатлар белән расланган 2–4 белгечлеге бар.

Шифаханә кунакларны инде 92 ел дәвамында кабул итә. Бүген ул – искиткеч яхшы шартлары булган уңайлы һәм заманча комплекс. Сигез катлы корпуста төрле категорияләр белән бәяләнә торган бер һәм ике урынлы бүлмәләр урнашкан. Люкс класслы бүлмәләр торак бинаның чирек өлешен алып тора. Гаилә номерларында берничә йокы бүлмәсе бар. Йокы корпусы, ресторан, дәвалану һәм спорт корпуслары җылытылган кичү юлы белән үзара тоташтырылган. Буш урыннар булганда, клиентлар теләсә кайсы көнне кабул ителә. Биредә бер үк вакытта 420 кеше урнаша ала.

Танылган табиб Мануил Певзнер нәтиҗәле дәвалануның нигезендә дөрес туклану ята, дигән. «Ижминводы»да әлеге принципка зур игътибар белән карыйлар: юллама бәясенә, интенсив дәваланудан тыш, дүрт һәм биш тапкыр диетик туклану да кертелгән. Менюда исә – төрле милли ашларның киң ассортименты, яшелчә һәм җиләк-җимеш. Менюга заказ бирү системасы да эшли.

Һәркемнең күңеленә хуш килә торган күптөрле хезмәт күрсәтү өстенә, биредәге искиткеч күркәм табигать ял итүчеләрнең сәламәтлекләрен ныгытып кына калмый, рәхәтләнеп хозурланырга һәм күңел ачарга да мөмкинлек бирә. Шифаханәгә күренекле артистларның еш кына концертлар белән килүе дә очраклы түгелдер, мөгаен.

«Шифалы су – Ижминводы»да бассейн, мунча, күнегүләр ясау һәм физкультура заллары, волейбол мәйданчыклары, теннис корты, өстәл теннисы залы, бильярд һәм шахмат клублары эшли, велосипед, чаңгы, чана һәм тимераякларны прокатка алу мөмкинлеге бар.

Курортта дәвалану сәламәтлекне ныгытырга, кәефне күтәрергә ярдәм итә, һәркем аннан матур тәэсирләр һәм күңелле истәлекләр алып китә. Шуңа күрә «Ижминводы»ның илебездәге иң танылган шифаханәләрнең берсе булуы һич тә очраклы түгел.

«Ижминводы» шифаханәсенең 2016 елдагы башка казанышлары:

- «Минераль суларны дәвалау-профилактика максатында куллануның иң яхшы технологияләре» номинациясе буенча «Здравница» Бөтенроссия форумында алтын медаль.
- «Шифаханәнең иң яхшы җитәкчесе» номинациясендә директор Айдар Рөстәм улы Садыйковка алтын медаль тапшырылды.
- «Савыктыру һәм дәвалау тукланууын оештыру буенча иң яхшы шифаханә» номинациясендә көмеш медаль.
- Татарстан Республикасының кунакханәләре һәм рестораннары арасында Top Notel Awards* һәм Top Restaurants Awards* республика профессиональ премиясе номинанты көмеш дипломы.
- «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәт күрсәтү-2016» республика конкурсы һәм «Россиянең 100 иң яхшы товары» Бөтенроссия федераль программасы-конкурсының «Санатор-сәламәтләндерү хезмәтләре» номинациясе лауреаты.
- «РФнең иң яхшы шифаханәләре-2016» милли конкурсы: лауреат дипломы, медаль (Санкт-Петербург).
- «Ел җитәкчесе-2016» Бөтенроссия почет премиясе (Мәскәү).
- «Актив озын гомер дөньясы» Халыкара социаль-медицина форумы: «Актив озын гомер өлкәсендә югары технологияләр лидеры 2016» почет дипломы (Мәскәү).
- Россия Федерациясе үсешенә ярдәм иткән күпьеллык нәтиҗәле эше өчен Айдар Рөстәм улы Садыйков («Ижминводы» шифаханәсе директоры) «Россиянең почетлы гражданины» Җәмәгать танылуының югары ордены белән бүләкләнә.

* «Татарстанның иң яхшы кунакханәләре» һәм «Татарстанның иң яхшы рестораннары».

PRESSA.RU

16+
НОВОСТИ СО ВСЕЙ РЕСПУБЛИКИ
И ДЛЯ ВСЕЙ РЕСПУБЛИКИ!
Реклама
24
НОВОСТИ КАЖДЫЙ ЧАС
НА ТЕЛЕКАНАЛЕ «ТАТАРСТАН-24»

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Кече ватан патриотлары **КАЯ** юл тотты

Чыршы уенчыгы **НИЧӘ** ел яши

Яңа ел сюжетлары **КАЯН** алына

Кыш бабай Яңа ел табынына **НИЛӘР** әзерли

PRESSA.RU



КЕЧЕ ВАТАН ПАТРИОТЛАРЫ

СЕЗГӘ ЭНДӘШМИ, УЛ КЕМГӘ ЭНДӘШСЕН, ӨЯНКЕЛӘР...

Автор:
Луиза Янсуар

Күлле Кимегә килеп кергәч, безне Сибгат абыйның җырына кергән өнякеләр каршы алды. Аларның ябалдашларын кискәннәр, ап-ак һәм тып-тын кышкы фонда алыплар булып тезелешеп утыралар. Күлле Киме халкы аларның язын шаулап китәчәгенә чын күңелдән ышана. Без дә шикләнмәдек.

«Сезгә эндәшми, мин кемгә эндәшим, өянкеләр…» – бу сүзләр, Сибгат Хәким эзләреннән йөргәндә, күңелдә яңгырап торган төп лейтмотив булды. Кешеләргә дә эндәшкәндер ул, сөйләшкәндер дә, аларның гамен дә тыңлагандыр. Һәрхәлдә, биредә – шагыйрьнең кече ватананында, аны, аз сүзле булса да, халык гаменә колак сала, аны ни борчый, шул хакта гәп кора торган үтә тыйнак, үтә сабыр һәм кешелекле зат буларак хәтерлиләр. Әмма бер йөрәккә күпме гамь сыя ала соң? Ул әле үлем сызыгыннан – сугыш кырларыннан алып кайткан хатирәләрне дә саклаcа…

Фотолар: А.Эшкинин, ТР Дәүләт архивыннан

НӘСЕЛ ШӘҖӘРӘСЕ – КЕМ КУЛЫНДА?

Юлыбыз Күлле Кименең чын мәгънәсендә иҗат йорты булган Сибгат Хәким музееннан башланды. Ул мәктәп бинасының бер канатында урнашкан. Дөрес, биредә шагыйрьнең туган нигезе дә исән. Берара музейны шунда күчерү хакында сүз дә булган, күпмедер эш тә җанланып киткән, әмма азагынача җитә алмаган. Сибгат Хәкимнең туган йорты, шулай итеп, тып-тын гына үз урынында йокымсырап утыра. Без аның янынннан карап кына уздык. Аны музей-йорт итү мәсьәләсе әле һаман да ачык булып кала...

Луиза апа Шәмсиева оештырган музейда, әйтерсең, аның үзенең дә бөтен гомере яши – балачактан алып, безнең көннәргәчә булган уй-хыяллары, ният-омтылышлары. Чөнки аны Сибгат Хәким белән балачак хатирәләре үк бәйли.

Луиза Шәмсиева, Күлле Кимедәге Сибгат Хәким музеена нигез салучы һәм аның җитәкчесе:

– Сибгат абый безнең гаилә дустыбыз иде. Әнием гомер буена укытучы булып эшләде. Әтием шахтада да эшләп алды, колхоз рәисе дә булды. Ул менә дигән оештыручы иде, Сибгат абыйның якын дусты. Әнием белән бертуган абый – Габдулла Сабиров – Сибгат абыйның күп кенә әсәрләренә кергән каһарман. Шәхес культы елларында 58 нче статья белән кулга алынып, 10 ел Колымада сөргендә була. Авылга исән-сау әйләнеп кайтырга насыйп була аңарга. Ул – Сибгат абыйның укытучысы да.

Габдулла абый әйләнеп кайткач, Сибгат абый гел аның янында бөтерелә торган була. Әле минем дә хәтеремдә: тел, авыл һәм милләт язмышы, аның киләчәге турында сөйләшеп утыра торганнар иде.

Музейда Сибгат абыйның шәхси әйберләре – китаплары, автографлы басмалары, кульъязмалары, киемнәре, хәтта мунча әйберләре, шампунь савытларына кадәр бар. Луиза апа боларның барысын да 30 ел буена бөртекләп җыйган. Ул зур җылылык белән Сибгат Хәкимнең әнкәсен – Газзә апаны искә ала. Гомумән, шагыйрьнең нәселен бик хөрмәт итә, аның шәҗәрәсен биш бармагы кебек белә.

– Шагыйрьнең нәсел шәҗәрәсе Мәмкә атлы карттан башлана. Гадел, зирәк була ул, шуңа да авыл халкы аны җир бүлүче итеп сайлый. Озын, авыр чылбырлар сөйрәп, Мәмкә карт иген басулары буйлап җир бүлеп йөри торган була. Сибгат Хәким үзенең бер шигырендә Мәмкә бабасын болай искә ала:

Мәмкә торган буын башында,
Бер сүз белән әйтсәк: межачы...
Авыл белән авыл арасын
Ярып узган дөнья нужасы.
...Хәзер дә бар Мәмкә елгасы,
Бар да дөрес, бар да чын монда.
Җир бүлгәндә, шушы елгада
Елаган ул, ятып чылбырга...
Буын-буын озын чылбырны-
Һич өзелмәс моңлы шул җырны
Ничә еллар инде, ни заман
Үзем сөйрим хәзер межадан.

«ЮЛЛАРЫМ – ӘНКӘЙНЕҢ АГАРГАН ЧӘЧЕНДӘ...»

Сибгат Хәкимнең әтисе балта остасы була. Аларның нәселендә гомумән балта эшен белмәгән кеше юк, дип искә ала авылдашлары. Әмма Сибгат Хәкимнең үзенә бу осталыкка өйрәнү насыйп булмый. Куллары кечкенә булып, балта эшендә остара алмый. Истәлекләрдә сакланып калган бу факт. Әнисе Газизә моңа бик кайгырган: «И улым, тамагыңны ничек туйдырырсың инде?! Авылдан-авылга йөреп, „Зингер"да кием-салым тегәрсең микән...»

Авылдашлары бу булдыклы, уңган, акыллы ханымны яратып, үз итеп, «Газзә» дип йөртә торган булганнар. Күлле Кименең иң хөрмәтле кешеләреннән берсе санала ул. Авыл җирендә казыйга-фәләнгә йөрмиләр инде ул заманда, эшне суд белән хәл итүне дә кулай күрмиләр, халык Газзә апага бара торган була – кешеләрнең араларын нәкъ менә ул җайга салган.

Газзә апа җиде бала тәрбияләп үстерә. Гомерендә бик күп кешеләрне шифалы үләннәр, шифалы киңәшләр белән дәвалый. Ул үзе Бирәзә авылыннан була. Күлле Кимегә кунакка килгәндә, танышып, дуслашып китә булачак ире Хәким белән. Дуслык акрынлап мәхәббәткә әверелә. Аңлашып, тату яшиләр. 1921 елда Хәким, өлкән улын ияртеп, акча эшләү максаты белән Украина якларына чыгып китә. Шуннан әйләнеп кайтмый. Газзә апага берсеннән-берсе кечкенә сабыйларны ялгызына үстереп, аякка бастырырга, кеше итәргә туры килә.

Кечкенәдән үк нечкә күңелле, хисле бала була Сибгат. Әнисен бик ярата. 1921 елгы ачлык елында мәктәптә укыган чагы. Укучы балаларга бушлай кайнар аш бирәләр. Ашханәдә балалар үзләре дежур тора. Менә Сибгатның да дежур тору көне килеп җитә. Тәмле исләр чыгарып аш пешеп җиткәч тә ул: «Апа, мин өйгә генә кайтып килим әле», – ди дә күздән югала. Күп тә үтми, әнисе белән килеп җитә. Ашны өйгә алып кайтып, барысы бергә ашыйлар.

«ЭШЛӘПӘСЕЗ ЧАГЫН ХӘТЕРЛӘМИМ...»

– Менә шулай итеп ачлы-туклы елларда да бер-берсенә терәк булып, яшим, дип тырышалар. Ә инде Бөек Ватан сугышы башлангач, өч агайэне сугышка китәләр. Сибгат Хәким сугыштан әйләнеп кайткач, фронт яралары шигырьләрендә калкып чыга. Гариф исемле туганына концлагерь газаплары аша үтәргә туры килә, бер апасы шәфкать туташы була. Боларның барысы да аның йөрәгенә җыела, билгеле, үз эзен салмый калмый.

– Инде олыгайгач та, туган авылына кайтып, әнисе белән озак-озаклап сөйләшеп утырырга ярата, үзен борчыган бик күп сорауларга аннан акыллы киңәшләр ала иде ул, – дип искә ала Луиза апа. – Сугыш хатирәләрен чит-ят белән сөйләшкәнен хәтерләмим, бәлки, Газзә апа белән сөйләшкәндер... Бик якын иделәр алар...

Бу хакта шагыйрьнең шигырьләре дә сөйли:

Карадым әнкәйгә: юлларым
Әнкәйнең агарган чәчендә...

– Нинди иде ул – Сибгат абый? – дип сорыйм Луиза ападан. Чөнки аның турында Сибгат Хәкимнәр, Хәсән Туфаннарның олпат тәрбиясе эләккән 60 нчы елгылардан күп ишеткәнем бар. Алар «Сибгат ага» дип үтә бер җылылык, тыенкы гына ярату һәм сагыш хисе белән искә алалар шагыйрьне. Сибгат ага-

PRESSA.RU

ны Казанда бер төрле булып, авылда икенче төрле булып йөргән күз алдына да китереп булмый, ул нинди бар, шундый иде – гади, табигый, дигән фикерне еш ишеткәнем бар алардан.

– Бик гади иде чынлап та, – дип елмая Луиза апа. – Аның кебек гади кешеләрне тормышта еш очратмыйсың. Кайта иде дә, плащ, эшләпәсен киеп алып, басулар буйлап йөрергә чыгып китә иде. Кайвакыт авыл советы председателе үз тарантасында җилләтеп кайта иде. Аз сүзле булса да, кирәген генә әйтеп куя, гадәттә, Сибгат абый. Урынлы булуын сизсә, киңәшен бирми калмый. Кайчакта иҗатташ дуслары белән бергә кайта иде. Алып кайткан дуслары да нәкъ үзе шикелле гади булып хәтердә калган.

Казанга килгәч, ул мине бик күп язучылар белән таныштырды. Аларны алып кайтып та очрашулар уздыра идек. Гомәр Бәширов, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Гариф Ахунов, Гамил Афзал... Кемнәрнең генә аяк эзе сакланып калмаган Күлле Киме туфрагында...

Луиза апа әйтүе буенча, Сибгат Хәким, кайтканда, шәхси әйберләрен музей өчен махсус үзе дә алып кайта торган булган. Гадәттә – эшләпәләрен.

– Эшләпәләре шулкадәр күп идемени? – дип көлемсерим.

– Булгандыр инде... – дип, берара аптырап, уйланып тора Луиза апа. – Эшләпәсез чагын хәтерләмим...

Аннары Сибгат Хәкимнең тагын бер сыйфатын искә ала:

– Кемне генә алып кайтса да, нинди генә дәрәҗәле кешеләр белән аралашса да, аның өчен иң кадерлесе – гади кешеләр, үз авылдашлары иде. Менә шул авылдашлары белән гадәти генә итеп аралашып, аннары аларны иҗатында күтәрә белде Сибгат абый. Безнең авыл кешеләре аның иҗатында үзенә бер галереяне тәшкил итә.

ТАВЫК ИТЕНЕҢ ХИКМӘТЕ

Хәтерлисездер, «Кече ватан патриотлары» проектының төп максаты – иҗат әһелләренең туган якларына кайтып, аларны исән чагында белгән кешеләр белән аралашу, истәлекләрен туплап, сезгә җиткерү. Димәк, Сибгат абыйны яхшы белгән 95 яшьлек Мәймүнә апа Гайсина белән очрашмыйча берничек тә китә алмый идек. Ул үзе тумышы белән Күнгәр авылыннан. 1946 елда Күлле Кимегә килен булып төшә. Кайнатасы белән Сибгат Хәкимнең әтисе – бертуганнар.

Мәймүнә апа, 95 яшендә булса да, гаять тере, җор телле, шат күңелле якты бер әбекәй булып чыкты. «Үзе дә шигырьләр яза ул», – дип пышылдады колагыбызга безне озата йөргән ханым.

– Яхшы хәтерлим Сибгат абыйны, менә бүген сезне күргәндәй, күз алдымда тора! – дип башлады Мәймүнә апа сүзен. – Зәңгәр плащтан булыр иде, кулларын кесәсенә тыккан, ә анда... гел тиен акчалар чылтырап тора. Авылның бала-чагасына өләшә иде шуларны. Бик юмарт, бик ита-

1946 елның язында Сибгат Хәким кайткан көн бик матур, кояшлы була. Өенә кайтып кергәндә, аны хатыны Мөршидә, бертуган сеңлесе Хәдичә көчкә таныйлар. Сап-сары йөзле, күзләре эчкә баткан, чәчләре чаларган,ябык. Сөйләшә алмый, буылып-буылып йөткерә. Аңа икенче көнне үк участок врачын чакыралар. «Бик бетерешкән, бер айдан артык яши алмас, хәстәрен күрә торыгыз», – дип диагноз куя табиб.

Шагыйрьнең кайтуын ишетеп, каләмдәш дуслары җыйнала. Алар 34 яшьлек Сибгатны бу хәлдә күреп аптырап калалар. Кайту сөенеченнән авылга – Күлле Кимегә, әнисенә, туганнарына хәбәр итәләр. Әнисе килеп төшә. Улын күреп аның да хушы китә. Әмма сиздерми. Улы янында озак кына утыра да, киленен читкә чакырып ала. «Кызым, бик елама, үзеңне бетермә, өметне өзмик әле, өметсез шайтан гына, диләр. Сибгатның күзендә нур бар, нурлары бетмәгән әле, Алла бирсә, терелер», – ди.

гатьле кеше иде, ул гадилеген әйтеп тә тормыйм...

Бала-чага дигәннән, берсендә авыл малайларын ияртеп, басуга алып чыккан Сибгат абый. Кошлар карап йөргәннәр болар. «Менә каргалар бик озак яшиләр», – дип сөйли икән Сибгат абый. Шунда бер авыл малае: «Алар бит тавык урлап, тавык ите генә ашыйлар, шуңа озак яшиләрдер», – димәсенме. Сибгат абыйга ошаган аның кыюлыгы, бу сүзләрне хәтерендә калдырган. Шуннан үзе дә тавык итенә өстенлек бирә башлаган. Шулай берсендә Сибгат абый кунакка кайтырга җыена. Мин кайнатама: «Тавык ите пешерәседер инде Сибгат абыйга, озын-озак яшәсен», – дип шаярып дәштем. Аннары, сөйләгәч, үзе дә көлде Сибгат абый. «Сибгат бит ул тавык ите генә ашый, озак яшәргә тели», – дип үзара көлешә иде туган-тумача.

Мәймүнә апа, хискә бирелеп, ул арада Сибгат Хәкимнең шигырьләрен дә, үзенекеләрне дә укып алырга өлгерә. Аннары шагыйрьнең кайбер шигырьләренең, «Курск дугасы» поэмасының язылу тарихына күчә:

– Менә безнең бакчадагы чия бит инде ул! Ярата иде шул чияне Сибгат абый. Мунчаны да... Хәзер генә ул мунчага артык әйберләрне чыгарып өяләр. Безнең заманда мунча алачыгы – ял урыны, тынлык почмагы иде. Сибгат абый безнең шул мунча алачыгында язып утырырга бик яратты. «Казбек» папиросын тәтәтә-тәтәтә яза иде, җаныем. Мин бит инде килен кеше, чәй чыгарам, капкалап алырга – ни дә булса... Бераз тартынам инде, әмма язуына бик соклана идем, шигырьләрен бик тыңлыйсым килә иде...

– Шигырьләрен авыл халкына укый идеме соң, Мәймүнә апа? – дим.

– Юк, сеңлем, әллә ни еш укымый иде. Шулай да, ирләр үзара гәпләшкәндә, колакка чалынгаладылар. Безгә, хатын-кызларга, аерып кына укып утырмый иде инде... Бигрәкләр дә гади, матур яза иде бит. Халыкчан итеп...

Ул кичке якта халык җыелган җиргә чыгып утырып, сөйләшкәннәрен тыңлап утыруны үз итте. Үзе белән гел блокнот йөртер иде. Берәр кызыграк сүз, гыйбарә ишетсә, вакыйгага тап булса, язып куя. Моны соңыннан шигыренә кертеп җибәрәчәк инде, материал җыя, дип уйлый идем эчемнән генә. Һәм чыннан да авыл кешеләре аннан әсәрләрендә калкып чыгалар иде. Ул үзенчә шулай итеп тормышны өйрәнгән инде, балам, тормыш бит ул дүрт стена эчендә түгел, кешеләр кайнашкан җирдә...

КЕШЕ ХӘЛЕНӘ КЕРӘ БЕЛДЕ...

– Әнием вафат булганда, миңа нибары 10 яшь иде, – дип сөйләп китте шагыйрьнең икетуган сеңлесе Дания Закирова. – Өч бала – тома ятим калдык. Мин – уртанчысы, ке-



Сибгат Хәким фронттагы полкташы белән. 1945 ел.

Сибгат Хәким (уңнан беренче) каләмдәш дуслары арасында.

черәк сеңлем бар. Сибгат абыйның әнисе Газизә апа безне тәрбиягә алды. Үз баласыдай күрде, какмады, кимсетмәде. Чиксез хөрмәт итәм мин аны, аның кебек кешеләрне фәрештәгә тиңләргә була.

Ул чакта Сибгат абыйның мине кочаклап юатканын һич онытасым юк: «Кызым, елама, әниеңне күз яшьләре белән кайтарып булмый барыбер», – дигән иде ул. Бу сүзләр, шундый хөрмәтле абыйдан ишетелгәч, минем өчен бик кадерле булды.

Сибгат абыйның безгә ярдәме күп тиде. Олы йөрәкле иде ул, кеше хәленә керә белә торган. Әнине операциягә салган чакта, Казанга алып килеп, урнаштырырга ярдәм итте.

Сибгат абыйны мин табигать баласы, дияр идем. Әнисе дә табигатьне ярата, белә торган кеше иде. Шулай берсендә чишмәгә суга төштем, Сибгат абый тал-тирәкләргә хозурланып йөри. «Ник шулай карыйсыз аларга?» – дип сорарга җөрьәт иттем. Үсә төшкәч кенә аңладым: ул бит – шагыйрь, шулай илһам ала икән...

Остазыбыз Сибгат ага Хәким янында. Сулдан уңга: беренче рәттә – Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, икенче рәттә – Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалим, Рәдиф Гаташ.

«ӘДӘБИЯТ – АЛГЫ СЫЗЫК»

Рәдиф Гаташ, Татарстанның халык шагыйре:

– Шагыйрьнең кече улы Рафаэль Хәким миңа әтисенең көндәлек дәфтәрләрен күрсәткән иде. Соңгы дәфтәрнең иң соңгы битендә 1986 ел, 16 январь көне белән тәмамланган язма... Мин аны күчереп алдым. Ни өчен дигәндә, нәкъ шул бит кенә шагыйрьнең үзе вафат булганнан соң дөнья күргән китабына (аңа мәкаләләр, публицистик язмалар, көндәлекләре тупланган) нигәдер «сыймый калган» иде. Сәбәпләрен ачыклап тормыйм. Әмма әлеге юллар зур шагыйрьнең, остазның шәхесен тагын да калкурак ачарга ярдәм итә дип уйлыйм. Менә ул өзек: «Буран, салкын, сулау авыр... Язучылар союзында җыелыш булды. Өйгә хәтле Рәдиф култыклап алып кайтты. Сугыштан яралыларны алгы сызыктан шулай алып чыгалар иде. Фронт искә төште. Үзем дә кайчакта алып чыккаладым. Әдәбият – алгы сызык. Хәзер үземне алып чыгалар. Минем өчен алгы сызыклар бетте. Әз генә дә үкенмим, борчылмыйм, ике фронтта да ахырынача сугыштым...»

25 елга якын аралашып, Сибгат агада мин бер генә «мәгънәсез көлке-уен» сүз озайту, арзанлы мәзәк, анекдот яки кемнедер рәнҗетү, саксызлык, тупаслык ишарәсе күрмәдем, ишетмәдем. Үзе чын зыялылар затыннан иде шул, гали тәрбияле, зирәк акыллы иде...



Менә безнең таныш фоторәсем. 1970 елның гыйнварында төшкәнбез. Сибгат ага – уртада. Аның тирәсендә – 60 нчы елларда әдәбиятка килгәннәрдән бер төркем: Равил, Ренат, Гәрәй, Рөстәм, мин... Әлегә торгынлык еллары. Үзгәрешләр әле бик еракта, киләчәктә атачак таң кебек – алда, алда... Без дә әле алданган, күпне аңлап та бетермәгән, ил, халык тарихын әле йөрәк белән төшенмәгән яшелләр, яшьләр, әмма иҗади дәрттә янган чая «әтәч»ләр...

Яшьлеккә канатлар куйган остаз янына сыенганбыз. Без нинди булырбыз? Дан өчен, урын, премияләр өчен яшәүгә йөз тотып, шигърияткә хыянәт итмәбезме? Идеалларга тугры калырбызмы, халыкка кирәк булырбызмы? Бу сорауларга җаваплар әле алда. Фото бу турыда сөйләми. Әмма ул инде – тарих. Бер буынның сәер дуслык чоры ядкәре. Дисбе кебек... Бисмилласы – Сибгат ага...

«ӨЧ КОРИФЕЙНЫ ОЗАТТЫМ...»

Госман Гомәр, язучы, публицист:

– Берзаман, яңа фатир алгач, салкында мебель ташып йөреп, суык тидердем. Обком хастаханәсенә кереп ятарга туры килде. Бу 1986 ел иде. Шунда сәгать 12 дә минем палатага китереп салдылар Сибгат ага Хәкимне. Сибгат абый аңында түгел иде. Палатада Мөршидә апага урын юк булып чыкты. Ә аңа бит Сибгат аганы карап төн кичәргә кирәк. Белештем, күрше палатада обком инструкторы ята, ә аның янында буш карават бар.

Дежур табибка бардым да, мине шунда күчерегез, ә мин яткан караватны Мөршидә апага калдырыйк, дидем. Шулай иттек тә. Иртән керсәм, Сибгат ага аңына

Сибгат Хәкимнең туган нигезе. Күлле Киме авылы.

Сибгат абый Казанда Ирек мәйданы янындагы Театральная урамында яши иде. Кичләрен урамга чыгып, һава сулап, фонарьларга сокланып, уйланып йөрергә ярата. Һәм менә шул фонарьлар турында шигырь яза ул. Әни белән алар дуслар бит, әни бу шигырьгә җыр яза. «Төнге фонарьлар» дип атала ул җыр. Сибгат абый белән әнинең башка кайбер җырлары кебек үк популяр булмаса да, бүген, шушы юбилей кичәсендә, аны Күлле Киме сәхнәсендә яңгыраттык, шөкер. Шатланып туя алмыйм моңа!

Әни белән Сибгат абый шулкадәр бер-берсе белән аңлаша торган булалар ки, хәтта аерылыша алмыйлар. Мөршидә апа берсендә шулай дип әйтә: «Сибгат көн буе Сара янында утырып кайтты, югыйсә, әмма, кайтып керүгә, аңа шалтыратып тагын кич буе сөйләштеләр».

Бу ике сәнгать әһеле үзләрен «без лириклар һәм патриотлар» дип йөртә торган булалар. Шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов аларны «бер җырның ике канаты» дип атый. Гомер буе бергә иҗат иттеләр, дус булдылар, хәзер Татар зиратында янәшә каберләрдә яталар. Иҗатлары һаман да очышын дәвам итә...

Сара Садыйкованың кызы Әлфия Айдарская сөйләгәннәрдән.

килгән. Мөршидә апа миңа рәхмәтләр укыды. Аннан әйтә: «Госман энем, – ди. – Сибгат абыең янында утырып тор инде, мин Рафаэль улыма Мәскәүгә телеграмма сугыйм». Шулай итеп, мин Сибгат ага янында утырып калдым. «Госман энем, рәхмәт инде караватыңны Мөршидә апаңа бирүеңә», – дип, мөгрәп кенә, чак елмаеп, Сибгат ага миңа эндәште.

Шул чакта минем күз алдымда өч корифей ахирәткә күчте. Берсе – Ленинны татарчага тәрҗемә иткән Сәгыйть абзый Сәлахов, икенчесе – атаклы җырчы Фәхри Насретдинов. Өченчесе – Сибгат ага. Бер атна эчендә китеп бардылар.

P.S. урынына:

Күлле Кимедән киткәндә, безне шул ук өянкеләр озатып калды. Кичке һавада сакка куелган солдатлар кебек.

Кайда ул, бергә ашкынган,
Бергә шаулаган көннәр?
Минем таныш өянкеләр,
Сезгә баш ияр кемнәр?

– дип язган иде Сибгат абый.

Безнең килүебез әнә шул баш ию иде...

PRESSA.RU

Ян-яклары эчкә батып торган шарларны XX гасырның 50нче елларында уйлап табалар: бу шәм утырту өчен уңайлы була.

Фото: Александр Эшкинин

96+

ОЗЫН ГОМЕРЛЕЛӘР

96 яшьлек «Татарстан» журналы үзенең яшьтәшләрен һәм, гомумән, республикабызның «озын гомерлеләрен» эзли. Сүз кешеләр турында гына бармый. Бәлки, яше 96га җиткән һәм аны узып ук киткән, әмма аңа карап әһәмиятен һәм кыйммәтен җуймаган тарихи һәйкәлдер ул, ә бәлки, бүген без сөйләргә теләгән гади чыршы уенчыгы гынадыр. Шул матур пыяла шарчыклар һәм ялтыравыклы нарат күркәләре аша да Татарстаныбыз тормышының бөтен бер тарихын – көтеп алынган Яңа ел бәйрәме тарихын күзалларга мөмкин бит.

РОДИОНОВЛАР ҺӘМ ПОРЫВАЕВЛАР

ТР Милли музее фондында (ул үзе дә озын гомерле – аңа 120 яшь) без хәйран «яшь» коллекциягә юлыктык. Яшь диюебез шуңа – ул әле узган гасырның 80 нче елларында гына туплана башлаган. Ә экспонатлар үзләре – чыршы уенчыклары; тиз уалучан булсалар да һәм балаларныкы дип исәпләнсәләр дә, алар инде шактый өлкән яшьтә. Әлеге коллекциянең беренче экспонатларын музейга борынгы морзалар нәселеннән чыккан, бүген Казанда яшәүче Родионовлар гаиләсе бүләк иткән. Алар артыннан Порываевлар гаиләсе дә «уянган».

Музей фондының әйберләр чыганагы бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре Елена Адрианова уенчыкларны күрсәтер алдыннан кулларына ак перчаткалар киеп куйды:

– Шулай тиеш, – дип аңлатты ул безгә, уенчыкларга кагылырга да рөхсәт итмәде. – Бармак эзләре экспонатларга зыян китерергә мөмкин.

ДРЕЗДЕН ОСТАЛАРЫ

Елена Владимировна төрле чорга караган чыршы уенчыклары белән таныштырганда, без үзебезне Яңа ел әкияте тыңлаган кебек хис иттек. Менә мамыктан ясалган алмалар һәм грушалар – алар XIX гасыр ахырыннан бирле сакланып калган. Чыршы уенчыкларын беренчеләрдән булып Германиянең Дрезден шәһәрендә ясый башлаганнар, һәм Беренче бөтендөнья сугышына кадәр немецлар бу эштә иң осталардан саналган. Аларның мамык һәм катыргадан ясалган нәфис, матур уенчыклары әле дә тоташ бер сәнгать әсәре булып тора.

АЛМАСЫЗ ЕЛ

Агач бизәү – элек-электән килгән Раштуа бәйрәме йоласы. Баштарак аны ашарга яраклы «уенчыклар» – алма, чикләвек, баллы тәм-томнар белән бизәгәннәр. Уенчык ясау идеясе шулардан килеп чыккан да. Германиядә алма уңышы булмаган елны беренче чыршы шарчыклары пәйда булган – алмаларны вакытлыча шулар белән алыштырып торырга уйлаганнар. Ә ул шарлар соңыннан да балалар күңеленнән югалмаган, яраткан чыршы уенчыкларына әйләнгәннәр.

1808 елда чыршы уенчыклары әзерләү эшенә Россиянең Клен шәһәрендә урнашкан, моңа кадәр бары тик керосин лампалары гына җитештерә торган пыяла заводы да катнаша башлаган.

ПЫЯЛА МӘРҖӘН ҺӘМ СӘЙЛӘН БӨРТЕКЛӘРЕ

1917 елда Николай II Раштуаны кышкы агачны бизәп бәйрәм итү гадәтен керткән. Төгәл бер елдан соң, Совнарком «Чыршы һәм аның белән бәйле чүп-чар бетсен!» дигән шигарь астында «буржуйлар бәйрәме»н тыйган.

Совет балалары 20 ел буе Яңа ел бәйрәменнән башка яшәде. Ә 1937 елның гыйнварында чыршы куярга рөхсәт иттеләр – Союзлар йортының Колонналар залында Яңа елны зурдан кубып һәм шаушулы итеп үткәрделәр. Һәм чыршы уенчыгы промышленносте кабат эшли башлады. 50 нче елларга кадәр уенчыклар арасында пыяла мәрҗән һәм сәйлән бөртекләреннән ясалган йолдызчыклар, кар бөртекләре һәм башка геометрик фигуралар, шулай ук көмеш катыргыдан ясалган төрле әкият геройлары өстенлек итте.

БӘЛӘКӘЙ ӨЙЛӘР ҺӘМ КЕЧКЕНӘ СӘГАТЬЛӘР

Елена Владимировна безгә төрле төстәге пыяладан ясалган кечкенә өйләрне күрсәтә; алар XX гасыр урталарына карый. Уклары унике туларга биш минутта тукталып калган нәни сәгатьләрне Эльдар Рязановның «Карнавальная ночь» фильмыннан соң җитештерә башлаганнар. Узган гасырның 60 нчы елларында ясалган уенчык космонавтлар Юрий Гагаринның космоска очуы белән бәйле, ул заманда алар бик киң таралган булган. «Бетчәле» кыярлар, «корсаклы» помидорлар һәм, билгеле, кырлар патшасы – кукуруз да – 60 нчы еллар ядкаре. Электергечле уенчыклар да шул елларга карый. Аларның «борынгы бабалары» – чыршы шәмнәре электергечләреннән бер америкалы телеграфистның башында чыршы гирляндалары ясау идеясе туган.

КЫШ БАБАЙЛАР

Кыш бабайларга аерым бер бүлек багышларга була. Аларны, бүләкләрне саклап торсын дип, чыршы астына бастырып кую гадәте бик күптәннән килә. Менә бүген каршыбызда – төрлечә киенгән дүрт Кыш бабай.

– Игътибар! Төшерәм! Күзләрне йоммаска! – дип команда бирде безнең фотограф һәм берсе – мамыктан, икенчесе – папье-машедан, ә калган икесе пластмассадан ясалган Кыш бабайлар, күзләрен дә алмый, объективка текәлеп тора башлады.

– Бездә аның тагын берсе бар, ул гомуми фотосессиядә катнаша алмый, тик, аңа карап, кыйммәте һич тә кимеми, – дип, Елена Владимировна катыргы әрҗәне ачты. Аннан безгә Бөек Ватан сугышы чорыннан калган Кыш бабай карап тора иде. – Мондыйларны госпиталь хезмәткәрләре үзләренең балаларына кул астындагы әйберләрдән (мамык һәм журналдан кисеп алынган берәр кешенең йөзен кулланып) ясый торган булганнар.

Родионовлар коллекциясендәге фарфор йөзле курчаклар (XIX гасыр ахыры – XX гасыр гасыр башы).

Унике туларга биш минут кала тукталган сәгатьләр чыршы уенчыгы буларак Эльдар Рязановның «Карнавальная ночь» фильмыннан соң популярлашып китә.

Мондый уенчык әтәчләр (картоннан, XX гасырның 50нче еллары) 2017 елгы Әтәч елына кадәр килеп җиттеләр.

Фото: Александр Эшкинин

Бөек Ватан сугышы елларыннан калган Кыш бабай.

Стеклярустан биш почмаклы совет йолдызы Вифлеем йолдызы үрнәгендә ясала.

«Малютка» җыелмасына кергән уенчыклар Порываевлар коллекциясендә сакланып калган.

«ТАТАРСТАН»НЫҢ ЯҢА ЕЛ МАҖАРАЛАРЫ

Безнең иң яраткан бәйрәмебезгә кадәр санаулы көннәр генә калып бара. Ул курьер поезды тизлеге белән якынлаша. Тагын бер-ике атна – һәм хуш киләсең, Яңа ел төне! Һәрвакыттагыча, курантлар сугуы, шампан шәрабе тамчылары, шаккатыргыч фейерверклар һәм теләкләр теләү көтә безне. Яңа ел – дөнья барыбер яхшырак, игелеклерәк, сафрак булыр дип, безнең самими өметләнүебез чоры ул. Һәм тагын – гаҗәеп вакыйгалар төне. Күңелне эретә торган көлкеле дә, хыялый да һәм моңсу да вакыйгалар. Яңа ел могҗизалы бит ул, анда әлләниләр булырга мөмкин. Моңа иң яхшы дәлил – «Татарстан» журналы укучылары белән Яңа ел төнендә булган хәлләр.

БЕРВАКЫТ ЯҢА ЕЛДА

ЯЛГЫЗ КАРШЫЛАГАН ЯҢА ЕЛ

1990 елның 30 декабрендә мине Мөслим районына туйга чакырдылар. Шуган авылында төркемдәшем кияүгә чыкты. Туй бик затлы булды. Кунаклар да, сый-хөрмәт тә, кияү булырга яраклы егетләр дә күп иде… Кәләшнең дус кызына тагын нәрсә кирәк соң?! Ә икенче көнне, 31 декабрьдә, безнең барыбызны да авыл клубына Яңа елны каршыларга чакырдылар. Кәләш өендә йокымны туйдыргач, бизәнеп-ясанып, мин кияү белән кәләшне көтә башладым. Тик алар һаман күренмәде. Байтак авыл егете килеп, мине үзләре белән клубка чыгарга үгетләде, кайберләре хәтта тезләнеп ялварды. Минем бик барасым килсә дә, дус кызыма ышандырганга, һаман аларны көттем. Ә алар күренмәде, инде дустымның әнисе дә миңа егетләр белән клубка чыгарга кушса да, мин үз сүземдә тордым.

Табын әзерләп, телевизор карадык, иске елны озаттык. Дустымның әти-әнисе, курантлар сукканын да көтмичә, ятып йоклады – иртәнге сәгать дүрттә торып, терлек карыйсылары бар бит аларның. Мин генә мул табын артында берүзем ямансулап утырдым. Дус кызымның мине шулай тиз онытуы бик аянычиде. Яңа елны ялгыз каршылагач, ел буена ялгыз булырмын, дип тә кайгырдым…

Бәхеткә, алай булып чыкмады. Бу минем тормышымдагы беренче һәм соңгы ялгыз каршылаган Яңа елым булды.

Ирина Большакова, Чистай

КЫЯР – ЯШЕРЕН КОРАЛ

Бу вакыйганың герое – минем әтием – Беренче Украина фронтында сугышкан. 1943 елның 31 декабрендә аның отряды Кодня авылында булган. Җирле халык шундый шәп мәҗлес оештырган! Тик… кичкә таба көмешкәләре беткән. Әти һәм тагын ике сугышчы күрше авылга җыенганнар. Кычкырып җырлап баралар икән. Кинәт агачлар арасында күләгәләр һәм учак телләрен күреп алганнар. Немецлар! Яңа елны бәйрәм итүдән башлары әйләнеп, безнекеләр коралсыз да чыгып киткән була: үзләре белән – спиртлы фляга һәм тозлы кыяр гына… Кар көрте артында утыралар, немец итекләре астында кар шыгырдавы якынлашканнан-якынлаша бара. Нишләргә?! Әти кесәсендәге кыярны ала да, шуны граната кебек тотып: «Якын килмә, барыгызны да шартлатам!» – дип кычкыра. Немецлар да куркып кала: «Рус, атма! Таң аткач, китәбез без. Яңа ел бит! Әйдә безнең белән!» – дип кычкыралар икән. Әтием сагайган: «Сезнең янга килсәк, бездән колбаса ясыйсыз бит сез», – дигән. «Wasistdas колбаса, Kommandant?» – дип сораган исерек немец. Барысы да көлеп җибәргән. Учак янына бергә киткәннәр. Аларның «табынына» безнекеләр кыярларын китереп куйган. Рус сугышчысының үзләренә нинди «граната» белән янавын күргәч, немецлар тагын шаркылдый башлаган. Ике сәгать бәйрәм иткәннәр – Яңа ел төне дошманнарны да дуслаштырган. Могҗизалар булмый, диләр тагын…

Иван Саможенов, Әлмәт

«ТАТАРСТАН»НЫҢ ЯҢА ЕЛ МАҖАРАЛАРЫ



БЕР ОЧЫШТА ГАШЫЙК БУЛУ

Яңа елга өч сәгать кала мин әле халык белән шыгрым тулы залда ямансулап утыра идем – Бөгелмә аэропорты ябык, Казанга берничек тә очып булмас кебек. Әмма тоткарланган биш рейсның беренчесенә кинәт кенә утырта башладылар. Законлы урыным бишенче самолетта гына булса да, мин дә теркәлү урынына ашыктым. Бер матур кыз белән талаша-талаша, аның урынына утыру талоны алдым. Оялып торырга вакыт юк иде – Казанда табын янында яхшы танышым көтеп утыра бит…

Һавага күтәрелдек, ярты сәгатьтән башкала утлары күренә башлады. Ә тагын ярты сәгатьтән стюардесса һава шартлары буенча Казанның безне кабул итә алмавын, кабат Бөгелмәгә төшеп утыруыбызны игълан итте. Безнең белән очып китә алмаганнарның үзебезне нинди сүзләр белән каршы алганнарын күз алдына китерә аласыздыр, шәт! Бигрәк тә теге чибәр кыз ачуланды, минем турында нәрсә уйлаганнарын барысын да әйтеп бетерде!

Һәм хәзергә кадәр туктаганы юк әле – өйләнешүебезгә 35 ел булды инде! Һәр Яңа елда безнең табында шампан шәрабе янәшәсендә гаилә реликвияләре – «Дюшес» лимонады һәм йомшак сыр. Ул чакта аэропорт буфетында башка бернәрсә дә юк иде…

Равил Ибраһимов, Әлмәт районы

ЯЗМЫШ ШАЯРТУЫ

Яңа ел алдыннан мин солдаттан кайттым. Галәмәт зур планнар, исерткеч ирек хисе – бернинди «тормоз» да юк! Бәйрәмне дустым белән ике тапкыр каршыларга булдык. Беренчесен – Октябрьскида, башкорт вакыты белән, икенчесен инде өйдә, Мәскәү вакыты белән. Лениногорскига Октябрьскидан нибары бер сәгать барасы, ә вакыт аермасы – ике сәгать!

Башкортостанга мажараларсыз гына барып җиттек. Курантлар сукканда шампан шәрабе эчтек тә, өйгә, төп банкетка кайтырга чыктык. Баулыны үткәч, ниндидер чыршы астыннан ГАИ формасы кигән Кыш Бабайлар килеп чыкмасынмы! Йөртү таныклыгын һәм ачкычларны кесәләренә шудырдылар: «Иртәнгә кадәр ял итегез, егетләр…» – диләр. Ялынуларыбызга колак та салмыйлар. Унике туларга биш минутта машиналарына чакырдылар – янәсе, безнең очракны тикшерәләр. Аннары исә барысы да әкияттәгечә булды. Машинада – мандариннар, каз, радиода – «Кадерле россиялеләр…» Безгә – шампан шәрабе, үзләренә термостан чәй салдылар. Иртән өебезгә кадәр үз машинабызда илтеп куйдылар. Документларны һәм ачкычны кайтарып бирделәр…

Мин армиядән соңгы беренче Яңа елымны менә шулай каршыладым. Ел ничек башлана, шулай үтә дә, диләр… Хәзер, Яңа елда кизү торырга туры килсә, үзем белән мандариннар һәм берәр тәмле әйбер алам. Кунакларны нәрсә белән булса да сыйларга кирәк бит!

Владимир Петров, Лениногорск

«ТАТАРСТАН»НЫҢ ЯҢА ЕЛ МАҖАРАЛАРЫ

ЗӨЯДӘ БУЛГАН ХӘЛ

Бу хәл Зөядә совет чорында булган, диләр. 31 декабрьдә ике тракторчы кырдан печән алып кайтырга киткән. Салкын булган, озак кайнашканнар, караңгы төшкән. Кайтырга чыкканнар. Кинәт берсе тракторын туктаткан, кабинасыннан сикереп төшкән дә, икенчесенә кулы белән ишарәли башлаган. Икенчесе дә туктаган, иптәше күрсәткән якка караган. Ә анда, хәзер генә алар киткән җирдә, күктә чыршы балкый икән.

– Әй, Семеныч, без артыграк эчеп ташлаганбыз, ахры. Бу җен безнең арттан ияргәнче, әйдә тизрәк авылга! – ди икән берсе икенчесенә.

Тракторларын булдыра алганча куып, авылга кайтып җиткәннәр.

– Нәрсә булды сезгә? – дип сораган алардан карт бабай.

– Анда... кырда... чыршы! Һавада эленеп тора! Безнең арттан очып китә язды! Без шуңа ашыктык та!

– Әй аңгыралар да икән сез! Ул сезгә хәзинә яшерелгән урынны күрсәткән бит. Мондый хәл гасырга бер генә тапкыр була! – дип уфтанган бабай.

Тракторчылар кабат кырга киткән. Төн буе, таңга кадәр туң җирне казыганнар, Яңа ел икәнен дә онытканнар. Тик бушка тырышканнар...

Ә Зөя хәзиналәре кемнәргәдер хәзергә кадәр тынгы бирми.

Артём Силкин, Зөя утрау-шәһәре

ТРАМВАЙДА ТОСТ

Мин Яңа елны дусларым белән каршыларга җыендым, тик аңа кадәр бер кызны бәйрәм белән котларга киттем. Аның белән шугалакка бардык, шәһәр урамнарында йөрдек, йорты янына килеп җиткәндә, инде 12 туларга 15 минут кына калып баруы ачыкланды. Мин якындагы трамвай тукталышына йөгердем. Урамда бер генә машина да, бер генә кеше дә юк. Унике туларга биш минут кала трамвай килде. Иске салкын вагонда миннән кала тагын трамвай йөртүче, кондуктор хатын һәм мех бүрек кигән исерек ирдән башка кеше юк иде.

Нәкъ сәгать уникедә трамвай, киләсе тукталышка барып җитмичә, туктады. Йөртүче радио кабызды, кондуктор хатын кайдандыр шампан шәрабе һәм конфет тартып чыгарды, исерекне төрткәләп уятты. Без шампан шәрабе эчтек һәм бер-беребезне Яңа ел белән котладык. Аннары ир-ат, бүрегенең идәнгә төшеп киткәнен дә сизмичә, кабат йокыга талды, ә трамвай исә юлын дәвам итте.

Айнур Мөхәммәтҗанов, Түбән Кама

«ТАТАРСТАН»НЫҢ ЯҢА ЕЛ МАҖАРАЛАРЫ

ШАХТАДА, ТИК ОЛИВЬЕ БЕЛӘН!

Бервакыт без Яңа елны дустыбыз Лехаларда каршыларга җыендык. Әллә нинди уңышсыз көн булды ул – дустыбыз тубык сөяген каймыктырды, шәһәр читендәге без гел бәйрәмнәр үткәрә торган йортны да башкалар бронылап өлгергән иде. Яңа елга бер-ике сәгать кала без Лехаларга киттек, Маратны ризык төягән пакетлар белән аста калдырып, үзебез фатирга кердек тә, үзебезчә шаяртырга булдык – янәсе, дустыбыз лифтта бикләнеп калды. Леха нервлана башлагач, шаркылдап көлеп җибәрдек һәм, Маратка шылтыратып, безнең янга менәргә куштык. Көтәбез-көтәбез – ул һаман юк, телефоны да җавап бирми. Фатирдан чыгып, лифт чакырган идек, шахтадан Маратның тавышы ишетелә:

– Егетләр, нишлибез?! Лифтер иртән генә килә!

Без көч-хәл белән лифт ишекләрен бераз ачып, ризыкларны алдык, әмма Марат үзе бу ярыкка гына сыймады. Шунлыктан без Яңа елны лифт янәшәсендә каршыларга мәҗбүр булдык – дустыбызны шампан шәрабсез, оливьесыз, бер ялгызын калдыра алмыйбыз бит инде!

Шунлыктан, язмыш белән шаяртмагыз, бигрәк тә ул сезне кисәтмәкче булып, нindидер ишарәләр ясаган очракта. Әллә нәрсәләр булуы бар...

Лилия Светлова, Чаллы

МАМЫК САКАЛЛЫ БАБАЙ

Яңа 1979 елны мин институтның бушап калган тулай торагында ялгызым, кесәмдә бер тиен акчасыз каршыларга мәҗбүр булдым. Дусларым өйләренә кайтып китте, ә миңа Казанда калырга туры килде. Билетка, шампан шәрабе һәм мандаринга дигән акчаны, кыскасы, бөтен стипендиямне трамвайда ниндидер фокусчы урлады. Тик язмыш сиңа бәйрәм бүләк итүдән баш тарта икән, димәк, син аны үзең ясарга тиеш! Минем башыма әлеге даһи фикер Кызыл почмакта Кыш бабай костюмын тапкач килде. Димәк, кыздырган бәрәңге генә ашап утырырга туры килмәячәк – оливье һәм «сельдь под шубой» салатлары, бәйрәмчә йөз грамм да эләгәчәк дигән сүз! Башка – бүрек, җилкәгә – тун эләсең, борын астына сакал ябыштырасың да – әйдә, фатирлар буйлап алга!

Нәкъ шулай булып чыкты да. Беренче кергән фатирымда ук мине табынга утырттылар, туйганчы ашаттылар-эчерттеләр. Икенчесендә җырлаттылар, иске елны озаттык, Яңа ел хөрмәтенә тагын берне салдык. Өченчесендә исә... мин 1 гыйнвар иртәсендә йокымнан уяндым! Буш фатирда, хуҗалар яткырган диванда. Өстәлдә мондый язу ята: «Михаил, деканыгызны Яңа ел белән тәбрикләргә теләвегез куандыра. Кызганыч, котлавыгызның мәгънәсен аңлый алмадым, әмма ул ихлас булгандыр, дип уйлыйм. Ачкычны палас астына куеп калдырырсыз. Яңа ел белән!»

Михаил Петров, Чаллы

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН»НЫҢ ЯҢА ЕЛ МАҖАРАЛАРЫ

ЧӘНЕЧКЕЛЕ БӘХЕТ АГАЧЫ

Чыршы бизәлә, ә аның астындагы киез итек эченнән курантлар сукканнан соң һәркем Кыш бабай бүләген таба. Безнең гаиләдә шундый традиция, хәер, ул күп гаиләдә шундый уктыр. Әмма бер елны гел эш, калып эшләүләр, «аврал»лар белән әвәрә килеп, 31 декабрьдә кичке җиделәр тирәсендә генә, ниһаять, бушый алдым. Өйгә кайтып керсәм – кызым елый: «Әти, безнең чыршыбыз юкмыни?! Төнлә Кыш Бабай да килмәячәк бит инде алайса!» – ди. Сез минем урында нишләр идегез? Әйе, мин дә нәкъ шулай эшләдем, тиз генә киендем дә, базарга чыгып чаптым. Ә алар инде барысы да диярлек ябыла, бер җирдә дә бер чыршы да юк… Чехов базарында инде шактый салмыш ике ирне очраттым. «Чыршы кирәкмени? Мең сум бирсәң, ике сәгатьтән подъезд төбеңә китереп җиткерәбез», – диләр. Алдыйлар, дип уйласам да, башка чарам булмаганга, ризалаштым…

Өйгә буш кул белән кайттым, кичке сәгать унбердә чыршыны китереп җиткерәчәкләр, дим. Яңа елга бер сәгать калды – әлбәттә инде, чыршының исе дә юк! Үземне әчтән генә битәрлим. Ә тагын ярты сәгатьтән соң ишек шакыдылар. Күрше Рәфыйк икән: «Сезгә чыршы кирәкмиме ул? Миңа дусларым ни өчендер икене китергәннәр…» Яңа елга ярты сәгать кала бөтен гаилә белән бергәләп чыршы бизәүдән дә рәхәтрәк нәрсә юк икән ул…

Азат Тыйләҗев, Казан

БАСКЫЧТАН… ЙОЛДЫЗ ТАБУ

Бу хәл 70нче елларда булды. Ул Яңа ел кичендә бездә туй гөрләде. Таң алдыннан кәләшнең әтисе подъездда йоклап ятучы таныш түгел егетне уятып алып керде. Ленинградтан әнисе янына өй туена кайткан икән, тик кайсы фатир булуын оныткан. Ашаттык, идәндә яткан туганнарны бераз кысрыклап, йокларга яткырдык. Иртән ул әнисен эзләп тапты һәм икәүләп рәхмәт әйтергә керделәр. Чәй эчкәндә, бу тыйнак егетнең фамилиясе дә ачыкланды – Альберт Әсәдуллин үзе икән! Йолдыз, «Алтын Орфей» бүләге иясе, «Поющие гитары» вокаль-инструменталь ансамбле вокалчысы. Вакыйга әле моның белән генә тәмамланмады. Нәкъ бер елдан соң, миңа Ленинградка командировкага барырга туры килде. Альбертның туганы белән без бер заводта эшли идек, ул туганына күчтәнәч җибәрде. Әлбәттә инде, тапшырдым һәм үзебезнең кайчан танышуны да хәтеренә төшердем. Әй, сөенде дә соң! Берничә сәгатьтән мин инде Киров исемендәге театр партерында аның чыгышы белән хозурлана идем – ул Яңа ел кичендә «Фламандская история» рок-операсын куйдылар.

Сергей Артюхин, Казан

«ТАТАРСТАН»НЫҢ ЯҢА ЕЛ МАҖАРАЛАРЫ

«АЛЧӘЧӘК АЛЫП КАЙТ МИҢА!»

Бөтен кешегә Яңа ел, ә миңа – җәза! Хатынымның туган көне – 1 гыйнварда! Һәм инде кунаклар Иске елны озатып, Яңа елны каршылаганда ук, иртүк кайдан чәчәк табарга, дип баш вата-вата, мин тиз арада айныйм. Хәтерләсәгез, совет чорында кышын чәчәк табу кыен иде. Ә инде беренче гыйнвар иртәсендә аны табуның авырлыкларын мин үзем генә беләм. Чөнки миннән башка беркем дә Яңа елның тәүге таңында бөтен базарларны әйләнеп чыкмагандыр. Һәм инде чемоданында чәчәк яшерелгән туңып беткән көньяк кешесен очратканда, минем сөенечемә чик булмый иде. Көенечемә дә – суыктан күшеккән кунак космик бәя сорый. Сатулашу файдасыз: миңа яртылаш туңган канәфер чәчкәләре өчен хезмәт хакымның өчтән берен чыгарып бирергә туры килә...

Кайчандыр курантлар сукканда башланган интегүләрем чираттагы бер Яңа елны каршы алганда тәмамланды да. Бәйрәм табыны артында утырганда, хатынымның әнисе кызының туган көне чынлыкта 1 гыйнварда түгел, бәлки 9 декабрьдә булуын ычкындырды: кар күп булган, теркәр өчен ЗАГСка кадәр барып җитә алмаганнар...

Ул Яңа елда миннән дә бәхетлерәк кеше булмагандыр, мөгаен. Бик тиздән исә чәчәк кытлыгы искиткеч муллык белән алышынды. Тик бу бер дә аяныч түгел. Хәзер без хатынымның туган көнен елына ике тапкыр билгеләп үтәбез.

Илгиз Вафин, Казан

ТЫНЫЧЛЫК ҺӘМ ТЫНЛЫК ФЕЙЕРВЕРКЫ

Иң тылсымлы, онытылмас тәэсирләребез – 2016 елны каршылаудан.

...Урал. Беркем дә яшәми торган Катавка авылы. Биредә Интернет та, телевидение һәм хәтта радио да юк. Урамда – 35 градус салкын. Без мичтә кабак пешерәбез, иртүк урманга барыр өчен иске агач чаңгыларны ремонтлыйбыз. Урманда исә пошилар йөри, куян һәм кабан дуңгызы эзләре ярылып ята...

Төн уртасында без урамга чыгабыз. Күктә ай балкый, бенгаль утлары кабызабыз һәм тынлыкны тыңлап хозурланабыз – аны шәһәрдә берничек тә ишетеп булмый бит. Бер-беребезне тәбриклибез, кочаклашабыз һәм барыбызга да гаҗәеп теләк телибез – Яңа елда хәтта көндәлек ыгы-зыгыда да тынлыкны табарга һәм тыңларга насыйп булсын, дибез...

Быел декабрь азагында без тауларга барабыз. Шул ук компания белән, чөнки былтыргы Яңа ел төне искиткеч булган иде!

Надежда һәм Роман Насыйровлар, Казан

КЫШ БАБАЙДАН – ТУТЫРГАН ТАВЫК

Кешелек тарихында беренче тапкыр Кыш Бабай белән балалар түгел, ә олылар очрашты. Чөнки өлкәннәрнең дә бәйрәм итәсе, могҗизага ышанасы һәм мәрхәмәтле тылсымчы үзе әзерләгән сихри нигъмәт белән сыйланасы килә.

Әйе-әйе. «Татарстан» үзенең кулинария репортажын Арча районы Яңа Кырлай авылында урнашкан Кыш Бабай резиденциясеннән алып бара. Кыш Бабайның йорты затлы, ул Габдулла Тукай музее белән бер бинада урнашканга, биредә һәрвакыт кунаклар күп була. Әгәр инде балалык яшеннән чыккан кунакларның буе озын булып, кайбер бүлмәләргә сыймасалар, Кыш Бабай аларны «Кырлай» ресторанына алып бара, анда алар еш кына Кар Кызы белән бәйрәм сые әзерлиләр.

Автор:
Татьяна Вафина

ТЫЛСЫМЛЫ АШЪЯУЛЫКСЫЗ...

– Мин Галәветдин дустымнан тылсымлы ашъяулыгын да сорап тора алыр идем, әлбәттә, – дип шаяртa Кыш Бабай, – әмма кадерле кунаклар өчен бәйрәм сыен бабайлар ысулы белән, сихерсез генә, үземнең әзерлисем килә.

Тик барыбыз да барыбер ниндидер тылсымга өметләнәбез – тикмәгә генә тылсымчыда кунакта түгел бит без.

– Без туңдырма ясыйбыздыр инде? – дип кызыксынабыз. – Ул сезнең яраткан ризыгыгыз диләр бит.

– Чынлыкта мин күп нәрсә яратам: туңганын да, туңмаганын да, – дип елмая бабакай. – Бигрәк тә үзебезнең милли ризыкларга – чәкчәк, өчпочмак, гөбәдиягә мөкиббән китәм... Сез чәкчәкнең тарихын беләсезме? Хәзер мин сезгә сөйлим. Бервакыт Чыңгыз хан ерак юлга чыгар алдыннан аш пешерүчеләренә бозылмыйча озак саклана торган ризык уйлап табарга боерган. Һәм алар чәкчәк – бал белән катырылган таякчыклар пешергәннәр. Тәмле дә, озак саклана да. Һәм берниндi пальма мае да кирәк түгел.

Татарларның тагын бер бәйрәм сые – бик тәмле каклаган каз. Яз башыннан Сабан туена кадәр каклана ул. Ә бәлеш? Бәлеш яратасызмы сез? Аеруча тантаналы очракларда пешерелә анысы. Гадәттә Яңа елның беренче көнендә әзерләнә. Кайбер районнарда, мәсәлән, Кукмарада, бәрәңге урынына борай кулланыла. Әле тагын тәбикмәк бар – гади төче камырны табада кыздырасың да, менә дигән ризык килеп чыга...

– Бабакай, син тәмлетамак икән!

– Шулайрак шул. Сыйланырга да, сыйларга да яратам. Ә бүген без Кар Кызым белән сезгә бик тәмле татар халык ризыгы – тутырган тавык әзерләрбез. Бәйрәм сые! Бары тик кадерле кунаклар өчен генә!

– Моның өчен безгә бик шәп авыл тавыгы, 6 йомырка, ярты стакан сөт, бераз тоз, кишер һәм 1 аш кашыгы он кирәк булачак, – дип сүзгә кушыла Кар Кызы.

Фото: Ната Смирнова

«ТАТАРСТАН»
МАХСУС
журналы өчен
ТАТАРСТАН
СПУТНИК АГИТАТОРА
ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН

PRESSA.RU



Безгә кирәк булачак:

- Тавык – 1 данә.
- Йомырка – 6 данә.
- Кишер – 1 данә.
- Он – 1 аш кашыгы.
- Сөт – 0,5 стакан.

ТАВЫКНЫҢ ТИРЕСЕ ЕРТЫЛМАСЫН

Кар Кызы тавыкның аскы ягын ак җеп белән тегә, аннары сак кына тиресен итеннән куптара.

– Ничек тә ертмаска тырышырга кирәк, чөнки бик кадерле кунаклар өчен әзерлибез бит. Тишелмәгәнен тикшерү өчен, тире астына өреп карыйбыз. Ит белән тире арасындагы буш урын кирәк безгә.

Кыш Бабай бу вакытта үзенең кызын мактый, ул бик оста да, акыллы да, зирәк тә икән.

ТУГАНЛЫК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ

Без исә шул арада туганлык мөнәсәбәтләре белән кызыксынабыз: ни өчен Снегурочка Дед Морозның оныгы, ә Кар Кызы Кыш Бабайның кызы? Дед Мороз белән туганлыгы бармы? «Татарстан» корреспондентларын һәм халкын тагын Кыш Бабайның җәмәгатенең кайда яшәве дә кызыксындыра.

Кыш Бабай әйтүенчә, Дед Мороз аның олы абыйсы икән:

– Мин 18 ноябрьдә Великий Устюгка аның туган көненә бардык, Россиянең барлык төбәкләреннән һәм чит илләрдән бөтен агай-эне җыелган иде: Удмуртиядән Тол Бабай, Карелиядән Паккайне, Финляндиядән Йоулупукки, Болгариядән Дядо Мраз, Казахстаннан Аяз-ата, Чехиядән Микулаш... Бик күбәү без – суык туганнар. Кемдер оныгы белән килгән иде, кемдер – кызы белән. Дед Мороз резиденциясендә безне аның хатыны – Баба Жара каршы алды. Ә минем хәләл җефетемнең исеме – Кар Әби.

Бик дәрәҗәле кунаклар да күп иде – Берендей патша, Вятка (Нократ) бичурасы, Кострома Кар Кызы...

– Колотун Бабай бар идеме соң?

– Булмый ни! Бар иде әлбәттә. Чынлыкта аның исеме Чысхаан – Суык хакиме. Ул бик салкын һәм могезле. Якут риваяте буенча, Салкын Үгезе кышны үзенең сулышы белән тудыра. Ел саен үзенең туган көне алдыннан Дед Мороз, Якутскига барып, Чысхаан (безнеңчә Колотун бабай) кулыннан салкын символын ала, шуннан соң инде кышның илебез буйлап сәяхәте башлана.

– Без белмәгән әллә ниләр бар икән бу дөньяда! Менә нинди икән бу тылсымлы тормыш!

1. Тегәбез!

2. Өрәбез!

3. Ватабыз!

4. Туглыйбыз!

5. Агызабыз!

6. Бәйлибез!

КАР БӨРТЕГЕ ЭРЕГӘНЧЕ...

Шулкадәр тәфсилле мәгълүматтан соң, эчлек әзерләүгә күчәбез.

Йомырка белән сөтне туглап күпертергә кирәк. Безгә кар бөртеге Самира ярдәм итә – аның ачык форточкадан очып кергәнен күрми дә калганбыз. Самира эрергә өлгергәнче, бик тиз тугларга кирәк – Кыш Бабай кухнясының сере шунда.

Әзер эчлекне ипләп кенә тавыкның эченә һәм тиресе белән ите арасына тутырабыз. Бу эш бик җаваплы, шунлыктан бары тик Кыш Бабайга гына ышанып тапшырыла:

– Бисмилләһир-рахмәәнир-рахииим! Булды бу!

– Тавыкның түш ите корырак булганга, тәбә аны йомшартачак һәм сусылрак итәчәк.

Муенын җеп белән бәйләп, формасын саклар өчен, тавыкны марляга төрәбез һәм 2 сәгатькә кайнап торган шулпага салабыз, шунда ук чистартылган кишерне дә салып җибәрәбез.

7. Төрәбез!

8. Суга салабыз!

9. Алабыз!

10. Бизәкләр кисәбез!

11. Бизибез!

12. Теләкләр телибез!

PRESSA.RU

Тавык пешкән арада мәрхәмәтле тылсымчылар тормышы белән танышуыбызны дәвам итәбез.

– Мин декабрьнең иң озын төнендә туганмын. Шунлыктан һәрвакыт елның иң салкын фасылы белән идарә иттем, бәйрәмне күңелле үткәрү өчен җаваплы булдым. Мин һәрчак үземнең яраннарым белән йөрим: Кар Кызы, татар халык әкиятләре геройлары – ярдәмчем Шүрәле, Аждаһа, Батыр, Алтынчәч, Таһир белән Зөһрә. Минем резиденциям 3 декабрьдән эшли башлый. Әмма биредә эләгү җиңел түгел. Килүчеләрне урман таможнясы – шайтан балалары каршы ала.

Алар кунакларның нинди ният белән килүен тикшерә. Усал ният белән килүчеләр кермәскә тиеш. Кунаклар урман сукмагыннан баралар, анда аларны төрле сынаулар көтә. Бары тик шуннан соң гына минем яныма керә алалар. Йортымда төрле тылсымлы әйберләр бар. Мәсәлән, пышылдау тыңлаучы имәннәр: бәләкәй, уртача һәм зурлар. Аларга теләгеңне пышылдап кына әйтергә кирәк: кечкенәсенә – кечкенә теләкләрне, уртачасына – уртачаларын, зур теләкләрне исә зур имәнгә әйтү зарур.

– Барыбызга да теләк теләргә ярыймы? – дип җанланабыз без.

– Барыгызга да, тик чын йөрәктән булсын. Теләкләрне тылсымлы баскычта да теләргә була: һәр баскыч саен – бер теләк!

Әле тавыкның тагын бер сәгать пешәсе булганлыктан, резиденциягә теләк теләргә йөгерәбез.

КҮҢЕЛ ТҮРЕНДӘГЕ ТЕЛӘКЛӘР

Миңа хат язучылар бик күп. Бөтен Россиядән, якын һәм ерак чит илләрдән язалар. Балалар да, өлкәннәр дә. Күбесе миңа сәламәтлек тели. Күп баланың бүләккә айфон аласы килә. Кызлар Винкс курчагын сорый. Малайларга «Лего» җыелмалары кирәк. Күптән түгел бер кыз велосипед сораган иде – кичә кибеткә барып, сайлап алып кайттым. Сәер теләкләр дә була: беркөнне бер кыз үзенә өч яңа теш үстерүемне үтенде. Бер ир-ат исә диссертациясен яклаганда ярдәм итүемне теләде! Мондый очракны да хәтерлим: бер кыз миңа хатлар язган да язган, тик әнисе ни өчендер җибәрмәгән. Бу турыда белеп алгач, ул хатны дус кызыннан җибәрттергән, чөнки үзе йөри алмаган. Хатны алгач, без барыбыз да бергә авылдагы Зөлфия янына киттек. Безне күрергә бөтен авыл җыелды. Айфон бүләк иттек үзенә. Кыз бик шатланды, ә без аннан да ныграк сөендек, канатлар үскәндәй булды үзебезгә. Кешенең яшерен хыялларын тормышка ашыру шулкадәр рәхәт! Миннән кияү сораучылар да булгалый. Йөкле хатыннар исә сабыйлары исән-сау тусын дип теләк тели.

– Гафу итегез, ә кияүләрне кайдан табасыз?

– Мин тылсымчы бит! Ихластан теләк теләсәң, ул һичшиксез үтәләчәк. Әкият бөтен җирдә бар ул.

ЗУР ИМӘННӘН – ЗУР ПОДПИСКА!

– Кыш Бабай, синнән яңа елда «Татарстан» журналына язылучыларның артуын сорасак ярыймы? Зур имәннән зур подписка сорыйк әле?

– Чын күңелдән сорыйсызмы соң?

– Безнең ихлас «Татарстан» күңеленнән!

– Ярар алайса, үтәлер бу теләгегез!

Безнең теләгебез әкренләп үтәлә башлагач, киләсе елдагы зур тиражлар белән канатланып, канәгатьләнеп, тавык янына, кухняга кире кайтабыз.

– Балалар ничә яшьтән Дед Мороз һәм Кыш Бабайларга ышанмый башлый? – дип кызыксынабыз бабайдан.

– Төрлечә булырга мөмкин. Менә мин күптән түгел 33 яшьлек хатын-кыздан хат алдым. «Мин синең барлыгыңа ышанам, Кыш Бабай, – дип яза ул. – Һәрвакыт могҗизага ышандым!» Ул миннән бернәрсә дә сорамаган, үземә генә сәламәтлек теләгән. Мин укыганда эреп китә яздым. Күңелебез белән без барыбыз да – бала-чага. Әгәр могҗизага, әкияткә ышанмасак, Татарстаныбыз шундый бай, яшәү өчен шундый уңайлы булыр идемени? Юктыр мөгаен. Өмет тә, тырышлык та кирәк.

КЫШ БАБАЙ ХЫЯЛЫ

Шулпадан тавыкны алып, аны кишердән ясаган чәчәкләр белән бизәгәндә, без Кыш Бабайның да хыялы булуын белдек. Ул үзенең резиденциясе турында хыяллана икән.

– Хәзер без резиденцияне Тукай музееннан арендага алып торабыз. Тик безнең үз йортыбызны булдырасыбыз килә, анда без ел буена барлык әкият бәйрәмнәрен уздырыр идек. Хыялланабыз әлегә. Башкаларның теләк һәм хыялларын тормышка ашырам, үземнекенә әле җитешеп булмый.

БЕР-БЕРЕБЕЗНЕ МАКТАШЫЙК

Тутырган тавык әзер!

– Мондый матур һәм тәмле сый абруйлы «Татарстан» журналыннан килгән кунакларыбыз өчен генә! – ди Кыш Бабай, тавыкны кисәкләргә бүлә-бүлә.

– Безнең өчен әле беркайчан да хөрмәтле Кыш Бабаебызның ризык әзерләгәне юк иде, – дибез без, искиткеч тәмле, авызда эри торган тавыкны авыз итеп. – Рецептны кайдан алдың, Кар Кызы?

– Кайданмы? Ютубтан! – дип көлә Кар Кызы. – Без бит, тылсымчы булсак та, заманадан артта калмыйбыз. Хәтта үзебезнең сайтыбыз да бар.

– Яңа ел белән, «Татарстан» журналын укучылар! Яңа ел белән, Татарстан халкы! – дип тәбрикли безне Кыш Бабай. Тутырган тавык исә безнең авызда эреп югала бара. Күтәренке бәйрәмчә кәеф белән без мәрхәмәтле тылсымчылар белән хушлашабыз һәм сезнең барыгызга да күңел күтәренкелеге телибез, сезгә Кыш Бабай өйрәткәнчә тутырган тавык рецептын җиткерергә ашыгабыз. **T**



Дорогим читателям журнала „Татарстан" и жителям Республики:
Желаю вам счастья и здоровья.
Пусть в ваших сердцах живет любовь и добро, а к лицам озаряют улыбки. Надеюсь вы полюбили нашего Кыш Бабая и это сказочная дружба будет основой для свержения [illegible] добрых, славных дел.
С наступающим Новым годом, уважаемые земляки. Кыш Бабай һәм Кар кызы.

PRESSA.RU

Язылh һәм телевизор от!

1 Языл
30.12.2016 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә 3 басмасына языл *(акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)*

2 Җибәр
язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр *(телефон номерыңны күрсәтергә онытма)*: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 От
телевизор, фотоаппарат h.б. бүләкләр отарга ашык!

Акцияне үткәрү вакыты: 20.10.2016 - 20.03.2017

Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында
Оештыручысы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222-09-84, өстәмә номер - 1261

16+
Реклама

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Нью-Васюкины **НИ ӨЧЕН** Тәтеш дип атамаганнар?

Яман бай авыл **КАЙДА** урнашкан

Иң яхшы чыпталарны **КАЙСЫ** авылда ясаганнар

Серле болгар калалары **НИ** көтә

Үз биеклегеңдә **НИЧЕК** калып була

Китап киштәсендә **НИЛӘР** бар

Хәзинә эзләүче 77 кеше **КАЙДА** үлгән

PRESSA.RU

ҖИРДӘГЕ ИҢ ШӘП УРЫН!

ТӘТЕШ: «НЬЮ» КУШЫМЧАСЫЗ ГЫНА...

Кышны Тәтештә каршылау күңелле. Ябалак-ябалак яуган йомшак кар акрын гына шәһәрчекнең тар урамнарына, йөз яшәр сәүдәгәр йортларының түбәләренә түшәлә. Тирә-юньдә – рәхәт тынлык, саф һава...

Тәтеш берничә гасыр дәвамында өяз шәһәре булып исәпләнә. Бу статусны аңа XVIII гасырда Екатерина патшабикә биргән. Шуннан бирле ул аңа «ябышып» калган. Җирле халык Ильф һәм Петров үзләренең мәшһүр Нью-Васюкиларын нәкъ менә Тәтештән алып язган дип исәпли – бирендә булып кайтканнан соң, Илья Ильф бу хакта көндәлегендә язып калдырган. Шахмат клубы да бар монда. Дөрес, күрше Мари Республикасының Козмодемьянск шәһәрендә яшәүчеләр вакыт-вакыт бу фаразга карата бәхәс куертып ала, әмма без бит Васюкиның уйлап чыгарылган гына икәнен беләбез, шуңа күрә тик бәхәсләшсеннәр шунда...

Маяковский да мәгълүм шигырендә буржуйларга шушыннан торып янамады микән әле:

Күреп торырсыз, Тәтештә
Нью-Йорк булачак...

Борынгы Тәтеш бөек Идел елгасы ярының иң матур урынында әле һаман да «нью» кушымчасыз гына яшәп ята. Бу яклар элек-электән балыкчылык белән дан тоткан. Пристаньдә зур-зур балык амбарлары урнашкан булган, ул балыкларны салда елга буйлап туп-туры патша өстәленә агыза торган булганнар.

Ә 1921 елны тотылган 960 килолы гигант кырпы балыгы тарихка ук кереп калган. Аның аклы-каралы фотосурәте музейда саклана. «Ул балыктан 12 пот уылдык алганнар, ә ашказаныннан бер капчык кысла, чөгә һәм җумба балыклары чыккан», – дип сөйли крайны өйрәнүчеләр. Гигант кырпыга һәйкәл дә салганнар – ул бүген дә Тәтешнең иң истәлекле урыны булып исәпләнә.

Гомумән, Остап Бендер «аталары»ның Нью-Васюки – Тәтештә галактикаара шахмат ярышлары уздыру хыялы һәм Маяковскийның бу урынны Нью-Йоркка әйләндерү теләге булса да, без Тәтешнең бүгенге кебек җирнең матур бер почмагы – һаман да шундый өяз шәһәрчеге булып калуын телибез.

Фото: Ната Смирнова

ТӘТЕШ:
КҮР ӘЛЕ, СИН ЯШӘГӘН ДӨНЬЯ НИНДИ МАТУР!

PRESSA.RU

PRESSA.RU

Кариле — Шушмабаш

«Татарстан» журналы, кызыклы атамалы татар авылларын, аларның тарихын һәм бүгенге яшәешен яктырту максаты белән, яңа сәхифә башлады. Сез дә безгә үз авылларыгызның хикмәтле яклары, гыйбрәтле хәлләре, уңган-булган кешеләре турында яза аласыз.

Балтач районы Кариле авылы

PRESSA.RU

ЯМАН БАЙ АВЫЛ

«Татарстан»ның кышкы санында «кышкы» авыл турында язсак, дөресрәк булыр, дип уйлаштык та Балтач районы Кариле авылына юл тоттык. Бу сүзне ике өлешкә таркатсак, «кар иле» дигән сүзтезмә килеп чыга. Анда кар, башка җирлекләргә караганда, күбрәктер, хуҗалык саен Кыш бабай торадыр, дип уйлаган идек. Баксаң, саланың атамасы килеп чыгышында кышның бер катнашы да юк икән.

Автор:
Линар Закиров

ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ТОРБАЛАР ЯСАУЧЫ

Кариле яман матур, бай авыл булып чыкты. Бу сүзне моңарчы тискәре мәгънәдә кулланган рәвештә генә ишеткәнем бар иде. Ә Балтач якларында бу сүз «бик» кисәкчесе буларак йөри.

25 яшьлек Нияз Камалов сәләмә ызба янына берничә катлы коттедж җиткереп куйган. Иске йортны тик яткырып булмый, дип 2013 елдан шунда сутөшергечләр белән төтен торбалары ясый башлаган. Җитмәсә, әтисе белән сервиста машиналар ремонтларга да җитешә. Өен дә, кеше яллап түгел, үзе җиткергән.

Остаханә бүлмәләре торбалар һәм калай кисәкләре белән тулган. Нияз башта кирәкле җиһазлар сатып алган да, сутөшергечләрне шартына туры китереп ясар өчен, берничә ай өйрәнгән. Үзенә һәм тагын берничә кешегә эшләп биргәч, башкалар да, күреп, кызыксына башлаган.

– Бу станоклар сутөшергечләр ясау өчен генә уйланылган. Салавычтан бер кеше, төтен торбаларын йортның түбә төсеннән эшлик әле, дип килде. Шушы ук станокларда калайны кирәгенчә бөгеп, торбаларны шулар белән төрдек. Бик матур килеп чыкты, – диде әңгәмәдәшебез.

Шәхси эшкуар булып теркәлгәч, Нияз үз куллары белән ясаган җиһазларны район кибетләренә сатуга чыгарган. Күптән түгел ул төтен торбаларын төрле төсләргә буйый башлаган. Бу алымны яңа технология, дип атый. Үзенең яңа өй түбәсен дә «ноу-хау» бизәп тора.

Заказлар күп килгәнлектән, ул иптәшкә Янгул авылыннан Раушан исемле егетне дә алган. Янгын сүндерүче булып эшләүче егет йә сменадан соң, йә ялларда дустына килеп булыша. Егетләр өйнең бер комплект торбасын ике көндә әзерләп бирә. Яңгырлы чорда сорау зур, җиргә кар яткач, егетләрнең эше кими.

– Хәзер яңгырлар сирәгрәк ява. Сутөшергечләр үз популярлыгын югалта бармыймы? – дим.

– Алар җәй көне яңгырдан гына түгел, яз көне эрегән кардан, боздан сакларга булыша. Сутөшергечләрне өйне матурлау өчен дә ясаталар. Кешеләр ишегалды бакчаларында чәчәк утырта, әз генә яуган яңгыр да аларның төбен казып бетерә. Торбалар исә шуңардан да саклый, – дип аңлатты яшь оста.

Фото: Ната Смирнова

Ниязның яшь эшкуарларга бирелә торган субсидияләрне алганы гына түгел, кызыксынганы да юк. «Кешегә дә, дәүләткә дә тиеш булып каласым килми», – ди ул.

– Хәзер авылда яңарыш чоры, кеше рәхәт, бай яши. Эш булса, кеше читкә китми. Кариле янында инеш, Шушма елгасы ага. Су буенда ял итәм дисәң, яман рәхәт! Элек кыш көне егетләр белән су буена төшеп, боз өстендә хоккей уйный идек. Мөмкинлеге булган кеше кәшәкәне сатып ала, кемдер агачтан үзе ясый иде. Хәзер уйнаучы калмады инде, – ди Нияз.

Аның ике кызы үсеп килә: Динәгә – 4 яшь, Ясминәгә – 2 яшь.

– Кызларның әти тәрбиясе күрә алганы юк әле. Бөтен хуҗалык һәм тәрбия эшләрен хатыным Фирүзә үз өстенә алды, – диде әңгәмәдәшебез.

– Балаларга Яңа елга нәрсә бүләк итәчәксез?

– Курчак инде. Кызларга тагын нәрсә кирәк, – дип елмайды Нияз. Аның үз авыл атамасы турында бер дә уйланганы юк. Аның каравы, күрше Норманың исеме нинди мәгънә белдерә икән, дигән уй тынгы бирми аңа.

– Чаманы белдерә торган русча «норма» сүзеннән барлыкка килмәгәнме икән? Һәрхәлдә, Нормада «нормаль»ный кешеләр яши, – дип көлкеле рухта тәмамлады ул сүзен.

КУРКУЫН ҖИҢҮЧЕ

Йосыповларның терлек абзарына кергәч, сигез сыер, күзләрен челт-мелт йомып, безгә сәлам бирде. Рәисә апа сөйләвенчә, ул кечкенә булганда әнисе сыер тотмаса да, унлап сарык, кырыклап куян асраган. Әнисе эштә чакта мал-туарны кечкенә кызчык әбисе белән бергә караган. Кияүгә чыккач кына, хуҗабикә ире белән ике баш сыер алырга җөрьәт иткән.

– Ир-ат булмаган гаиләгә мөгезле эре терлек тоту кыен бит ул. Иң курыкканым – ирем эчкече булмасын, дидем. Бәхеткә, җәмәгатемнән уңдым, балаларым да акыллы, тәртипле. Кышка кергәч, иремне сугымга чакырып торалар, бу эш тә азмы-күпме керем китерә. Без үскән заманда сыер асрау бик авыр эш иде. Дөресен әйткәндә, гомер-гомергә сыердан курыктым. Кияүгә чыгып, беренче сыерны алып кайткач, аны күрүгә, өйгә кереп качтым. Көтү кайтканда да ишегалдына кереп поса идем.

– Куркуыгызны ничек җиңә алдыгыз? – дип, кызыксындым бүген сигез сыер асраучы Рәисә Йосыповадан.

– Хайваннарны бик яратам. Сыерыбызны башта күрше хатыны саугалады, аннары үзем батырчылык иттем. Кул ияләнгәнче, имчәген катырак тартырга да куркасың. Башыңа төшкәч, савасың инде. Терлектән курыкмаска кирәк, алар бит сизә. Хәзер сыерларны аппарат сава. Аны алырга дәүләт субсидия бирде. Элек печәнне авыл халкы үзе чабып әзерләсә, хәзер сатып кына алалар. Без дә быел 80ләп рулон терлек азыгы алдык. Алты сыер бозауларга тора әле. Бәләкчәләр өчен аерым абзар бар. Авыл җирлегендәге яшь җитәкчеләргә сокланып туя алмыйбыз. Бәлки, картая-картая усалланырлар, тик яшь чагында әйбәт эшлиләр. Авыл советы беркайчан да аяк чалмый. Аппарат өчен субсидия алганда да яман тиз эшләп бирделәр, – диде хуҗабикә.

Сигез баш сыер асраган өчен, хөкүмәт Йосыповларга һәм Кариледәге тагын бер гаиләгә абзар төзү өчен 200 мең сум биргән.

– Авыл көтүен шушы ике гаилә генә саклап калды, – дип сөйләшүгә кушылды Норма авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Алмаз Рамазанов. – Ике гаиләдән көтүгә 15ләп сыер чыга. Аларга карап, авылдагы башка кешеләр дә терлек санын берәр башка арттырды, – диде ул.

Кариледә көтүгә 40–50 баш сыер чыга. Халык чират буенча көтә. Рәисә апа сөйләвенчә, элек, җәй көне көтү бер-ике тапкыр гына эләккәч, аңа бәйрәмгә хәстәрләнгән кебек әзерләнгәннәр. Кибеттән тәм-том алып, тәмле ризыклар пешереп, кичтән мәш килеп җыенганнар.

– Терлек тоту үзен аклыймы соң? Чыгымы да күп бит... – дип мәсьәләнең матди ягын да кузгаттым.

– Ә кая барып эшлисең? Дәүләттән 5–6 мең сум хезмәт хакы алып, көне буе шунда ятасың. Ә үз хуҗалыгыңда иртән ике сәгатеңне эшләп керәсең дә төшкә кадәр өйдәге бөтен эшеңне башкарасың, барасы җиреңә барасың. Өч ел элек эштән киттем. Аңарчы 14 ел хат ташыдым. Көндезге унбердә китеп, пенсияне өләшеп чыкканчы, кичке сигезләр җитә. Ул вакытта почтальонның эше күбрәк булды, хәзер хезмәте бермә-бер җиңеләйде, – диде.

Аның әйтүенчә, башка авыллар белән чагыштырганда, Кариледә халык, хәтта әбиләр дә интеллигентрак. Кешеләр бер-берсен сөйләми, гайбәт чәчеп йөрми. 14 ел эчендә Рәисә апаның беркем белән дә ачуланышканы булмаган.

ТАГЫН БЕР КАРАШ

Балтач районындагы Кариле авылының исем-атамасы кара + иле сүзләре кушылмасыннан тора. Кара сүзе монда төньякны аңлата, иле – авыл мәгънәсен бирә, ягъни каралар иле. Кара – төрки, аерым алганда нугай этнонимы. Ногайларның кара һәм ак төркемнәргә бүленүе турында сүз булган иде инде. Телләре дә ак ногай һәм кара ногай диалектларыннан тора. Кара иле/Кариле атамасы алган авыллар Ставрополь һәм Әстерхан ногайларында да бар. Димәк, бу урыннарга ногайларның төньякны белдерә торган кара төркемнәре килеп утырган. Күршедә генә тагын Карадуван авылы урнашкан.

Фирдәүс Гарипованың «Авыллар һәм калалар тарихыннан» китабыннан (I том, 2001 ел)

PRESSA.RU

– Кариледән яшьләр бүтән авыллардагы сыман качып бетми. Күбрәк егетләр кала, кызларга эш юк бит...

Шулай да авыл төзек, матур, урамнарыннан йөрергә рәхәт бит, – дип хисләнде әңгәмәдәшебез.

УЛЫНА БИШЕК ЯСАУЧЫ

Авылның тагын бер алтын куллы кешесе – 24 яшьлек Фәнзил Хәкимов. Остаханәсе урнашкан гаражга килеп кергәч, дивардагы тәрәзә йөзлекләренең чуарлыгыннан күзләр камаша башлады.

– Шәһәрдә укып та, яшәп тә караган кеше түгел мин, күңелем гел авылга, табигатькә тарта. 2009 елда Норма мәктәбенең тугыз классын тәмамлагач, лицейда тракторчы, поварга, эретеп ябыштыручыга укыдым. Тәрәзә йөзлекләре белән алты-җиде ел элек мавыга башладым. Бөрбаш авылыннан Рамил абый аларны калайдан күптән эшли иде инде. Аңардан тәрәзә йөзлеге ясатып алдык та, шуңа карап, үзебез дә бу эшкә тотындык, – дип сөйләде яшь оста.

Кариленең күпчелек йортларында калай тәрәзә наличниклары эленеп тора. Татарлар аларны өй төсенә туры китереп ясатса, күрше төбәктә яшәүче марилар чуарлыкка тартыла. Фәнзил әйтүенчә, республика халкы калайга күнегеп кенә килә. Әйтик, әнисенең туган ягы – Әгерҗе районында һаман да агачка тугрылык саклана. Юкса, калай йөзлекләр 25 елга чыдый, диде оста.

– Үзем генә җитешми башлагач, мәдрәсәдә укытучы дустымны ярдәмче итеп алдым. Төрле вакытлар була, бәйрәм, Сабантуй алдыннан заказ бирүчеләр, читтән кунаклар кайта, дип ашыктыра. Авылда тәрәзә йөзлекләре ясаучылар күп, көндәшлек зур, – дип аңлатты Фәнзил.

Ул бер ай элек кенә туган икенче малаена бишек ясап биргән. Бала экологик чиста җайланмада тирбәлеп үсәчәк, дигән сүз.

– Әти-әни безне, эшләтеп, мәчеткә йөртеп, иманлы итеп үстерде. Шуның аркасында тормышка тизрәк җайлаштык. Балаларыбызга да шундый тәрбия бирәчәкбез. Эшлим дигән кешегә эш бетми. Тырышлык кына кирәк. Бернәрсә дә зурдан башланмый. Мин бу эшне башлап җибәргәндә, гаражда бернәрсә дә юк иде, – диде алтын куллы егет.

– Кариледә кар күпме соң? – дип сорап куйдык.– Элеккеге кебек карлар юк инде бүген. Балачакта инеш буеннан кайтып керми идек. Кышын балык тотарга да йөрдек. Хәзер өйдән чыгып китеп булмый шул.

Тимур Гатауллин, Норма авыл җирлеге башлыгы:

– Безнең җирлеккә алты авыл керә. Кариле халкы тырышлыгы, бердәмлеге белән аерылып тора. Бу якта эшмәкәрләр дә күбрәк. Өмәләргә бөтен авыл белән чыгарга тырашалар. Мәчет карты Фаил Зәйнуллин ике көнгә бер, сельсоветка кереп, саланың проблемаларын барлап чыга.

Кариледә кеше саны арта, өй салабыз, дип җир сораучылар күп, бигрәк тә яшьләр арасында. Былтыр авыл халкы белән күңелле чара оештырдык: олысы да, кечесе дә чана шуды, музыка уйнап торды, коймак, пылау пешерелде. Кариледә дин дә көчле. Быел урамлап ифтар оештырдылар.

ТАРИХНЫ БАРЛАУЧЫ

Гөлсем Миңнебаева авылның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге өчен җан атып йөри. 1972 елдан 2001 елга кадәр Нормада математика укыткан. Ул киткән елны мәктәптә алты авылдан 640 бала укыган (бишенче класслар бишәү булган!), 70 укытучы эшләгән. Хәзер андый саннар белән мактанып булмый шул.

Гөлсем апа әйтүенчә, авыл атамасының килеп чыгышы турында ике фараз бар. Беренчесе атаклы Карабай нәселенә бәйле. Өч улының берсе Мөхәммәд исемле булган. Аның нәселе XVI гасырда хәзерге Кариле якларына килеп төпләнгән, дип әйтелә. Авылда бүген дә Карабай туганнары гомер кичерә. Фәнни хезмәтләргә таянып, авыл кешеләре аның нәсел шәҗәрәсен төзеп, 40нчы буынга кадәр җиткән. Анда әле күптән түгел генә дөньяга аваз салган Зифа исемле кызчык та кергән. Гөлсем Әдһәмовна әйтүенчә, Карабай Нократ татарларына нигез салган, аңарчы ул якларда мөселманнар булмаган, марилар белән чуашлар яшәгән.

Икенче фараз буенча, авылның исеме «карый» сүзенә бәйле, гарәпчәдән Коръәнне яттан белүче дип тәрҗемә ителә. Ләкин Кариледә андый кеше яшәве турында бер мәгълүмат та юк.

– Кечкенә чагымда тарих укытучысы булып эшләгән класс җитәкчебез Флера апа бездән авылда сакланып калган борынгы әйберләрне: савыт-саба, акчалар җыйдырта иде. Безнең чор кешеләре тырышлыгы белән кечкенә бүлмәдә мәктәп музее барлыкка килде. Шунысы кызык: районда авыллар тарихын язучылар арасында математика, физика укытучылары шактый. Саннар белән бик төгәл эшләү, анализ ясау өчен баш яхшы эшләргә тиеш, – диде Гөлсем Миңнебаева.

ШУШМАНЫҢ ИКЕ ЯРЫНДА

Сугышка кадәр була бу хәл. Күрше авылдан егетләр Шушмабашка кыз урларга килә. Шушма егетләре аларга ярдәм итәргә була: толыпка төреп, кызны күтәреп китереп салалар. «Барыгыз тизрәк, хәзер куа чыгалар», – дип ашыктыралар да әле. Кыз урлаучылар «табыш»ның авызына: «Мә, җаным, җылама!» – дип, кәнфит каптырып, атларын кууларында булалар. Кайтып җиткәч, ни күрсеннәр: анда үлгән кәҗә бәйләп салганнар, ди.

Автор:
Гөлүсә Закирова

Фотолар авторныкы

– Шул үлгән кәҗә вакыйгасыннан соң 30 ел буена Шекә белән Шушмабаш халкының аралары бозылып торды, – ди авыл аксакаллары. – Кызлар ул авылга кияүгә бармады, егетләр аннан кыз алмады. Совет чорында гына, бер совхозга берләшкәч, үпкә саклап йөрүне кирәксенмәделәр инде…

КӨЙМӘЛӘРДӘ ЙӨЗГӘННӘР

Шушмабашта кыз урлау йоласы күптәннән килә. Бу элеккеге чордагы җыен уздыру белән бәйле бер йола шикелле. Бу авылда ул «Казак җыены атнасы» дип исемләнгән. Июнь аеның 15ләре тирәсендә бәйрәм иткәннәр. Җыен җомга көнне башланып, якшәмбе көнне тәмамланган. Анда Шекә, Апаз, Каратай авыллары да катнашкан. Ярминкә, алып-сатулар да оештырылган. Кунакка йөрешкәннәр, күңел ачканнар, яшьләр төрле уеннар уйнаган, җырлар җырлаган. Парлы кешеләрне парлы, бертөсле атларда тарантас җигеп алдырганнар. Ялгыз кунакларны ялгыз атта, худ арбасына утыртып алып килгәннәр. Ат дирбияләренең тәңкәләре агартылган, каешлары майланган булырга тиеш, дип саналган. Яшьләр Шушма елгасының ике ярында «Так карвыл», «Түгәрәк», «Такрау» кебек уеннар уйнаган. Гармун уйнап, урам әйләнгәннәр. Әмма бәйрәмнең төп максаты – яшьләрне үзара таныштыру булган.

– Совет елларында яшьләр Биләнгәр елгасында көймәләрдә йөзеп күңел ача иде. Елга ярларына тезелеп утырып, ачык һавада республиканың тынлы уен кораллары оркестры концертын да тамаша кылган булды, – дип искә ала яшьлеген ветераннар советы рәисе Кәүсәрия Нуриҗанова. Ә хәзер язгы ташудан киңәеп калган болыннарында каз, үрдәк бәбкәләре үлән чемченә. Ул да түгел, киң канатлары белән авылны күләгәдә тотарлык торналар күтәрелә…

ЧЫПТАЧЫЛАР АВЫЛЫ

Архив документларында Шушмабаш авылының борынгы чорлардагы атамасы Шушма елгасының ике ярына урнашкан авыл дип билгеләнгән.

Язучы Мөхәммәт Мәһдиев «Шагыйрьнең бишеге» язмасында болай дип яза: «Кенәр ягы – байлар ягы. Чыпта сугучы, дуга, чана эшләүче, чүлмәк ясаучы Шекә, Шушма яклары алар «кара як» дип атаганнар». 70 нче елларда була бу хәл. Элегрәк Шушмабаш халкының чыпта сугып, чабата үрүләрен күрсәтергә теләп, бер өзек сәхнәләштерә авыл халкы. Анда бер апа чабата үрә икән. Моны күргәч, борыны җепшеп киткән бер малайның исе киткән. Кайткач әбисенә сөйли икән: «Әби, бер апа аякка кия торган нәрсә ясады, җитмәсә, аның ике койрыгы да бар!» – дигән ди».

Шушмабашта әле инкыйлабтан соңгы елларда да чыпта сугу остаханәләре тоткан байлар була. Алар мунчаланы чыпта сугучы хуҗалык-

PRESSA.RU

ларга таратып, суккан чипталарын, дөресрәге, чиптадан теккән капны (капчыкны) җыеп алганнар. Күпләп җитештерелгән бу товарны балык, тоз һ.б. тутыру өчен файдаланганнар. Аларны Апаз базарына гына түгел, ә ерак шәһәрләргә озатырга дип сукканнар. Шушмабашта чипта каплары үрүчеләр пыяла заводы белән килешү нигезендә эшләгән. Чипта нык булганга, сугыш вакытында корал ташу һәм паровоз мичемә ягулык салу өчен дә кирәк булган. Шулай ук балык кебек тиз бозылучан азык-төлек салып йөртү һәм төзелеш материаллары тутыру өчен дә файдаланылган. Соңрак, күмәк хуҗалык оешкач та, чипта сугу Шушмабашта төп һөнәр булып кала бирә – чиптачылар артеле оештырыла.

Авыл ир-атлары ат белән ерак юллардан әйбер ташый, «Казанга барабыз»лыкка хезмәт итә. Ат җигеп, юл йөрү Казан артында абруйлы эш санала. «Базарга килгән җигүле ат хуҗалары билләрен кызыл комач белән буа иде», – дип язып калдырды Мөхәммәт Мәһдиев тә. Кызыл путалы татар агайлары урыс миссионерларын авылга кертмәслек кырык сәбәп таба алгандыр ул... Шушмабаш – күп кенә татар авылларын зар елатып көчләп чукындырган заманнарда да бу афәттән котылып калган авылларның берсе.

ИМАН КӘЛИМӘСЕ

Шушмабашта муллалар бер нәселдән килә. XIX гасырда 50 ел дәвамында Хәбибулла Абдуллин имам-хатыйп, мөгаллим булса, вафатыннан соң улы Мөхәммәткамал Хәбибуллин муллалык итә. Анысы да 30 елга якын дини йолалар башкара. Шуннан репрессия еллары ишек кага. Шушмабаш мулласын беренчеләрдән булып авылдан сөрәләр. Хатыны Фаһирә абыстай бик гыйлемле, алдан күрүчән хатын була – чит-ят җирләрдән барыбер бер әйләнеп кайтуны өмет итеп, кечкенә генә кәгазь битенә иман кәлимәсе яза һәм шуны урталай ертып, берсен чәчүргечене бәйли, ә икенче кисәген ишек өстендәге матча ярыгына кыстыра...

Гомерләр үтә. Авыл халкы муллаларын юксына башлый. Ничә буын муллалык иткән бу нәсел дәвамчыларын бәлки эзләтеп карарга кирәктер? Чит-ят җирләрдә каңгырып йөрмәсеннәр, туган нигезләренә кайтсыннар, дип, югары даирәләргә хатлар юллый шушмабашлылар. Үтенечләре канәгатьләндерелә, чөнки Камал мулла акланган була. Әмма хәзрәт инде вафат: төзелешенә күп кенә татар зыялылары гомерен биргән Магнитка каласында салкын тидереп, бакыйлыкка күчкән. Фаһирә абыстай, мең газаплар белән озын-озак юллар үтеп, газиз нигезенә кайтып егыла. Бусаганы атлап керү белән үк матчага кыстырылган иман шартын эзләп таба. Һәм беренче мәртәбә, бернидән дә оялмыйча, шушы кәгазь кисәген күкрәгенә кысып, үкси-үкси елый ул.

Шушмабаш мәчетен 1931 ел башында ябалар. 2005 елда тумышы белән шушы авылдан булган эшкуар Габделхәй Кәримов өр-яңа затлы гыйбадәтханә салдыра. Мәчет картлары елның елында зиратларны карап, тәртиптә тоту эшен дә авырсынмый башкара. Кышын, үлем-китемнәр булганда, туң җирне лом белән чүкеп азапланмас өчен, чарасын да уйлап тапканнар: зиратта 15–20 метр арага салам түшәп калдыралар, болай иткәндә җир туңмый, кабер казырга уңай икән. Бөтен мәсьәләләр мәчеткә намазга килгәч хәл ителә. Элеккеге җыеннар вазыйфасын да мәчет үти.

АМЕРИКА АШХАНӘСЕ

Ачлык елларында уку кайгысы калмый. 1921 елның 10 августына 3 яшьтән 15 яшькәчә 41 ятим бала теркәлә. Халыкның күпчелеге икмәк суррогатлары белән туклана. Ике гаиләнең өстәлендә икмәге бар, ә 38 гаилә алабута, 43 гаилә агач кайрылары һәм яфраклары, 20 гаилә теләсә нинди үлән белән җан асрый. Гомумән алганда, 101 гаилә ачлыктан интегә, әмма үләксә ашаучылар булмый. Шул елларда Россиягә килгән Америка ярдәм оешмасы (АРА) вәкиле Р.Чайльдс: «Мин узарга туры килгән авылларда йортларның күбесе буш, ә калганнары тормыш билгеләре, хәтта эт өргәне, мәче мияулаганы да ишетелми», – дип язып калдыра. Шушмабашта да ачлыктан интегүчеләргә Америка ашханәсе ачыла. 1922 ел башында Германиянең Кызыл Хач җәмгыяте белән берлектә Швециянең шәхси сәүдә-сәнәгать предприятиеләре берләшмәсе юллаган сохари өләшәләр. Аннан Америка паегы – маис ярмасы кайтартыла.

Репрессияләнгән авылдашларга һәйкәл.

ТҮГӘРӘК ЧЫРШЫЛАР

Элегрәк авылның Носы басуы уртасында түгәрәк чыршылар да үсеп утырган. Бу чакрымнар белән исәпләнгән юлның маяклары булгандыр, ди авыл халкы. Түм-түгәрәк, очлы конус кебек формада була ул. Әле сугыштан соңгы елларда аның шактые басып тора. Хәзер дә мари ягында рәттән тезелеп киткән шундый түгәрәк чыршыларны очратырга мөмкин. Кәүсәрия апа Нуриҗанова мәктәптә укыган елларында шул чыршылар янынннан узганын хәтерли:

– Ишнаратка Хисмәт карттан кыяр үсентеләре алырга җибәрә иде әни. Юлга озатканда: «Түгәрәк чыршылар янына барма!» – дип кат-кат әйтүен хәтерлим. Яңгыр яуганда аларның ылыс ябалдашлары астында ышыкланып, яшен сугып үтерү очраклары да ишетелгәли иде. Аннан төпләренә ашламалар өйгәннән мантый алмый, харап булды ул чыршылар.

Тау башындагы өч нарат үскән урынны да изге дип исәпли авыл халкы. «Зират урыны бу, анда изгеләр күмелгән» диючеләр дә, «Чирмеш зираты ул» дип ышанучылар да җитәрлек. Халык монда чүп-чар атмаган, хәтта печәнен чабарга да курыкканнар. Шәфәкъ кызыллыгында бу тирәдә йөрмәскә тырышканнар, күзләрне элпә каплый торган шөбһәле урын, дип, балаларына кат-кат әйткәннәр. Тау итәгеннән саркып чыккан Зират чишмәсе суының зәхмәте кагыла, дип ышанганнар. Авылның иң өлкән кешеләренең берсе – 1927 елгы Сафура апа Яббарова сөйләве буенча, янәшәдә урак урсалар да, алар беркайчан да бу су белән юынмаган.

ГЕРОЙЛАР КӨН ДӘ ТУМЫЙ

Шушмабаш агае Гыйльметдин абый Шиһаповның Рейхстагта үз имзасы бар. Сугышта командир була ул. Мәскәүне саклау өчен барган каты бәрелешләрдә аның җитәкчелегендәге 3 нче батарея «Волокаламск операциясе»ндә катнаша. Дошманның 6 танкын юк иткән өчен Ленин ордены белән бүләкләнә.

Авылның тагын бер каһарманы бар. Ул матросовчы егет – Кәрим Исхаков. Аның исеме, батырлыгы турында авылдашларына шактый еллар узгач кына билгеле була. 1943 елның 5 октябрендә Кировоград өлкәсенең Старое Липово авылы янында, чуаш егете Арсентий Карташов белән бергә, дошманның ут өермәсен томалап һәлак була. Арсентий – тумышы белән Буа районы Әлшәй авылыннан. Әлеге батырлык

турында күренекле чуаш язучысы Антип Николаевның «Ак каеннар мәңге уяу» дигән документаль повестенда язылган. Күпмедер вакыттан соң, язучы-эзтабар Шаһинур Мостафин да кызыксына матросовчы егет белән һәм китапларына аның исемен дә кертә. Амбразураны күкрәкләре белән каплаган бу егетләргә медаль дә, герой исеме дә бирелмәгән.

ВОРОШИЛОВКА ХАТ ЯЗА

Зәйтүнә апа Һадиева – 1930 елгы. Яңгыравык, матур тавышлы, җор телле бу әбинең һәр сүзендә хикмәт ярылып ята. Ул үзе һәр баласының – ә алар аның дүртәү – кайчан, ничәнче елда, атнаның кайсы көнендә, сәгать ничәдә туганын хәтерли. «Бүлнистә түгел, өйдә таптым», – ди. Ире Әхмәт – матросовчы Кәрим Исхаковның туганы, балта остасы буларак танылa. Зәйтүнә апа үз вакытында 19 ел буе Шушмабаш тегү цехында эшли, пешерә дә. «18 яшемдә яраткан кешемә кияүгә чыктым, бәхетле яшәдем», – ди. Кайнанасы Әсма апа белән 40 ел тату тора алар. Әсма апа яшелчәчелек бригадиры була. Эштән бушаган арада җөй тегә. «Тегү өчен аңа күреп калу да җитә иде. Кешенең гәүдәсен кул, бармаклар белән генә үлчәп ала иде», – ди Зәйтүнә апа. Тик бер көнне кайнанасын төрмәгә утырталар. Теккән өчен кемдер эш хакына 2 кг бодай биргән, шуны сәбәп иткәннәр. Улы Әхмәтнең Германиядә хәрби хезмәттә чагы була бу. «Әни анда төрмәдә утырганда мин туган илемә ничек хезмәт итим ди», – дип, Ворошиловка хат яза Әхмәт солдат. Мәсьәлә уңай якка чишелеш таба. 7 айдан әнисен төрмәдән азат итәләр.

ДИПЛОМСЫЗ ИНЖЕНЕР

1958 елның кышы. Бу елларда кышын машиналар йөрми диярлек. Комбайнер Мансур Низамов, пропеллерлы аэрочана ясап, бар кешене шаккатыра. «Северный» совхозы директоры Нәкыйп Сафинга да ошый бу техника могҗизасы. Ул аны өстен ябулы итеп совхозга да эшләп бирүен сорый. Һәм ни хикмәт – ул эшләгән «канатлы чана» совхоз җитәкчеләренә шактый еллар игелекле хезмәт күрсәтә. Алай гына да түгел, оста мононарталар да ясап куя: болары пропеллерсез, ягъни хәвефсезрәк, өч чаңгының берсе урынына башмак-гусеница куеп ясала.

Болай техниканың җаен белгәч, халык аңа еш мөрәҗәгать итә. Үз вакытында данлыклы Шушмабаш ипие мичләрен, агрегатларын да Мансур Низамов көйләп, карап тора. Хәер, үз бакчасында да күп нәрсә механикалаштырылган: бәрәңге утырту, рәт арасын эшкәртү, казып алу кебек җайланмалар да ясый ул. Хәзер менә Мансур абыйның оныклары, биш бертуган кыз: Руфинә, Резедә, Люция, Илсөя, Гөлсу олы сәхнәдә җырлап-биеп танылу алдылар.

Бүген Шушмабашта җыен да уздырмыйлар, кызлар да урламыйлар инде. Әмма үткәннәрен санлап, бүгенгеләрен матур итеп яшәргә тырышалар. Болар хакында 2016 елда дөнья күргән «Шушмабаш» китабында тулырак бәян ителә.



XII гасырда Идел буе Болгарстанындагы базар. Р.Ф. Хуҗин рәсеме.

СЕРЛЕ БОЛГАР КАЛАЛАРЫ: ШӘМ-СУАР ҺӘМ КАШАН

Борынгы болгар калаларын гадәттә археологик яктан яхшы гына өйрәнелгән, дип әйтәләр. Шулай да кебек. Әмма тирәнрәк уйлап карасаң... Йөзгә якын эреле-ваклы шәһәр-шәһәрчекләрнең бик сирәге генә археолог күрәге кургән. Хәтта исемнәре елъязмаларда теркәлеп калган болгар калалары да үзләренең тикшеренүчеләрен көтеп ята.

Автор:
Фаяз Хуҗин

ТАГЫН БЕР КАТ СУВАР КАЛАСЫ ТУРЫНДА

Сувар каласы Болгар иленең иң атаклы тарихи һәйкәлләре исемлегендә урын алган, шуңа күрә аны еш кына шәһри Болгар белән янәшә куеп телгә алалар. Ул хәзерге Спас районының Кузнечиха авылыннан дүрт чакрым ераклыкта урнашкан. Хәрабәләре 4,5 чакрым озынлыктагы балчык үрләрдән һәм тирән чокырлардан торган ныгытмалар белән уратып алынган турыпочмаклы шәһәрлектән гыйбарәт. Борынгы кала 90 гектар мәйданны биләгән. Баштан ук сувар-савир исемле эре кабилә берләшмәсенең – Сувар билегенең (әмирлегенең) үзәге, башкаласы сыйфатында төзелә ул. Шуңа күрә дә биредә Шәрык илләреннән килгән сәүдәгәрләр, сәяхәтчеләр еш булганнар. Суварны алар үзләренең язмаларында телгә алалар. Мәсәлән, гарәп географы әл-Балхи хезмәтендә, Сувар – зур шәһәр, аның үзәк мәйданында Җәмигъ мәчет урнашкан, халык саны 10 меңгә җитә, дигән хәбәр бар. Моңа охшаш юлларны әл-Җәйхани, әл-Истахри язмаларыннан да табарга мөмкин.

Соңгырак чорда яшәп иҗат иткән авторларның Сувар турында мәгълүматлары бик ярлы, кайчакта дөреслеккә дә туры килми. XI гасырның атаклы тел галиме Мәхмүд Кашгарыйның «Төрки телләр сүзлеге»ндә Сувар бары тик бер тапкыр телгә алына, анда да урнашкан урыны Иделнең уң ягында, Каспий диңгезе буенда дип күрсәтелә. XII йөз географы әл-Идриси исә Суварны бортаслар шәһәре дип атый. XIV гасыр галимнәре сирәк кенә булса да Суварны искә алып үтәләр, тик үзләреннән алдарак яшәгән авторларның язганнарын кабатлау белән генә чикләнәләр.

Шунысы гаҗәп: Болгар иленә 1135 елда ерак Андалузиядән (Испаниядән) килеп, озак кына торып киткән Әбү Хәмид әл-Гарнати үзенең китабында нишләптер Суварны бөтенләй телгә дә алмый. Урыс елъязмаларында да аның турында бер кәлимә сүз юк.

Сувар билегенең X йөздәге сәяси тормышын өйрәнүдә нумизматика материаллары да мөһим роль уйный. Галимнәр болгар акчалары арасыннан Сувар әмирләре Талиб ибн-Әхмәд һәм Мөэмин ибн-Әхмәд тарафыннан 948–976 елларда сугылган көмеш тәңкәләрне аерып алдылар. Нумизматика материаллары күрсәткәнчә, Сувар X йөз ахырына кадәр мөстәкыйль, ягъни Болгарга буйсынмыйча яшәүче суверен билек (әмирлек) булган.

Тарихи чыганакларның аз булуы, алардан алына торган мәгълүматлар-

Фотолар авторлардан алынды





Суварда саклану корылмалары. А.М. Гобәйдуллин реконструкциясе.

Борынгы Болгар шәһәре. Р. Газиев рәсеме.

ның ярлылыгы аркасында XIX гасыр ахырларына кадәр Суварның урнашкан урынын да юньләп белүче булмаган. Атаклы дин галиме һәм тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре үзенең 1885 елда чыккан «Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр» дигән китабында Сувар хәрабәләрен хәзер менә без белгән урында эзләргә кирәклеген әйтеп үтә. Икенче бер татар галиме Гайнетдин Әхмәров әлеге урынны барып тикшерә һәм Мәрҗани тарафыннан әйтелгән фаразның чынбарлыкка туры килүен археологик табылдыклар белән раслый.

СУВАР ТАБЫЛДЫКЛАРЫ

Суварда иң беренче һәм күләмле казу эшләрен Мәскәү археологы атаклы болгарчы-галим Алексей Смирнов 1933–1937 елларда үткәрә. Башта ул шәһәр ныгытмаларын казый. Ул ныгытмалар валлар өстендә 4х5 метр үлчәмдәге бураларны бер-берсенә ялгап төзелгән стеналар рәвешендә булган икән. Араларын 100–120 метр калдырып, биек башнялар корылган. Бу ныгытмаларның буеннан буена, тышкы яктан, тирәнлеге 5 метрга җитә торган чокыр казылып, төбенә очлы казыклар кагып куелган.

Әлбәттә инде, Алексей Смирнов тикшергән корылмаларның иң кызыклысы – X гасыр ахырында ук салынган кирпеч бина калдыклары. Ике катлы булганга охшый, стеналары да калын, бер почмагына донжон тибындагы башня утыртып куелган. Беренче катта уртача зурлыктагы дүрт бүлмәсе булган. Гомуми мәйданы 96 кв. м. Үзәкләштерелгән ягу системасы – идән астыннан үтә торган төтен юллары сакланып калган. Галим бинаның борынгы «кыяфәтен» күз алдына китереп, аның якынча реконструкциясен дә ясап куя: артык зур булмаган тәрәзәләр, як-яктан ярымколонналар куелган арка тибындагы киң һәм биек ишек. Ишегалды кирпеч белән түшәлгән. Әлеге бинада Сувар әмире торгандыр, дип фаразлана.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты археологлары Суварда Алексей Смирнов тикшеренүләреннән соң 60 елга якын вакыт үткәч, 1990нчы еллар башында эшләп алды. Ниятебез болгар бабаларыбыздан калган тарихи һәйкәлләрне халкыбызга яңадан кайтару, аларны күрсәтү өчен Болгардан башланып, Сувар һәм Биләр калалары аша Җүкәтауга кадәр сузылырга тиешле «Көмеш дага» исемле туристик маршрут ачарга тырышу иде. Смирнов тарафыннан 1930нчы елларда ук тикшерелгән Сувар әмире сараен да табып, төзәтеп-тәртипкә китереп, туристлар өчен әзерләп куйсаң, начар булмас иде, дип уйладык без. Һәм эшкә дә керештек.

Смирнов казылмаларының янәшәсендә генә әзер йорт нигезләре, хуҗалык чокырлары килеп чыкты. Табылдыклар күп, әмма әллә ни искиткечләре юк иде: тимер йозаклар, ук очлары, камчы сабы (бронзадан ясалган, бөркет сурәтендә), муенса төймәләре, пыяла рюмка, ватылмыйча сакланган чүлмәкләр, кувшиннар. Зур гына бер келәттә күмерләнгән бодай бөртекләре, чия төше, кура җиләге орлыгы, йомырка кабыклары, балык һәм хайван сөякләре... Алтын Урда чорына караган бер генә әйбер дә юк, барысы да монголларга кадәрге чорныкы. Димәк, Сувар 1236 елда монгол-татарлар тарафыннан җимертелгән дә, яңадан тернәкләнеп китә алмаган.

Артык зур күләмдә булмаса да, казу эшләрен тагын ике ел дәвам иттек. Табылдыкларыбыз да бер музей төзергә җитәрлек. Тик финанс мөмкинлекләре генә чикле. Хөкүмәт кешеләре Суварның тарихыбыз өчен нинди зур байлык икәнен һаман да аңлап бетермиләр әле. Җимерелеп кенә бетмәсен инде, өстен гел сөреп торалар бит. Килер бер вакыт... Һәм халыкара туристик маршрут... Ышанам, хыялларыбыз тормышка ашар.

СЕРЛЕ КАШАН

Кашаннан да серлерәк болгар каласы бармы икән? Болгар, Биләр, Сувар, Җүкәтауларны азмы-күпме казып киткәннәр әле археологлар, ә менә Кашанга нигәдер куллары җитми. Матур гына риваять-легендаларыбыз да бар Кашан турында. Рус елъязмаларында да телгә алына ул. Халык җырларына кергән. Тик үзе белән һаман юньләп кызыксынучы юк әлегә.

Балчык савытлар.
XI–XII гасырлар.

Пыяла савыт. Болгар.
Пыяла кубок. Сувар. XI–XII гасырлар.

Бизәкле балчык кувшин.
Идел буе. XIV гасыр.

...Аксак Тимер Болгарны яулап алгач, Габдулла хан хатыны һәм балалары белән зур гына бер таш бинага кереп бикләнә. Дошманнар бу бинаны ут төртеп яндыралар. Габдулла ханның бер кызы һәм өч ир туганы гына исән калалар. Искиткеч чибәрлегенә, диндарлыгына күрәме, кызны ялкын алмый. Бу могҗизага шаккатып, Аксак Тимер утта янмый торган хан кызын һәм аның үлемнән котылып калган энесен үзе белән Сәмәркандка алып китә. Еллар үтә. Тимернең үлеменнән соң тоткыннарны азат итәләр һәм алар туган илләренә, Болгар-йортка кайтып китәләр. Аларны Кашан каласында каршы алалар, озак кына сый-хөрмәт күрсәтәләр. Соңыннан хан кызы үзенең энесе белән Алтынбәк һәм Галимбәк исемле туганнары янына, Казан якларына күчеп китә.

Әлеге легендада XIII йөз вакыйгалары турында сөйләнә. Биредә Кашан да телгә алына, тик аның ниндирәк кала булуы турында әйтелми. Ә менә борынгыдан килгән бер халык җыры әлеге болгар шәһәрен бераз тулырак күзалларга мөмкинлек бирә. «Шәһри Кашан – җиһанның бер гүзәл почмагы, олысы-кечесе – һөнәр иясе; аның мактаулы сыйфаты – охшаган ул нурлы кояшка. Кашан – җиһанның бер көзгеседер, халкы аның: берсе – корыччы, икенчесе – алтын-көмешче; бу сүзләргә гаҗәпләнмә, алар хактыр», – диелә бу җырда.

Борынгы рус елъязмаларына күз салыйк. Бу документларда Казан һәм Кашан калалары еш кына буталып бирелә. Воскресение елъязмасында, мәсәлән, мондый сүзләр бар: «1391 ел... Новгород һәм Устюг кешеләре һәм аларга кушылган башкалар, насадларга һәм ушкуйларга төялеп, Вятка елгасы буйлап түбәнгә табан йөзеп киттеләр һәм Җүкәтау, Казан калаларын кулга төшереп, Иделгә чыктылар, халкын талап, кире әйләнеп кайттылар». Аңлашыла ки, Вяткадан Камага чыгып, аннан Иделгә тикле барганда ушкуйниклар һич тә Казанны ала алмый, чөнки ул Идел белән Кама кушылдыгыннан югарырак урнашкан. Димәк, Казанны Кама тамагындагы Кашан белән бутаганнар. Кашан 1396 елгы хәбәрдә дә Җүкәтау һәм Кирмән кебек Кама буе калалары белән беррәттән телгә алына. Бу хәбәрләргә таянып, Кашанның XIV йөз ахырында яшәгәнен аңларга мөмкин. Ушкуйникларның игътибарын җәлеп итәрлек булгач, ул бай гына кала да булгандыр, дип уйларга нигез бар.

Тагын бер кызыклы тарихи фактны искә төшереп үтәм. 1179–1229 елларда яшәгән гарәп энциклопедисты Якут әл-Руминең атаклы «Географик сүзлегендә» мондый юллар теркәлеп куелган: «Кушан – иң ерак төрки дәүләтнең чигендә урнашкан кала. Аның патшасы төрки хакимнәрнең иң көчлеләреннән санала». Галимнәр әлеге Кушанны, һич тә шикләнмичә, болгар шәһәре Кашан белән тәңгәлләштерәләр, чөнки «иң ерак төрки дәүләт», әлбәттә, Идел Болгарстаны инде ул.

XIII гасыр башына караган атаклы «Кыйсса-и Йосыф»ның бер кульязма нөсхәсендә аның авторы Кол Гали үзе турында: «Бән – Кушани, зәгыйфь бәндә, атым Гали», – дип белдерә. Таҗетдин Ялчыголның «Тәварихы Болгария» китабында китерелгән шәҗәрәгә ышансаң, Кашан шәһәрендә Кол Галинең әтисе Мирхаҗи туган һәм биредә утыз ел гомер кичергән. Аннан соң ул, имеш, Зәй тарафларына юл тоткан, шул якларда төпләнеп калган. Биредә булачак шагыйрь Кол Гали дөньяга килгән. Бу нәрсәләрне кайбер галимнәр чынга саныйлар, кайберләре исә Кол Галинең туган җире итеп Зәй буйларын түгел, ә Кашанны күрсәтәләр. Чынбарлыкта ничек булгандыр, тагын да төгәлрәк, ышанычлырак тарихи чыганаклар юк, ә менә Кашанның әле монгол яуларына кадәр үк яшәгән булуын ышаныч белән әйтә алабыз.

КАЙДА СОҢ УЛ КАШАН КАЛАСЫ?

Күргәнегезчә, Кашан турында чыганакларыбыз аз. Мондый очракларда без археологиягә мөрәҗәгать итәбез. Әмма... кайда соң ул Кашан каласы? Элек тә эзләгәннәр аны, хәзер дә эзлибез. Эзләнүләрнең тарихы болайрак.

Кама кичүе тирәсендә (Балык Бистәсе районының Саескан Тавы авылы янында) электән калган топонимик атамалар сакланган: Кашан тавы, Кашан култыгы, Кашан юлы. Соңгысын картлар әле хәзер дә хәтерли. Очраклы хәл түгелдер бу, ди Петр Кондырев, XIX гасыр башында Казан университетында эшләгән галим, һәм шул якларга юл тота. Хәзерге Лаеш районының Шуран, Балык Бистәсе районының Олы Елга авыллары арасында болгар истәлекләрен табу була аның хыялы. Кашан каласын таба алмый.

1862 елда тарихчы С. Мельников болай дип язып калдыра: «Шураннан өстәрәк, имәнлектә, җирдән өелгән үрләр белән уратып алынган мәйданда еш кына көмеш һәм бакыр

Сәманидләр дирһәменә ияру.

Болгар шәһәрлеге көмеш дирһәмнәре. X–XIV гасырлар.

акчалар, бизәнү әйберләре, чүлмәк китекләре табыла. Биредә Болгар шәһәре Кашан, бу яклардагы татарлар әйтүенчә, Казан яисә Иске Казан урнашкан булган диләр. Шәһәрлекнең эче сөрелми: ата-бабалардан калган бу изге урынны җимертүдән куркалар». Әлеге хәбәрдә җирле халыкның Кашанны Казан һәм Иске Казан белән тәңгәлләштерергә омтылуы кызык. Академик Мирфатыйх Зәкиев тә Казан атамасы, ныклабрак тикшерсәң, Кашан топонимы белән бәйләнгән булырга мөмкин, дигән фикер әйткән иде.

Борынгы Кашанның урынын 1879 елда археолог Петр Пономарев таба. Ул үзенең разведка рәвешендәге тикшеренүләрен Саескан Тавы авылының көнбатыш ягыннан башлый. Биредә бер урынны күрше авыл халкы «Калачык» («Городок») дип йөртә. Шуны эзләп таба. Яхшы гына тикшерә ул Калачыкны, ике рәт үр һәм чокырлардан гыйбарәт борынгы ныгытма эзләрен планга төшереп куя. Бер карасаң, кечкенә шәһәр булырга ошамаган – ныгытмалар белән уратып алынган өлеше генә дә 28 гектарга җитә. Әмма шул зур мәйданда бер генә чүлмәк китеге табылса иде! Берданбер табылдык – гарәп хәрефләре белән нидер язылган тимер кылыч. «Шуңа күрә, – дип нәтиҗә ясый Петр Пономарев, – болгарларның Кашаны монда булгандыр дип әйтергә һичнинди нигез юк». Галим тикшеренүләрен дәвам итә.

Тиздән ул Шуран авылыннан бер чакрым чамасы көнчыгыштарак Каманың биек яр башына урнашкан зур гына болгар шәһәрлегенә килеп чыга. Ныгытмалары да яхшы гына сакланган, мәйданы 108 гектарга җитә, димәк, кайчандыр ул эре калалар исәбендә йөргән. Дөрес, җирдә аунап ята торган табылдыклар әлләни күп түгел. Күрше авыл кешеләре генә элегрәк җыелган әллә никадәр борынгы әйберләр биреп калдырды. Арада алтын беләзек белән алкалар да бар иде. 1865 елда булса кирәк, шушы тирәдән генә Алтын Урда акчаларыннан торган хәзинә дә табылган булган.

Димәк, эзләгәнемне таптым, дип нәтиҗә ясый Петр Пономарев һәм көндәлегенә теркәп куя: «Безнең алда, һичшиксез, Кашан хәрабәләре. Ныгытылган өлешенең зурлыгына, табылдыкларның байлыгына карап фикер йөрткәндә, Идел-Кама Болгарстанының бу шәһәре Биләр белән Болгардан гына калышадыр». Табылган шәһәрлекләрнең беренчесенә ул Кашан II, соңгысына Кашан I дип шартлы исемнәр бирә.

Бары тик 1948 елда гына Кашан I һәм Кашан II шәһәрлекләрендә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы археологлары кечкенә күләмдә булса да казулар үткәрәләр. Экспедиция җитәкчесе Николай Калинин, яңа табышларга таянып, Петр Пономарев фикерләрен хуплый. Кашан XII гасырда барлыкка килеп, 1396 елда Новгород ушкуйниклары тарафыннан җимертелгән болгар каласы, ди ул. Уңайлы урында урнашкан, борынгы сәүдә юлында, шуңа күрә дә бик тиз үсеп китә ул һәм шул тирәдәге җирләрнең, төгәлрәк итеп әйтсәк, Кашан кенәзлегенең үзәгенә әйләнә. Кашан II дигән шәһәрлекне Николай Калинин зур һәм көчле хәрби нытма, ягъни крепость калдыклары дип аңлата. Әлеге крепость Кама буйлап йөзүче сәүдә корабларының хәрәкәтен контрольдә тоткан, елга кичүен саклаган һәм бер үк вакытта Кашан бәгенең җәйге резиденциясе дә булып торган, имеш. Мантыйкка бик тә туры килә торган фикер. Тик...

1990нчы елларда Казан археологлары яңадан Кашан серләрен ачарга тырышып карадылар. Кашан I каласының ныгытмалары тикшерелде, шурфлар салынды, ярыйсы гына күләмдә казу эшләре үткәрелде. Аннан километр ярым ераклыктагы Кашан II каласында да тикшеренүләр алып бардык. Нәтиҗәләр мондый: соңгысында культура катламы да, табылдыклар да юк. Димәк, нытмаларын төзеп куйганнар да, ни сәбәпледер яшәргә өлгермиканнар. Кашан I каласын да бик авырлык белән генә чын шәһәр дип атап була. Мәйданы зур үзенең, тик культура катламы бик юка, күп урыннарда бөтенләй юк, табылдыкларны да күп дип әйтмәс идем. Тирә-юнендә авыл урыннары, мөселман зиратлары да юк. Ә бит шәһәр тирәсендә алар күп була.

Нәрсә соң бу? Нишләп аларның берсендә халык аз яшәгән, икенчесе исә бөтенләй дә буш? Рус ельязмаларында, халык авыз иҗаты әсәрләрендә телгә алынган бай һәм чәчәк атып утыручы Кашанны, чыннан да, шул Пономарев тапкан, соңыннан Калинин һәм башка археологлар тарафыннан тикшерелгән кала белән тәңгәлләштерергә мөмкинме? Бик тә шикле.

Эзләнүләр дәвам итә. Ә Кашан әлегә серләрен ачарга җыенмый.

PRESSA.RU



ҮЗ БИЕКЛЕГЕҢДӘ КАЛУ

Разил абый белән сөйләшүләр, гадәттә, озакка тынгысызлый – мин әле аның кабинетыннан чыгып киткәч тә, гәпләшеп, хәтта бәхәсләшеп тә йөрим. Шуларның өземтәсе бу. Сүзне үзенә бирәм.

Әзерләде:
Луиза Янсуар

«МИЧ БАШЫНДА КИТАП УКЫЙ ИДЕМ...»

– Әдәбиятка алып керүчеләрнең иң беренчесе әнкәй булды. Мин мич башында утырам, әнкәй безгә – сигез балага ашарга пешерә. Миңа кычкырып китаплар укыта. Чөнки үзенең укып утырырга вакыты юк.

Такташны бик яратты ул. Дүрт яшемдә «Мокамай»ны урындыкка басып яттан сөйли идем. Апаларым мәктәпкә баргач сөйләр өчен ятлагандыр инде, алардан ишетеп, мин дә ятлаганмын, күрәсең. Шул ук дүрт яшемдә укырга, язарга өйрәндем. Эштән арып кайткач, ял иткәндә, «Совет Татарстаны» газетасын кычкырып укыта иде әткәй. Аңа, колхоз рәисе булгач, җәмгыятьтәге хәлләр, илдәге сәясәт, вазгыять турындагы хәбәрләр кирәк булган, билгеле, мин моны үсә төшкәч аңладым. Бәлки, үземнең дә сәясәткә кереп китүем шуның белән бәйледер.

ЮГАРЫ ОЧНЫҢ МӨСЛАХ ТАҖИЕ

– Авылда безнең оч Югары оч дип атала иде. Бирегә Мөслах Таҗи дигән шигырьләр яза торган бик кызыклы бер җегет бар. Авыл халкы, билгеле, көлебрәк, мыскыллабрак карый иде аңарга – шигырь язуы бер хәл, ул бит әле Таҗиев урынына Мөслах Таҗи дип тәхәллүс тә куя. Аның белән дуслашып киттем. Ул миңа язучылар, әдәбият турында шулкадәр илһамланып, сокланып сөйли иде. Үзенең югары белеме дә юк, һөнәре буенча – төзүче, прораб булып та алды, аннары күп еллар журналист булып эшләде. Район газетасында даими басылып тора иде, әдәби түгәрәкләр эшендә катнаша. Авырып китеп, иртә вафат булды. Җаны-тәне белән әдәбият-сәнгатькә гашыйк кеше булып хәтердә калган.

РАЗИЛӘ АПА ҺӘМ ӘНИГӘ БҮЛӘК

– Разилә апам бар иде минем. Бик матур итеп рәсемнәр ясый, гармунда уйный. Шундый шаян-шук, хыялый холыклы... Мин дүртенче сыйныфта укыганда, әнкәйне 8 март белән котларга уйладык. Авыл кибетендә открытка да юк ул чакта. Разилә апа ак кәгазьгә матур итеп рәсем ясаган, миңа әйтә: «Монда шигырь кирәк, әйдә, рәсем астына шигырь язып куй әле», – ди. Мин инде шунда дүрт кенә юллык бер шигырь әмәлләдем.

Әткәй алдында бөтен балалар җыелышып бүләк иттек без кулдан ясалган бу открытканы. Әнкәйнең сөенүен күреп шаккаттым шулчакта. Рәсеменә сөендеме икән, шигыренәме – белмим. Мин инде үземчә шигыренәдер, дип уйладым. Югыйсә инде ул шигырь дә түгел, ә такмак, хәтерләмим дә хәзер үзен. Шигырь белән кешене сөендереп булганын шунда аңладым.

ЯЗГАН ӨЧЕН БЕРЕНЧЕ КЫЙНАЛУ

– Безнең күршедә бер абзый бар иде. Яшь вакытында аны бик азып-тузып йөргән, дип сөйләгәннәрен хәтерлим. Мин үскәндә, ул инде тәүфыйкка утырып, мулла булып, аштан-ашка йөри иде. Алтынчы класста укыганда, шул абзый турында «Хәтерлә, изге» исемле мәкалә язып, район газетасына җибәрдем. Моны тиз арада бастырып та чыгарганнар. Газета килә бит инде авылга, халык укыган. Икенче көнне, кич клубтан кайтканда, бу абзыйның малайлары мине, сагалап торып, тотып кыйнадылар. Үз гомеремдә шигырь өчен беренче кыйналуым булды. Мин аны, шаяртып, «беренче гонорарым» дип тә атыйм.

«МИН НИЧЕК МУЗЫКАНТ БУЛМЫЙ КАЛДЫМ...»

– Миңа 10–12 яшьләр булгандыр, авылыбызга концерт куярга мәшһүр җырчы Рәшит Ваһапов килде. Аның белән Оркыя Ибраһимова һәм Мөхтәр Әхмәдиев исемле баянчылар да бар иде. Алар безнең өйдә кундылар. Шулчакта шаккаттым аларга. Рәшит Ваһаповның тавышы – буй җитмәслек биеклек. Алай мәңге җырлый алмаячагымны аңлыйм.

Ялына торгач, әткәй миңа «Украина» дигән хромка алып бирде. Гармунда уйнарга өйрәтә торган китап та алдык. Гармун телләренә ноталарны язып куйдым, өйрәндем. Авыл клубында кызларны биетә-җырлата башладым. Мин шулай итеп музыкант булырга тиеш идем, әмма булмый калдым...

«ХЫЯЛЫМ – ӘНКӘЙГӘ АК ТӨЕНЧЕК ТАШЛАУ ИДЕ»

– Бу хыялдан мине күрше авылдагы бер абзый тайпылдырды. Ул очучы иде. Атнага бер-ике мәртәбә безнең авыл өстеннән кукурузникта очып уза. Ап-ак төенчеккә төйнәп, әнисенә самолеттан күчтәнәч ташлый. Без, авыл малайлары, самолет килгән вакытны чамалап, күз текәп көтеп торабыз – 15–20 малай дәррәү басу уртасына атылабыз да, теге төенчекне табып алып, әнисенә илтеп бирәбез. Үскәч, дип хыяллана башладым, авылыбыз өстеннән мин дә шулай очып узачакмын, әнкәйгә күчтәнәчләр ташлаячакмын.

Фото: Мадина Мөгътәсимова.

Әмма мин тугызынчыда укыганда, мәктәпкә бер төркем язучылар килде. Мәктәп директорыбыз Николай Максимов әйтә миңа: «Разил, – ди, – Актлар залында язучылар белән очрашу булачак, мин аларны укытучылар исеменнән котлармын, ә син шигырь яз, укучылар исеменнән котларсың».

Төн утырып яздым, чыгып укыдым. Шигырьләремне сайлап алып киттеләр дә республика газетасында бастырып чыгардылар. Шуннан язучы булырга ниятләдем һәм бүтән уңга-сулга тайпылып йөрмәдем.

«ЧАЛЛЫ БАНДИТЛАРЫ», ЯКИ 30 СУМ АКЧА

– Мөдәррис Әгъләм белән Чаллыдагы «Коммунизм байрагы» газетасы каршындагы әдәби берләшмәгә бергә йөри идек. Казанга укырга керергә дә бергәләп чыгып киттек. Пароходка утырып бардык. Берәр килограмм помидор, берәр буханка ипи алдык үзебез белән. Таң беленгәндә пристаньга килеп төштек. Трамвай-троллейбуска утырырга шүрләтә. Матбугат йортының Бауман урамында урнашканын беләбез. Киттек сораша-сораша җәяү шунда.

Килеп җиттек тә басып торабыз. Берәр таныш язучы очрамасмы, дип, көтеп. Чаллыдагы әдәби берләшмәгә килеп йөргән язучыларны азмы-күпме беләбез бит инде. Берзаман Зәки абый Нури күренде горизонтта. Килә-килешкә: «О, Чаллы бандитлары, нишләп йөрисез Казанда», – дип, безне җылы итеп сәламләде. «Укырга керергә килдек», – дибез. Алып керде Зәки абый безне Язучылар союзына, кулга каләм тоттырды, кәгазь сузды: «Язучылар союзының җаваплы секретаре Зәки Нури исеменә яшь шагыйрьләр Мөдәррис Әгъләмов һәм Разил Вәлиевтән гариза языгыз...» – диде. Шунда ул кулыбызга утызар сум акча тоттырып чыгарып җибәрде. Безнең мондый зур акчаны күргәнебез дә юк иде.

«БЕЗ АНДА ТИЕШЛЕ ВАКЫТТА БАРЫП ЭЛӘКТЕК»

– Гөрләп торган студент тормышы башланды. Зөлфәт, Фәрит Гыйльми белән аралаша башладык. Рәдиф Гаташ белән таныштык. Әйбәт кенә дуслашып киттек. Икенче курста укыганда, Илдар Юзеев мине Язучылар берлегенә чакырып китерде. «Әдәбият институтына конкурс игълан иткәннәр, барырга теләмисеңме?» – ди. 12 яшь язучыны чакырып алган иде. Шул уникебезнең дә әсәрләрен – подстрочникларын Мәскәүгә җибәрдек. Бәхетемә, мин ул конкурстан уздым.

Әдәбият институтында ул чакта Рәсүл Гамзатовлар, Чыңгыз Айтматовлар тулай торакка килеп, кичләр буе безнең ишеләр белән аралашып утыралар. Һәр шимбәне диярлек тулай торакның Кызыл почмагында Евтушенко, Окуджава, Вознесенский, Рождественский, Ахмадуллиналар чыгыш ясый. Моныcы – үзе бер мәктәп. Без анда нәкъ менә тиешле вакытта – әдәбиятның абруе югары булган һәм иҗат кайнап торган чорда барып эләккәнбез икән, дип уйлыйм хәзер.

ПУШКИН – ШАГЫЙРЬМЕ, ҮГЕЛМЕ?

– Хәзер без БДИ белән мавыгып, күрсәткечләр артыннан куып, мәгариф системасында укыту сыйфаты шактый түбәнәйде. Укыту мөгаллимнең үз фәненә булган яратуына корылган булудан туктады.

Мин үзем укыту осталыгының нинди булырга тиешлеген Әдәбият институтында аңладым. Анда безне Еремин дигән бер профессор укытты, ул Пушкин иҗаты буенча махсус семинар алып бара иде. Менә, ишекне әкрен генә ачып, аудиториягә килеп керә. Сөмсере коелган, кәефе юк. Сүзен болай башлый: «Дорогие мои молодые друзья, перед тем, как идти к вам, я всю ночь читал Пушкина...» Без, хәзер нәрсәдер була бугай, дип, тып-тын калып, колакларыбызны торгызып утырабыз. Еремин дәвам итә: «Пушкин, оказывается, дряннейший поэт, зря я его изучал, зря пропагандировал, сколько лет на это потратил...» Аннан китә укып аның бик билгеле булмаганрак шигырьләрен, Вересаевның «Пушкин в жизни» китабыннан цитаталар сибә... Шулай итеп, безне Пушкинның бозык, яман кеше булуына, шигъриятенең пүчтәк икәнлегенә тәмам ышандыра.

Институттан гаять дулкынланып кайтабыз да тулай торакта ду килеп бәхәсләр оештырабыз, Пушкинның томнарын өр-яңадан актарып чыгабыз. Күңел тынгы тапмый... Ничек

PRESSA.RU


Разил Вәлиев гаиләсе белән.

инде шулай?! Бөтен рус әдәбият фәнен өйрәнүчеләр ялгыша алайса?!

Икенче көнне ул безне балкып каршы ала. «Дорогие мои молодые друзья, я опять сегодня всю ночь читал Пушкина, Пушкин оказывается прекраснейший, гениальнейший поэт…» – ди һәм шагыйрьнең иң шәп шигырьләрен укый башлый. Менә шулай ул безне гомерен багышлаган шәхес дөньясына – Пушкин иҗатына гашыйк булырга өйрәтте, гап-гади студентларны фикердәшләре югарылыгына күтәрде.

Әле илгә кайтып өлгермәгән, машинкада гына басылган тыелган әдәбиятны, кульъязма рәвешендә, кулдан-кулга йөртеп укый идек. Фикер хөрлегенә шунда өйрәндек без. Юкка гына мин, монда кайтып, листовкалар ыргытып йөрмәдем бит инде аннары…

«МОНДА ПОЛИТИКА БЕЛӘН ТҮГЕЛ, ПОЭТИКА БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНЕРГӘ КИРӘК»

– Мәскәүдә мине семинар җитәкчесе Лев Ошанин, ректорыбыз Владимир Пименов үз күрделәр. Бик күп ярдәмнәре тиде. Ректорга билгеле бер оешмадан листовка мәсьәләсе турында хат язып җибәргәннәр иде, әмма алар мине институттан кудырмадылар. «Это Литературный институт, здесь не политикой надо заниматься, а поэтикой» – шул иде аларның төп шигаре, үгет-нәсихәте. Казанда булсам, бәлки, ул чакта минем башым Себер киткән булыр иде.

Без, төрки халыклар, Кавказ республикалары, Алтай-Бурятиядән килгән егетләр-кызлар белән нык аралаша идек. Шулай бервакыт СССР тарихыннан лекция тыңлыйбыз. Аны безгә Сталинград шәһәре партия комитетының сугышка кадәр идеология буенча өлкә комитеты секретаре булган профессор Водолагин укыды. Ватан сугышы чорына килеп җиткәч, кырым татарлары турында сөйли башлады. «Крымские татары – предатели», – дигән җөмлә әйтте бу. Гомумән, татарларга тел-теш тидерә башлады. Минем йөрәгем дөп-дөп тибәргә кереште, җаным түзмәде: «Сез татарлар турында нахак сүз сөйлисез, моннан ары мин сезнең лекцияләрегезне тыңлый алмыйм», – дидем дә торып чыгып киттем. Аудитория артымда тып-тын калды. Ул чакта бит, бездә хөрлек уянып килсә дә, сәяси мәсьәләләр бик кискен тора иде. Эчемнән генә уйлый башладым: бетте, институттан куачаклар. Шулчак аудитория ишеге ачылып китте дә, Намжил Нимбуев исемле бурят егете килеп чыкты. Минем белән бер бүлмәдә яши иде ул, бурятларның искиткеч шәп шагыйрьләре. Калмык егете Олег Манджиев чыкты, монголлар, поляклар, эстон егете, хәтта берничә афроамерикалы студент та. Кыскасы, группадагы 25 кешенең яртысы диярлек… Эшне зурга җибәрмәделәр. Бу миңа бердәмлекнең нинди зур көч икәнлеген күрсәтте.

БЕЗ КАЙСЫ ШИНЕЛЬДӘН?

– Миңа әле шул вакытларда ук үзебезнең төрки әдәбият вәкилләре кызыклы, якын иде. Кумыкларны, карачайларны, ногайларны, казахларны, үзбәкләрне оригиналда укыйм, әлбәттә. Без бит без бер-беребезне тылмачсыз аңлыйбыз.

Кайберләрен тәрҗемә дә иттем. Кадрия исемле бик әйбәт шагыйрә укыды безнең белән. Гаҗәеп чибәр иде үзе, аңа гашыйк булмаган егет юк иде. Аны соңыннан Дагыстанда өстенә бензин сибеп, яндырып үтерделәр. Безгә хәбәре килеп иреште, бик үкенечле булды…

Алтай шагыйрьләре бик үзенчәлекле иде – үзләрендә сакланып калган борынгы дала рухы, табигый мәкаме белән.

Балачактан Такташ бик зур мәктәп булды. Такташ күңелгә тиз юл таба торган шагыйрь. Чөнки Такташ – халыкның үзеннән, аның теле – безнең яшәешебез теле. Безгә тагын зур тәэсир ясаган шагыйрьләр – Хәсән Туфан белән Сибгат Хәким. Шәхесләре, язмышлары аша да зур тәрбия бирделәр.

Замандашларыма килгәндә, ике кешене аерып куясым килә – Роберт Әхмәтҗанов һәм Мөдәррис Әгъләм. Мөдәрристәге фикер агышы гына түгел, сүз куәсе, гармониясе дә искиткеч. Ул каян килгәндер аңа, минем өчен – һаман да сер. Татар шигъриятенә ул чорда өр-яңа дөньяны, өр-яңа яңгырашны беренчеләрдән булып Роберт Әхмәтҗанов алып килде, дип саныйм.

ПРОЗАГА УРАУ ЮЛЛАР, ЯКИ КАРА МӨҺЕР

– Язмыйча түзеп булмаганда гына язарга кирәк. Яшьтәшләремә дә әйтәм: «Язмагыз, зинһар, уртакул шигырьләр, калыгыз шул яшь чактагы биеклегегездә», – дим. Яшьләр килә бит мәйданга: алар кызыклырак, заман теле белән сөйлиләр, үз чорының манифестларын яңгыраталар. Шагыйрь белән космонавтны чагыштырып карыйк әле: космонавт, гомер буе күккә менми бит, бер менеп төшкәч, ни генә булмасын, барыбер гомере буена космонавт булып санала. Шагыйрь дә шулай. Иң яхшысы – вакыты җиткәч, шигырьдән китеп, прозага күчү. Әмма моны бик сирәкләр генә булдыра ала.

Шулай берчак Мәскәүдә беренче курста укыган чакта Аяз Гыйләҗев килеп керде безгә, иҗат йортына барышлый сугылышы икән. Рәдиф белән икебез аңа шигырьләребезне укыдык. «Язгыгыз, сезнең әле шашып язар чагыгыз, әмма әйтәсе сүзне шигырьгә генә сыйдырып бетереп булмый, бөекләрнең пакусы киң була ул, проза да язып карагыз…», – диде. Мин шунда, тәэсирләнеп китеп: «Яза башлаган, тәмамланмаган повестем бар инде», – дип әйтеп ташладым. «Бер 10 көннән кайтам, укытырсың», – диде Аяз абый.

Аяз абыйның кульъязма астына «Шәп! Лихо!» дип язып куйган сүзләре дә бар. Батулла миңа машинкасын биреп торды, мин моны бастырып алдым. Язучылар берлегенә тапшырдым. Идарәдә зур аксакал язучылар – Мирсәй Әмир, Сибгат Хәким, Ибраһим Газилар тикшерде аны. Рафаэль Мостафин бик җылы сүзләр әйтте. «Татарстан китап нәшрияты»ның ул чактагы баш мөхәррире Марс Шабаев шулчак болай диде: «Совет чынбарлыгын каралтып күрсәткән Разил бу әсәрдә». Аяз агай инде мине яклап чыкты: «Ул бит талантлы язылган». Марс Шабаев: «Шул шул, талантлы язылган, талантлы булмаса, аны бастырып та булыр иде», – дип, тешләрен шыкылдатып киная белән «фәлсәфи» җавап кайтарды һәм әсәргә кара мөһер сукты. Шуннан соң ул 21 ел буе басылмыйча, үз сәгатен көтеп ятты.

«КАЙТЧЫ, ЗИНҺАР, СӨЕМБИКӘ…»

– Безнең буынга җыр мәсьәләсендә бәхет елмайды. Рәдиф Гаташ, Равил Фәйзуллин, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Роберт Әхмәтҗанов, Марсель Галиев, Роберт Миңнуллин, Фәннур Сафин һ.б. – барысының да сүзләренә көйләр иҗат ителде, аларны халкы-

бызның затлы композиторлары язды, затлы җырчылары сәхнәдән башкарды. Бу җырлар радио, телевидениедән даими яңгырап торды.

Халыкта шактый популяр «Зинһар өчен, кермә төшләремә» дигән җырны тормышымдагы бик каршылыклы вакытта, җиде ай буе хастаханәдә ятып, күп җәфалар күргәннән соң язган идем. Бер иҗат кичәсендә сәхнәдән укыдым. Венера Ганиева ишеткән булып чыкты аны. «Бу җыр бит көй сорап тора», – диде. Шигырьне Резеда Әхиярова күрсәткән. Төн уртасында икәүләшеп шалтыраталар: «Җыр яздык», – диләр.

«Сөембикә» җырын бик озак яздым. Бу тема минем өчен генә кадерле түгел, ә халыкның бәгырендәге яра да бит. Кызыма да мең җәфа белән кушкан идем заманында ул исемне.

Хәзерге эстрададагы җыр текстларына карата сорауларым күп минем. Акрынлап затлы телебезне очсызга әйләндерә барабыз. Профессиональлекне югалтабыз. Мин үзем дә югары музыкаль тәрбия алып үскән кеше түгелмен. Әмма безнең күңелгә әнкәйләр, апалар халык җырларын, гасыр башындагы югары зәвыкле көйләрне сеңдереп үстерделәр. Сәйдәшне, Яхинны... Җырга карата булган югары, каттый таләпләребез шуннан киләдер, дип уйлыйм.

Янарак кына шаулап узган «Үзгәреш җиле» концертында колагыма ятмаган, күңелем кабул итмәгән чыгышлар булды. Әйе, профессиональ югарылыктыр бу, бәлки, әмма берничек тә үзгәреш җиле түгел. Бер концерт белән генә татар эстрада сәнгатендәге торгынлыкны үзгәртеп булмый. Һәм – читтән кемнәрнедер чакырып та. Моң ул халыкның үз бәгыреннән үтеп чыгып, дөнья сәнгатендәге казанышларны үзләштереп, органик яңгырашка ирешсә генә, халык йөрәгенә үтеп керә ала. Җырчылар да үзләренә кадәр булган сәнгатьне йөрәге аша кичереп, шуңа нигезләнеп башкарса гына, милли сәнгать әсәрен тудыра ала.

Илһам Шакировлар, Әлфия Авзаловалар да төрле стильләрдә башкарды җырларны. Үз заманы өчен яңалык иде бу. Әмма алар халыктан, милли җирлектән аерылмаган иделәр.

«БЕЗ БЕР ЙОДРЫК ИДЕК»

– Дәүләт эшендәге кеше сәгать кебек эшли белергә тиеш. «Күңелсез түгелме, Разил, иҗатыңны корытмыймы бу эш?» – дип сораучылар да күп булды. Мине коткара торган нәрсә – һәр нәрсәгә иҗат дип карау.

Фәрит Мөхәммәтшинның шелтәләгәне бар: «Ник һәр фикереңә шулкадәр ябышып ятасың соң син, Разил, барыбер түгелмени инде – сөйләгәндә син бит аны җиренә җиткереп сөйлисең, аңлаганы аңлар, аңламаганы – юк». Әмма мин өстән-өстән «вакыт узсын, чабата тузсын»га гына эшли алмыйм. Чөнки, беләм: ул бит – минем чыгышым, минем кулым белән язылган, минем авыздан чыккан, мин аның өчен җаваплы. Ничек әдәби әсәр, җыр тексты язам, тәрҗемә итәм, монда да үземә шул ук принципны куям. Казна эшендә дә югары биеклектә калырга кирәк.

Монда шигырь, әдәбият – ят нәрсәләр. 90нчы елларда шушы обком бинасында – Югары Совет мөнбәреннән «Тотса мәскәүләр якаң» шигырен укыдым. Тукайның йөз ел элек язылган бу шигыре ул көннәрдә бик актуаль яңгырады. Шуннан соң, безгә – каләм әһелләренә парламентта булган мөнәсәбәт үзгәрә башлады. Әдәби әсәрнең, шигырьнең күңел ачу өчен генә язылмаганына, ә зур милли-иҗтимагый, хәтта ки сәяси мәсьәләләрне хәл итүдә дә зур роль уйнарга мөмкин булуына төшенделәр.

90нчы елларда без парламентта бер йодрык идек – Туфан Миңнуллин, Равил Фәйзуллин, Фәүзия Бәйрәмова, Ренат Харис, Роберт Миңнуллин депутат булган вакытлар бу. Тел мәсьәләләрен күтәреп кенә калмый, ә хәл дә итә ала идек. Вазгыять үзгәрде. Туфан абый – соңгы могикан – ул да китеп барды. Мин ул вакытларны еш сагынып искә алам...

«ТЕЛНЕ ҮЗЕБЕЗ САКЛЫЙ БЕЛМИБЕЗ»

– Дәүләт Советында телләр өчен җаваплы вазыйфада утырабыз икән, әлбәттә, аларның сакланып калуы, дәүләт дәрәҗәсендә кулланылышы өчен безгә хисап тотасы. Бу эш елдан-ел бик катлаулырак мәсьәләгә әйләнеп бара. Татарстан эчендә татар телен саклау турында сүз алып барабыз – уйлап кына карагыз әле! Россия белән мөнәсәбәтләр мәсьәләсенә килгәндә, хәлләр тагын да катлаулырак. Чөнки андагы хакимият безнең асылыбызны белми, аңламый. Җыенмый да. Ул безгә начар булсын дип тә эш йөртмидер, бәлки, татар мәнфәгатьләре – алар өчен үзәктә түгел, шул гына.

Элек туган телебезне авыл саклый иде. Авыл мәктәпләрендә чытырдатып үз телебездә укып килдек. Без – татарча, марилар – марича, чувашлар – чувашча... Шөкер, югалмадык. Бүгенге көндә Казанда 40тан артык милли мәктәп бар, дибез. Асылда, ул бүген дә – берәү генә.

Узган ел Дәүләт Советына бер документ килеп төште. «Россия мәктәпләрендә рус телен һәм әдәбиятын укыту» турындагы концепция иде ул. Исеме бик матур яңгырый, шик-фәлән тудырмый. Болай дип язылган: «Россиядә бүгенге көндә 4 меңнән артык милли мәктәп бар, һәм бу Россиянең куркынычсызлыгына яный». Ягъни безнең татар телендә укыта торган мәктәпләребез Россия дәүләтенә каршы зыянлы эш алып бара булып чыга. Тагын бер маддәсендә шундый сүзләр бар: «Россиянең бөтен мәктәпләрендә дә укыту рус телендә генә алып барылырга тиеш». Бу концепцияне әзерләү һәм гамәлгә ашыруның башында Россия Дәүләт Думасы җитәкчесе Сергей Нарышкин тора иде.

Мин әйтәм, бу гамәлгә ашса, бетәбез бит, Россиядә бер милли мәктәп тә калмаячак. 21 милли республика парламентлары белән бәйләнешкә кердем. Комитет рәисләренең кайсыберләре моны инде тиз генә хуплап кире Мәскәүгә җибәргән дә, артык уйлап та тормаганнар. Кердем Фәрит Мөхәммәтшинга. «Без моны хуплый алмыйбыз», – дидем. Очраштык мәгариф министры белән.

Концепцияне төзегән эшче төркемне Казанга Дәүләт Советына чакырып, түгәрәк өстәл уздырырга булдык. Россиянең Тел һәм әдәбият институты җитәкчелеген, галимнәрен чакырдык. Үзебезнекеләрне җыйдык. Укытучылар да килде, журналистлар да, депутатлар һәм республика җитәкчеләре дә. Безнең мәктәпләрдәге ситуацияне аңлаттык, галимнәребез сөйләде. Һәм элеге эшче төркем вәкилләренең карашлары бөтенләй үзгәрде. «Без бит ситуациягә бу яктан карамаган идек», – диделәр.

Бүген милли мәсьәләдә, Татарстаннан кала, бердәнбер активлык күрсәтүчеләр – якутлар. Ә 90нчы елларда без – 21 милли республика – бөтенебез дә бер фикердә идек.

– Илһам абыйның җыр сүзенә, җыр шигыренә таләбе зур иде, бу миңа иң беренче зур мәктәп булды. «Бер алманы бишкә бүләек»тә «кар аклыгы гөлгә күчкән, алмагачлар кояш эчкән» дип язган идем. Илһам абый әйтте: «Алай булмый, шигырь өчен матур ул – «кар аклыгы», ә җырлаганда бит «караклыгы» булып ишетеләчәк. Җырда сүзләрнең мондый тезмәсе булырга тиеш түгел», – диде. Бу минем күңелемә мәңгегә кереп калды. Мин аны «кыш аклыгы гөлгә күчкән» дип үзгәрттем.

Разил Вәлиевнең «Сагындыра моңлы җыр...» әңгәмәсеннән.

ВАКЫТ ШАВЫ, ЯКИ ТАРИХИ РЕТРОСПЕКТИВА

Яңа ел алдыннан без гадәттә нәтиҗәләр ясарга яратабыз. Үткән елыбызга, эшләгән эшләребезгә, ирешкән уңышларыбызга. Үзенә күрә бер еллык тарихи хисап-гамәл. Мин нәрсә эшләдем дә, мин әле кая юл тотам... Ә бит зур тарих чынлап та әнә шул эшләгән эшләребездән тукыла. Кешеләрдән. «Китап киштәсе» сәхифәсендә дә нәтиҗә ясарга булдык – дөнья һәм үзебезнең тарихыбызда эз калдырган, бүген дә эз салып баручы шәхесләр турындагы китапларга күзәтү ясап.

«ВАКЫТ – АНЫҢ КУЛЛАРЫНДА...»

ДЖУЛИАН БАРНС. «ШУМ ВРЕМЕНИ»

Инглиз язучысы, әдәбият тәнкыйтьчесе, бүгенге постмодерн әдәбиятының иң күренекле вәкилләренең берсе, Букер лауреаты Джулиан Барнс иҗатын үз итүчеләр һәм, бигрәк тә, үзебезнең совет композиторы Дмитрий Шостакович музыкасын яратучылар өчен «Азбука-классика» нәшрияты күптән көтелгән бүләген ясады. «Шум времени» китабы әлегә Казандагы китап кибетләренең киштәләрендә очрамаса да, кайбер әйдәп баручы электрон ресурсларда ул инде бар. Йөкләтеп алырга һәм укырга мөмкин.

Барнс рус классик әдәбиятына һәм, гомумән, рус мәдәниятенә мәхәббәте белән билгеле иҗатчы. Шуңа интервьюларында Шостакович турында әсәр язуы турында хәбәр итүеннән соң, рус укучысы аның иҗатына игътибарын тагын да арттыра төште. Мин дә көтеп алдым бу романны. Шул заманның тагын бер титаны һәм корбаны булган Осип Мандельштам белән параллель уяткан китапның ни рәвешле хикәяләүгә корылачагы кызыксыну уятты.

Әйтергә кирәк, күңелне кайтармады. Россиядә китапка куелган таләпләр, аңлашыла ки, Англиядәге китап сөючеләрнең генә түгел, ә дөньякүләм аудиториянекеннән дә шактый аерылып тора. Безнең өчен, әйткәнемчә, «Шум времени» – чираттагы әдәби әсәр генә түгел, ә заманны тасвирлаучы документ та. Без мондагы һәр нәрсәдән – тарихи факттан, каһарманның гамәл-жестларыннан, хәтта интерьердан да фальш табып алырга мөмкинбез. Чөнки, безнең тимер рәшәткә эчендә озын-озак еллар буена формалашкан үз тарихи хәтеребез, башта махсус «яшерелгән», ә аннары шау-гөр китереп «ачып салынган» хакыйкатебез бар. Менә шул менталь момент аеруча мөһим безгә бу әсәр белән танышканда.

Романда сурәтләнгән вакыйгаларда бу «читтән караш» үзен беркадәр сиздерә, ләкин борчып тормый. Сталин режимы, шәхес культы вакытында, «тимер рәшәткә» артында ничек яшәвебез белән кызыксыну британлыларда гомумән бик көчле икәненә дә басым ясарга кирәктер. Әйтик, узган җәйдә Петербургта Анна Ахматова музеенда – Фонтанный домда йөргәндә, анда гаиләсе белән бер британ мемуаристы килеп керде. Ул курку белән тыгызланган шул чор совет чынбарлыгы хакында том-том китаплар актарган, аны үтә җентекләп өйрәнгән булса да, исе китеп кат-кат сораштырды: «Сезнең әти-әниләрегез, әби-бабайларыгыз ничек яшәгән соң ул шартларда?»

Әсәрдә хикәяләү өченче зат исеменнән барса да, постмодерн вәкиле буларак, Барнс безне традиционлык белән ялыктырмый. «Быть Джоном Малковичем» дигән атаклы фильмдагыча, абсурд дәрәҗәсенә үк җиткереп, Малкович башына алып кермәсә дә, җай гына укучысын Шостаковичның уйларына, эмоцияләренә тоташтыра. Без, әйтерсең, бөек совет композиторы белән берьюлы уйлыйбыз, шикләнәбез, кайгырабыз, шатланабыз, карарлар кабул итәбез... Үзебез белән автор арасындагы чик югала,

Автор:
Луиза Янсуар

ә инде әсәр каһарманы күпмедер дәрәҗәдә безнең альтер эгобызга ук әйләнә.

Әсәр автор исәбенчә Шостакович язмышында хәлиткеч булган берничә мөһим вакыйгага нигезләнә. Беренче өлештә ул әле үз заманы турында читтәнрәк карап уйлана, борчыла, нәрсәдер сизенә, әмма бу каһарманыбызның әле чорның канлы учын кысмаган, аның марионеткасына әйләнү куркынычыннан ерак торган чагы. Алга таба Барнс безнең күз алдыбызга язмышындагы кыен борылышларда үтә читен җаваплы карарларга килергә, һәм заман вазгыятенең басымы астында үз намусы белән күзгә-күз калырга мәҗбүр ителгән иҗатчыны китереп бастыра. Вакыт-вакыт кыен булып китә, чөнки, без дә шунда – аның белән бергә. Безгә дә оят, тынгысыз, һәм куркыныч.

Ул чордагы Мәскәү консерваториясе директоры булган Александр Глазунов яшь-яшь Шостаковичның матди хәлен яхшырту нияте белән, аны стипендиягә тәкъдим итәргә була. Ә стипендиатларның кем булачагын Анатолий Луначарский үзе контрольдә тота. Һәм менә, Глазунов белән Шостакович турында сөйләшкәндә, Луначарский сорый:

–Ул сезгә ошыймы?

– Коточкыч яза, – ди Глазунов.

– Алай булгач, ник килдегез? – ди Луначарский.

Глазунов болай дип җавап кайтара:

– Миңа ошамый, ләкин эш анда түгел. Вакыт үзе – бу малайның кулларында.

Барнс әсәрендә нәкъ менә шуны чын киеренкелектә күрсәтә дә – иҗатчы һәм аның заманы, иҗатчы һәм Мәңгелек, бу икәүнең мөнәсәбәтләре, каршылыклары. Текст мине, филолог буларак, катламнары, интертекстуаль тыгызлыгы белән сокландырды. Бирედә Шостаковичның чордашлары һәрберсе үз стилендә, үз телендә «сөйләшә».

Әсәр композиторның музыкасын буеннан-буена сеңдергән: беренче әсәрләренең әле артык кычкырып тормаган шомлы куемтысы иңнәргә авыр кара шәлдәй килеп ятса, тора-бара симфонияләренең таныш ачыргалануы баш очыннан самолетлар булып оча башлый, җиргә гранаталар булып төшеп ярыла. Тантаналы, «бәхетле» совет чынбарлыгын сурәтләргә тиешле бу даһиның үз намусы белән тартышы да, системага карата булган яшерен, чын карашы да ишетелә...

ГАДӘТИ ТОРМЫШНЫҢ ГАДӘТИ БУЛМАГАН СИРПЕЛЕШЕ

БОРИС МЕССЕРЕР. «ПРОМЕЛЬК БЕЛЛЫ: РОМАНТИЧЕСКАЯ ХРОНИКА»

Быел илебезнең төп телеканалы – Беренче канал экранына чыккан «Таинственная страсть» фильмы шактый гына шау-шу һәм, әйтергә кирәк, кискен ризасызлык та тудырды. Тәнкыйтьләүчеләр лагерена керүчеләр күпчелекне тәшкил итте, дисәм, ялгышмам. Аеруча – әлеге сериалның үзәгендә булган алтмышынчы елгыларның иҗатын гына түгел, ә биографиясен дә шактый әйбәт белгән интеллектуаль аудитория вәкилләре пыр тузды. «Ничек инде шулай күзгә күренеп торган фактик төгәлсезлекләр булырга мөмкин?!», «Нәрсә әйтергә телиләр бу фильм белән?!», «Аксенов әсәре белән тәңгәллек мәсьәләсе дә – шикле...» Күпчелек танышларым беренче ике сериядән соң сабырын җуйды, сериал рейтингын күтәрүчеләр исемлегеннән төшеп калды.

Минем үземә «Таинственная страсть»ның беренче сериясен мәркәзебездә һәр елны зур тантана һәм кайгыртучан әзерлек, үзенчәлекле мөнәсәбәт белән үткәрелә торган «Аксенов фест» кысаларында карау мөмкинлеге тәтегән иде. Шунда ук миндә бик күп сораулар туып калды. Һәм, яшерен-батырын түгел, теге рейтингны бозучылар исемлеген мин дә тулыландырдым. Сүз уңаеннан, моңарчы шул ук иҗади богема тормышын тасвирлаган «Оттепель» сериалы җәмәгатьчелектә күпкә җылырак тәэсирләр калдырган иде.

Ул, бәлки, шулай булырга тиештер, хөкем итәргә алынмыйм, әмма «Таинственная страсть» әсәренең каһарманы калкытып куела да башкаларның шәхесләренә, гәрчә алар тарих битләрендә инде һәрберсе лаеклы урынын алган затлар булсалар да, шактый башбаштак якын киленә, дигән тәэсир калды миндә. Һәм менә шул хактагы уйларга бирелеп йөргән көннәрдә, Интернет-ресурсларның берсендә Борис Мессерерның яңарак кына сатуга чыккан китабына юлыктым. «Промельк Беллы: Романтическая хроника» дип атала ул китап.

Белла Ахмадуллина белән 36 ел дәвамында бергә гомер иткән елларындагы истәлекләргә нигезләнгән XX йөз рус поэзиясенең Анна Ахматова, Марина Цветаевалардан соң, үзенә күрә бер символы булган шагыйре Белла Ахмадуллина турындагы бу китап. Хәер, аны Белла турындагы китап дию бик үк дөрес тә булмас иде. Дөресрәге, бу – аларның бергә яшәгән чорларында үзара сөйләшүләре, рухи гәпләшүләре аша тудырылган тормыш мифологиясе. Балачак, Ватан сугышы еллары, чор катаклизмнары, Казан, иҗатка килү юллары, чордашлар...

Борис Мессерер үзе китапка керешендә шуны ассызыклый: безнең яшәешебезнең табигый агышында, барышында инде күп еллар элек үк туплана башлаган иде бу китап, ди. Сүз башым бит Шүрәле, дигәндәй, янәдән «Таинственная страсть»ка әйләнеп кайтыйм әле. Мине иң канәгатьләндермәгән каһарманнарның берсе анда Белла Ахмадуллина булды. Мессерер китабында сурәтләнгән Белла белән танышканчы ук аның турында шактый истәлекләр укыганым, аларны үзара чагыштырып, анализлап караганым булды. Мессерердагы образ миңа тагын шул ягы белән кадерле – ул күп еллар дәвамында ике иҗатчы – рәссам һәм шагыйрьнең үзләре тарафыннан яратып язылган, эшкәртелгән, чын мәгънәсендә сәнгать әсәре дәрәҗәсенә җиткерелгән сурәт.

Менә нәрсә ди бу хакта Мессерер:

Идея записывать, фиксировать свои наблюдения и впечатления укрепилась в моем сознании после того, как совпали наши с Беллой жизненные пути.

Я был не сторонним наблюдателем, а участником этой безумной, но счастливой жизни. Рассказ о человеческих взаимоотношениях и событиях нашей общей с Беллой жизни — не главное для меня в этой книге. Важнее образ самой Беллы, который я хотел бы донести до читателя.

Пусть говорит сама Белла, чтобы читатель снова был увлечен ее изумительной, неповторимой интонацией, заворожен гипнотическим влиянием ее речи. Как всегда, Белла говорила все это не для записи, а просто разговаривая со мной. Когда эти беседы были расшифрованы и легли на бумагу, то, перечитывая их, я заново начинаю понимать всю безмерность таланта Беллы. И еще мне хочется сказать об отсутствии у нее всякого тщеславия, что, быть может, было главным ее качеством.

Китаптагы иң ошаган үзенчәлек – зур игътибарның нәкъ менә балачакка, кешенең әле үзендә нинди көч йөрткәнен тоемлаган гына, формалаша башлаган чорына бирелүе. Мессерер моны махсус үзмаксат иткәндер дип уйлыйм, чөнки, ул – үзе дә иҗат кешесе. Дөресен генә әйткәндә, биограф һәм язучы-теркәүче буларак ул иҗатчы, тоемлаучыдан күпкә калыша. Ләкин нәкъ менә балачак, күпсанлы детальләр, беренче карашка, әһәмияте дә булмаган вакыйгалар чылбыры аша ул Беллага хас булган төп сыйфатларны барлый һәм укучыга да күрсәтә: нәни генә кызчык килеш башкаларның бәхетсезлеген күтәрә алмавы булсынмы ул, ташландык, яки бәлагә юлыккан этләр, песиләр турында кайгыртуымы, мәктәп белән каршылыкмы, сугыш елларында шәфкать туташы булып эшләүчеләрне фәрештәгә тиңләүме...

Кыскасы, Белла Ахмадуллина, мин шигырьләрендә тойганча, катлам арты катлам аша ачыла бара миңа. Мин аны горизонтальдә түгел, ә зигзагта, бөгәрләнеп беткән, әмма җете буяуларын, бизәген җуймаган тасмада күрәм. Шуңа да Мессерер, бәлки, вакытны төп каһарман иткәндер дә бу китапта. Әйе, әйе, Белланы түгел, ә аның белән бәйле ретроспективаны. Танылган шәхесләргә урын азрак бирелгән булу да аклый үзен. Алар турында мин, укучы буларак, инде болай да беләм.

Гадәти тормышның гадәти булмаган нур-сирпелеше – Белла Ахмадуллина шигъриятенең бар тылсымы әнә шул бит. Китапта мин әнә шул сирпелешнең җуелмаган яктысын шәйләдем.

ҮЗЕБЕЗНЕҢ ТАРИХ ДИСБЕСЕНДӘГЕ БЕР БУЫН

ИНДУС ТАҺИРОВ.
БЕЗ ТАРИХТА ЭЗЛЕБЕЗ.

Менә монысы инде – минем үз заманым. Бирегә җыелган шәхесләр дә – балачактан мин радио, телевизордан ишетеп-карап, газета-журналлардан укып белгән затлар. Яңа заман тарихын язучылар.

Индус абый Таһировны иң беренче чиратта тарихчы буларак беләбез. Аннары инде – җәмәгать, сәясәт эшлеклесе буларак. Китапларына килгәндә дә, тарихка кагылышлыларын, һәм публицистик язмаларын гына укыганым бар иде моңарчы. Ә бу юбилей уңае белән басылып чыккан тупланмасын китап кибетендә актарганда, бер бүлегә җәлеп итте – «Көрәштәшләрем һәм дусларым турында» дип атала ул. Һәм, нигездә, бу китапны сатып алырга этәрүче дә әнә шул бүлек булды. Индус абыйның замандашлары портретларын ничек сурәтләве, аларның галереясен нинди эзлеклелектә туплавы кызыклы.

Шушы кечкенә генә язмаларымда арабыздан киткән һәм исән замандашларымны тасвирларга тырыштым. Аларга биргән бәяләмәләрем – тик минем үз фикерем генә...

Шулай дисә дә, һәр шәхескә бәйле истәлекләрендә һәм уйлануларында үзе яшәгән чорның вакыйгаларына, детальләренә дә туктала, әлбәттә, Индус Таһиров. Шул рәвешле, без аларның артындагы фонны «укыйбыз». Нигездә, ул туры һәм гади яза, артык катлауландырмый, боларны нинди дә булса аерым бер жанрга кертү мәсьәләсе дә еш кына минем өчен ачык сорау булып кала. Эскизлар, дияргәдер, бәлки.

Шунысы әһәмиятле бу истәлек язмаларда – Индус абый тормыш-көнкүрештә, аннан да бигрәк җәмәгать эшендә очратып-белгән һәм иңгә-иң торып эш иткән кешеләр турында гына яза. Нигездә, ул шәхес белән үзенә кагылышлы вакыйгаларга туктала да, фикерен җөпләп, замандашы хакында үз нәтиҗәсен ясап куя. Артыгын исә Вакытның һәм тарихның үзенә калдыра. Ә, бәлки, әлеге талантлы татар улларының һәм кызларының биографларына...

Менә аның портретлар галереясы: Рәмзи Вәлиев, Риф Хәйретдинов, Сәлам Алишев, Миркасыйм Госманов, Нурмөхәммәт Хисамов, Разил Вәлиев, Равил Фәйзуллин, Нурихан Фәттах, Җәмит Рәхимов, Әнвәр Шәрипов, Михаил Аверьянов, Хәйдәр Бигичев, Фән Вәлиәхмәтов, Айдар Фәйзрахманов, Мирсәет Сөнгатуллин, Фаяз Ибраһимов... Бу шәхесләрнең һәркайсы белән аны төрле еллар белән исәпләнгән һәм сыналган аралашу бәйли. Кайберләре белән – иптәшлек, дуслык та. Әмма язганда, ул һәркайсына, хиссият-тойгыларга бирелмичә, тигез бер объективлык белән якын килә.

Ул вакыт мин Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты рәисе идем. Нурихан Фәттахның иҗат кичәсен, дөресрәге, фәнни эшчәнлегенә, бигрәк тә әнә шул Фест дискына багышланган утырышны Конгресс бинасында үткәрик, дигән тәкъдим керттем. Моны күпләр хуплап каршы алды. Тик менә аның үзен күндерү һич кенә дә җиңел булмады. Киреләнде, дип әйтер идем, ул андый кире кеше түгел. Тыйнаклык күрсәтте, дип әйтер идем, ул, дөресен әйтергә кирәк, үз бәясен үзе белә килде. Бәлки, ул мондый инициативаның югары дәүләт органнарыннан чыккан булуын көткәндер? Күрәсең, шулайдыр. Рәнҗегән булуы да ихтимал. Ләкин ул моны сиздермәде. Ул горур кеше иде.

Дөресен әйтергә кирәк: бу утырышта катнашучылар шушы олы шәхескә, аның фәнни хезмәтләренә, әдәби әсәрләренә зур бәя бирделәр. Мин үз чыгышымда адәм баласына тиешле бәяне үзе исән чагында бирергә кирәклеген ассызыкладым. Инде менә ул фани дөньядан киткәч тә, мин аның бөек шәхес булуын тагын бер кат кабатлыйсым килә.

Мин мәктәпнең югары сыйныфларында Нурихан Фәттахның тарихи әсәрләрен кат-кат укып, аның Фест дискы турындагы фаразларыннан үз тарихыма горурлык белән карап тәрбияләнгән буын баласы. Профессиональ тарихчы булмаган килеш, татар тарихы чоңгылларына баштанаяк чумган, татар әдәбиятына яңа бер сулыш алып килгән язучының тормышы белән бәйле кечкенә генә, тыйнак кына, хәтта ки саран гына дип әйтер идем, шушы истәлек минем күз алдыма соңгы ике дистә ел эчендә инде үземнең күз алдымнан узган тарих борлышларын китерә дә бастыра. Индус абый үзе шаһит булган бер вакыйга хакында бәян итә, ә мин, шуны укып, кая барганыбызны ваемлауга күчәм.

Җырчыларга мөнәсәбәте дә үз тоелды миңа Индус абыйның. Айдар Фәйзрахманов турындагы язмасы, мәсәлән, аның дискы чыгу уңае белән язылган, татар фольклорын туплап, аны зәвыклы рәвештә халыкка җиткерүнең әһәмиятен ассызыклый язмасында Индус абый. Ә Фән Вәлиәхмәтов белән аларны җылы, дустанә мөнәсәбәтләр бәйләвен аңлап аласың тел төбеннән:

Дөнья малына табынып яшәмәс, аның өчен иң кыйммәтлесе – рухи байлык. Ул халыктан чыккан, аның белән гомер кичерә.

Бәкердә вакытта аңардан: «Ниләрең бар, ниләр корып ятасың?» – дип сорагач, ул: «Авылда атамнан калган йортым, ике кәҗәм, өч сарыгым, бер хатыным бар», – дип җавап бирде.

«Без тарихта эзлебез» аша без соңгы еллардагы иҗтимагый-мәдәни тормышыбыз турында күбрәкне белә алабыз. Үзебезнең татар китабы сатыла торган киштәләрдә таба аласыз. ■

МАХСУС ПРОЕКТ

— 18нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

PRESSA.RU

Николай Колесов, «Ростех» дәүләт корпорациясенең «Радиоэлектрон технологияләр концерны» АҖ генераль директоры, декабрьдә үзенең 60 еллык юбилеен билгеләп үтә.

Сергей Анохин,
«Раменск приборлар төзү заводы» АҖ генераль директоры

ЛИДЕРЛЫК СЫЙФАТЛАРЫГЫЗ АЛГА БАРЫРГА ЯРДӘМ ИТӘ!

Хөрмәтле Николай Александрович!

Сезне «РПТЗ» АҖ коллективы һәм үз исемемнән туган көнегез белән тәбрик итәм!

Сез ниятләрегезне тормышка ашыра беләсез, үз эшегезнең остасы буларак ихтирам уятасыз һәм вакыт белән бергә атлыйсыз – без боларның барысына да сокланабыз. Лидерлык сыйфатларыгыз һәрвакыт алга барырга, югары максатларны тормышка ашырырга, бердәм куәтле «Радиоэлектрон технологияләр концерны» АҖ кысаларында эшне төгәл һәм җайлы итеп оештырырга ярдәм итә.

Сезнең җитәкчелек астындагы КРЭТка динамик үсеш һәм яңа техник казанышлар телим.

Безнең үзара хезмәттәшлегебез алга таба тагын да нәтиҗәлерәк, уңышлырак һәм тыгызрак була барыр дип ышанам.

Сезгә нык сәламәтлек, тулы канлы актив тормыш, күңел көрлеге, бәхет һәм иминлек телим! Һәрвакыт уңышлар юлдаш булсын, һәр көнегез иҗади энергия, туганнарыгызның һәм якыннарыгызның җылысы белән тулып торсын, ә белемегез, тәҗрибәгез һәм эшкә бирелгәнлегегез Россия файдасына озак еллар хезмәт итсен!

КРЭТ
РПЗ

Реклама

ЗУР МАСШТАБКА ИЯ ҖИТӘКЧЕ

Николай Александрович Колесов кебек кешеләр турында озаклап һәм кызыклы итеп сөйләргә мөмкин. «Ростехнология» дәүләт корпорациясенең «Радиоэлектрон технологияләр концерны» АҖ генераль директоры үзенең юбилеен бәйрәм итә. Концернга керүче предприятие – «П. А. Ефимов исемендәге «Электроавтоматика» Тәҗрибә-конструкторлык бюросы» АҖ исеменнән Андрей Владимирович Гурьянов Николай Александровичны истәлекле дата белән тәбрик итә һәм нәтиҗәле хезмәттәшлек өчен рәхмәт сүзләрен җиткерә.

Андрей Гурьянов,
«Электроавтоматика» ТКБ» АҖ генераль директоры вазыйфаларын вакытлыча башкаручы

Хөрмәтле
Николай Александрович!

«П.А. Ефимов исемендәге «Электроавтоматика» Тәҗрибә-конструкторлык бюросы» АҖ коллективы һәм үз исемемнән юбилеегыз белән тәбрик итәм! Сезнең бай тәҗрибәгез, оештыру һәм җитәкчелек итү сәләтегез, максатчанлыгыгыз һәм үз сүзегездә нык торучанлыгыгыз хезмәт баскычы буйлап уңышлы рәвештә күтәрелергә ярдәм итә. Профессиональ үсеш юлыгыз да соклангыч – Казан заводы эшчесеннән «Радиоэлектрон технологияләр концерны» АҖ генераль директорына кадәр күтәрелдегез. Бүген Сезнең җитәкчелек астында яңа проектлар тормышка ашырыла, Россия Федрациясенең оборона сәләте хакына предприятиеләр камилләшә һәм яңартыла.

Сезне хаклы рәвештә югары звеноның иң тәҗрибәле һәм абруйлы, белемле һәм иҗатка сәләтле җитәкчеләренең берсе дип исәплиләр. Энергиягез, тормыш тәҗрибәгез, күпкырлы белемгә ия булуыгыз, оештыру сәләтегез оборона-промышленность комплексы алдында торган бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән үзгәртеп коруларны, «КРЭТ» АҖ радиоэлектрон промышленносте концерны үсешенең яңа перспективаларын ачучы проектларны уңышлы тормышка ашырырга ярдәм итә.

Сезнең күп еллык фидакарь хезмәтегез, сайлаган профессиягезгә тугрылыгыгыз лаеклы рәвештә мактаулы исемнәр белән билгеләп үтелгән. Сез – РФ Табигать фәннәре Академиясенең хакыйкый әгъзасы, Халыкара сыйфат һәм маркетинг Академиясе почетлы академигы, Хәрби фәннәр Академиясенең хакыйкый әгъзасы, Татарстан Республикасы дәүләт премиясе лауреаты (2002), ТР Атказанган машина төзүчесе. Югары дәүләт бүләкләре, шул исәптән III һәм IV дәрәҗәле «Ватан алдындагы казанышлар өчен», Дуслык орденнары, җиде медаль белән бүләкләнгәнсез.

Сез – менә дигән гаилә башлыгы һәм эшегезне дәвам итүче балалар тәрбияләгән кайгыртучан ата. Бөтен гаиләгезгә тынычлык, сәламәтлек һәм иминлек телибез!

Чын профессионал һәм тәҗрибәле белгеч кенә 100 дән артык предприятиене берләштергән оборона кластеры белән аның ышанычлы икътисадый үсешен тәэмин иткән хәлдә җитәкчелек итә ала. Предприятиеләрнең камилләшүе һәм яңартылуы, яңа проектларның гамәлгә кертелүе, хезмәткәрләрнең социаль мәнфәгатьләре яхшыру – болар барысы да Сезнең хезмәт нәтиҗәсе.

Иң кыю ниятләрегезне һәм барлык проектларыгызны тормышка ашыруыгызны, алдыгызга куйган максатларыгызга ирешүегезне телибез! Күтәренке кәеф һәм яңа биеклекләр юлдаш булсын!

Сезнең белән нәтиҗәле хезмәттәшлек итүебез белән без нык горурланабыз, моның өчен чын күңелдән рәхмәт белдерергә рөхсәт итегез! Иң яхшы теләкләребез чынга ашсын иде!

Реклама

PRESSA.RU

Иң кыю планнарыгыз тормышка ашсын!

Ронис Шәрипов,
«Шимко исемендәге «Радиоэлектроника» ФҖБ» АҖ генераль директоры

Рөстәм Абдуллин,
«Радиоприбор» АҖ башкарма директоры

Айрат Хөснетдинов,
«Әлмәтнең «Радиоприбор» заводы» АҖ башкарма директоры.

**Хөрмәтле
Николай Александрович!**

Барлык партнерларыгыз һәм хезмәттәшләрегез Сезне бай тәҗрибәсен, белемен һәм көчен үзенең эшенә багышлаган тырыш һәм белемле җитәкче буларак белә. Сез Россиянең радиоэлектрон тармагындагы иң эре холдингларының берсе булган «Радиоэлектрон технологияләр концерны» АҖ оештырган күпсанлы предприятиеләр белән уңышлы җитәкчелек итәсез. Идарә итү сәләтегезнең һәм шәхси җаваплылыгыгызның югары дәрәҗәдә булуы Сезгә яңа проектларыгызны һәм планнарыгызны яхшы сыйфатлы итеп башкарырга мөмкинлек бирде, һәм моның өчен күпсанлы лаеклы бүләкләргә ия булдыгыз. Сезнең җитәкчелек астында Концерн предприятиеләрендә фәнни-тикшеренү эшләре алып барыла, яшь хезмәткәрләргә һәм галимнәргә авиация промышленносте өлкәсенең перспективалы юнәлешләрендә эшләргә мөмкинлек тудырыла. Сез Концерн предприятиеләрендә чын профессионалларны саклап кала алдыгыз, һәм бу гаять катлаулы проектларны уңышлы тормышка ашырырга мөмкинлек бирә.

Николай Александрович, юбилеегыз уңае белән предприятиеләребез коллективларының ихлас котлауларын җиткерәбез, иминлек һәм бәйрәм күтәренкелеге телибез! Без һәрчак Сезнең ярдәмегезне һәм аңлавыгызны тоеп яшибез, һәм бу предприятиеләребез үсешенә нык ярдәм итә.

Хөрмәтле Николай Александрович, алдагы казанышларыгыз үткәннәренә караганда да уңышлырак булсын, Концернның финанс күрсәткечләре тайпылышсыз үсеп торсын, холдинг үсеше буенча гаять зур планнарыгыз тормышка ашсын! Бетмәс-төкәнмәс энергиягез һәммәбезгә дә яңа биеклекләр яуларга ярдәм итсен, тәҗрибәгез һәм профессиональ сиземләвегез яңа максатларга алып барсын! Үзегезгә һәм якыннарыгызга бәхет һәм нык сәламәтлек телибез!

Иң яхшы теләкләр белән,

*«Шимко исемендәге «Радиоэлектроника» ФҖБ» АҖ
генераль директоры Ронис Шәрипов,*

*«Радиоприбор» АҖ
башкарма директоры Рөстәм Абдуллин,*

*«Әлмәтнең «Радиоприбор» заводы» АҖ
башкарма директоры Айрат Хөснетдинов.*

АНЫҢ ЯЗМЫШЫНЫҢ ШӘҺӘРЕ

Игорь Куляжев

Игорь Куляжев, Казан башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – тышкы төзекләндерү комитеты рәисе, декабрьдә үзенең туган көнен билгеләп үтә. Башкарма комитетында Игорь Владимирович чынлыкта бөтен шәһәрнең торышын билгеләүче юнәлешкә күзәтчелек итә. Аның җаваплылыгында – юллар челтәренең торышы һәм аны алга таба камилләштерү, мәйданнарны һәм урамнарны яшелләндерү, паркларны һәм скверларны карау һәм үстерү, шәһәр сулыклары, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм башка бик күп нәрсәләр. Куляжев һәм аның командасы шундый зур бурычларны ничек башкарып чыга торгандыр, моны ул үзе генә беләдер, мөгаен. Һәрхәлдә, биредә тәҗрибә һәм профессиональлек хәлиткеч роль уйный. Игорь Владимирович чирек гасырга якын шәһәр төзекләндерү һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә хезмәт куя. Бу эшнең ни дәрәҗәдә уңышлы башкарылуын беренче чиратта аның язмышының шәһәре – бүгенге гүзәл Казан йөзенә карап фикер йөртергә була.

Олег Калимов,
«Мәскәү районы ТКХ ИК» ҖЧҖ директоры

Нәтиҗәле эшегез – Казанның гөрләп үсүенә зур өлеш ул!

Хөрмәтле
Игорь Владимирович!

Сезне туган көнегез белән котлыйбыз! Торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендәге хезмәтегез – республикабыз башкаласының төзеклеге һәм гөрләп үсүе эшенә шактый зур өлеш кертү дигән сүз. Җаваплы, белемле җитәкче, тәҗрибәле оештыручы буларак, Сез зур абруй казандыгыз. Үз дигәнегезне итә белүегез һәм куелган бурычларны хәл итүдә өзлексез рәвештә нәтиҗәле юллар эзләвегез шәһәр үсешенә юнәлтелгән киңкырлы эшчәнлегегездә һәрвакыт юлдаш булсын!

Сезгә корычтай нык сәламәтлек һәм иминлек телибез!

PRESSA.RU

Хезмәт юлын профессиясенең иң түбән баскычларыннан башлап, бар мөмкинчелеген яраткан эшенә багышлау һәм шуның белән зур уңышларга ирешү һәркемгә дә бирелми. Владимир Васильевич Пресняковның хезмәт юлы хезмәттәшләре арасында олы хөрмәт уята һәм яшь хезмәткәрләр өчен үрнәк булып тора. «ТАИФ» ААҖ генераль директорының нефтехимия һәм нефть эшкәртү буенча урынбасары үзенең 65 яшьлек юбилеен билгеләде.

ТАРМАК ҮСЕШЕНӘ КЕРТКӘН ӨЛЕШЕГЕЗ ӨЧЕН РӘХМӘТ БЕЛДЕРЕП

Бүген нефтехимия һәм нефть эшкәртү Татарстан икътисады драйверларының берсе булып тора. Республикада нефть эшкәртү тармагының үсешен һәм алга китешен Владимир Васильевич Пресняков кебек чын профессионаллардан башка күз алдына китереп булмый.

Владимир Васильевич үзенең хезмәт юлын профессиясенең иң түбән баскычларыннан башлаган. 18 яшендә Түбән Кама нефтехимия комбинатында электрослесарь укучысы булып эшли башлаган. Бер үк вакытта Казан химия-технология институтында укыган. Аны 1976 елда тәмамлаганнан соң, Түбән Кама шин заводының ремонт-механика цехына механика участогы мастеры итеп кабул ителгән. Бер елдан соң Түбән Кама нефтехимия комбинатында химик җиһазлар ремонтлау буенча өлкән мастер итеп билгеләнгән.

80 нче еллар башына кадәр Владимир Васильевич өлкән мастер һәм комбинат цехларында механик булып эшләгән. 1985 елда берләшмәнең капиталь төзелеш идарәсе башлыгы урынбасары итеп күчерелгән һәм шул ук елны «Петрокам» уртак предприятиесендә баш инженер булып эшли башлаган. 1991 елдан – «Полиформ» фирмасы директоры.

1997 елда «Түбән Кама Нефтехим» ААҖ генераль директорының җитештерү һәм икътисад мәсьәләләре буенча ярдәмчесе итеп билгеләнгән. 1998 елда шунда ук – урынбасар, аннары беренче урынбасар итеп куелган.

2003 елдан алып бүгенге көнгә кадәр «ТАИФ» ААҖ генераль директорының Татарстан Республикасы өчен гаять мөһим юнәлешләр – нефтехимия һәм нефть эшкәртү буенча урынбасары булып тора.

Владимир Васильевичның күпьеллык фидакарь хезмәте күпсанлы исемнәр һәм бүләкләр белән билгеләп үтелгән:

– 2005 елда «Казанның 1000 еллыгы хөрмәтенә» медале белән бүләкләнгән;

– 2006 елда «ТР атказанган химигы» дигән мактаулы исем бирелгән;

– 2009 елда Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән фән һәм техника өлкәсендә РФ Хөкүмәтенең 2008 елгы премиясе тапшырылган һәм «Фән һәм техника өлкәсендә Россия Федерациясе Хөкүмәте премиясе лауреаты» дигән исем бирелгән;

– 2015 елда «Россия Федерациясенең атказанган химигы» дигән мактаулы исем бирелгән.

Хөрмәтле Владимир Васильевич!

Без Сезне оста җитәкче, тәҗрибәле идарәче, энергияле һәм җаваплы кеше буларак беләбез. Сез җитәкли торган нефтехимия һәм нефть эшкәртү юнәлешләренең иң уңышлылардан берсе булуы, перспективалы һәм динамик төстә үсеп баруы башлыча Сезнең тырышлык, уңышка ирешүне даими максат итеп куя һәм стратегик әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итү өчен үз тирәгезгә югары классы белгечләр туплый, команда белән эшли белүегез һәм үзегезне яраткан эшегезгә тулысынча багышлавыгыз нәтиҗәсе дип ышанычлы рәвештә әйтергә була.

Сезнең актив катнашуыгыз белән ТАИФ компанияләре төркеме тарафыннан республикада күп кенә игелекле эшләр башкарылды, Татарстан һәм Россия өчен стратегик әһәмиятле булган программалар һәм зур проектлар тормышка ашты, һәм киләчәктә алда тагын да күбрәк эшләр тора әле. Уртак эшебезнең үсеше һәм алга китеше өчен керткән өлешегезнең кадерен без бик яхшы беләбез.

Сезне чын күңелдән юбилеегыз белән тәбрик итәбез, нык сәламәтлек һәм озын гомер, бәхет һәм иминлек, яңа офыклар, яхшы кәеф һәм Татарстан белән Россия бәхете өчен яңа профессиональ җиңүләргә ирешүегезне телибез!

Хөрмәт белән, ТАИФ компанияләре төркеме исеменнән,
«ТАИФ» ААҖ Генераль директоры А.К.Шиһабетдинов

Реклама

Көндәлек иҗади эшчәнлегегез сөенеч китерсен!

Азат Бикмурзин,
«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ
генераль директоры

Хөрмәтле Владимир Васильевич!

Тормышыгыздагы истәлекле вакыйга – туган көнегез белән ихлас күңелдән тәбрик итәм!

Бу көн Сезгә – ТАИФ КТ уңышына лаеклы өлеш кертүче абруйлы, таләпчән җитәкчегә, белемле һәм югары профессиональ белгечкә хөрмәт хисләрен белдерү өчен менә дигән мөмкинлек. Сез һәрвакыт вакыт белән бергә атлыйсыз, гаять киң белемегез һәм хезмәт сөючәнлегегез белән зур ихтирам казандыгыз һәм танылу алдыгыз.

Бу тантаналы көндә чын күңелдән нык сәламәтлек, рухи күтәренкелек, иҗади озын гомер телим! Һәр көнегез Сезгә шатлык бүләк итсен! Эшлекле сыйфатларыгыз, хезмәттәшләрегезнең ышанычы һәм ярдәме яңа казанышларыгызның нигезе булсын!

Сез – югары дәрәҗәдәге белгеч!

Хөрмәтле Владимир Васильевич!

Ринат Шәрәпов,
«Түбән Кама өченче монтаж идарәсе» ААҖ
генераль директоры

«ТБМИ-3» ААҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән 65 яшегез белән тәбрик итәм!

Сез электрослесарьдән алып, Россия Федерациясенең иң эре предприятиеләренең берсе – «ТАИФ» ААҖ генераль директоры урынбасарына кадәр гаять зур юл үттегез. Илебезнең нефть химиясе һәм нефть эшкәртү тармагы үсеше эшендә профессиональ югарылыкка ирештегез. Сез – иң югары дәрәҗәдәге белгеч: галим буларак та, технолог һәм механик буларак та, сәләтле оештыручы буларак та. Тормышта ирешкән барлык казанышларыгыз – тырыш хезмәтегез, көчле холкыгыз, шәхси сыйфатларыгыз нәтиҗәсе.

Юбилей көнегездә алга таба да үзегез булып кала алуыгызны телибез. Нык сәламәтлек һәм иминлек юлдаш булсын сезгә! Профессиональ, принципиаль булуыгыз, стратегик дөрес карарлар кабул итә белүегез киләчәктә дә нәтиҗәле эшегезнең һәм ТАИФ компанияләр төркемендәге предприятиеләр үсешенең нигезе булып хезмәт итсен.

PRESSA.RU

Без җирле риваятьләр туплауны дәвам итәбез. Бүгенгесе Иске Чүриле авылыннан язып алынган. Ә киләсе язмабыз сезнең җирлектән дә булырга мөмкин. Риваятьләр эзләүгә сез дә кушылыгыз – аларны редакциягә җибәрегез, һәм без, бергәләп, Татарстанның барлык риваятьләрен бергәләп тупларбыз.

ТАТАРСТАН РИВАЯТЬЛӘРЕ: 77

ХӘЗИНӘ ЭЗЛӘҮЧЕ

Арчага кергәндә кунакларны Казанның Изге Ана иконасы гыйбадәтханәсе каршы ала. Гыйбадәтханәне XIX гасырда төзегәннәр, ә XX гасырда аны, революция традициясе буенча, складларга әйләндергәннәр. 60 ел дәвамында биредә башта орлык, соңрак авыл хуҗалыгы техникасын саклаганнар. 90нчы елларда өлкән поп килгәч, мәхәллә кешеләрендә чиркәүне кабат торгызу өмете туган. Әмма поп ремонтны башлап кына өлгергән, ничек килгән булса, озакламый шулай ук кинәт кенә юкка да чыккан. Менә шунда Чүриле халкы фаҗигале язмышлы тагын бер поп белән булган куркыныч вакыйганы искә төшергән.

Бу хәл 1930 елның 10 августында була. Чиркәү ябылгач, Василий Пантелеев дигән руханины атып үтерәләр. Гәүдәсен идән астына ташлыйлар. Күп еллардан соң мәхәллә кешеләре, шунда төшеп, руханиның мәетен күмәргә ниятли, әмма анда… бер өем кеше баш сөякләре табалар. Алар барысы 78 була.

Җирле халык моны ни дип фаразларга да белми. Ә өлкән яшьтәгеләр элек-электән халык телендә йөргән бер риваятьне искә төшерә. Имеш, бер бай чиркәүдә үзенең хәзинәсен яшергән һәм шундый сүз тараткан: янәсе, ул хәзинәне сихерләп күмгән, кем дә кем аңа кагыла, ул кеше шунда ук егылып үләчәк. Хәзинә эзләргә теләүче кыю егетләр сихергә ышанмаган, ә кайсылары хәзинә чиркәүдә күмелгән булгач, сихернең анда көче булмаячак дип уйлаган. Әмма, күрәсең, ялгышканнар. Бер баш сөяге атып үтерелгән руханиныкы булса, калган 77се хәзинә эзләүчеләрнеке булып чыга инде.

Шуннан бирле авыл халкы чиркәүнең идән астына төшәргә шикләнә. Күз читен генә төшереп алучылар булгалый, билгеле, әмма алар да комсыз хәзинә эзләүчеләрнең төрбәсен тынычсызларга кирәкми дип исәплиләр – бәхетнең акчада, хәтта аның күләмендә дә түгел икәнлеген шулар язмышы тагын бер кат раслый лабаса.

АЙ КӘЕФЕ: «ТАТАРСТАННЫКЫ»

Декабрь аенда «Татарстан» журналы традицион рәвештә яңа язылучылар эзли һәм моңа кадәр булганнары белән дуслык җепләрен ныгыта. Быелгы язылу кампаниясе вакытында без Казандагы эре сәүдә үзәкләре белән килешүгә ирештек. Шулай ук «Татмедиа»га килүчеләр #2017елгаЯзылуБүләкИт акциясендә катнаша алды. Алар, балалар һәм картлар йортларын яздырып, матур бүләк тә ясадылар. Һәм журналыбызның төп соравына җавап бирделәр: «Мин «Татарстанны» ни өчен яратам?»

#МинТатарстанныНиӨчен ?

Гөлнара ГАЙНЕТДИНОВА, ТР Фәннәр академиясенең Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану институтының икътисад һәм планлаштыру бүлеге җитәкчесе:
– Монда кызыклы һәм яшәү шартлары уңайлы булганга...

Гөлчәчәк НӘҖИПОВА, ТР Милли музееның генераль директоры:
– Мин үзем Татарстанда тудым, Татарстан белән горурланам, һәм, әлбәттә, «Татарстан» журналын укыйм.

Айрат ГАТИЯТОВ, ТР Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министры урынбасары:
– Монда һәркем үз максатларын тормышка ашыра ала. Ә «Татарстан» журналы республика тормышын бар яклап яктырта.

Светлана РЫЖОВА, хуҗабикә:
– Биредә тудым, биредә яшим, ничек үз ватаныңны яратмаска мөмкин?

Сәбрия СӘМИРХАНОВА, пенсионер:
– Татарстанның бөек тарихы бар. Һәм монда бик яхшы кешеләр яши.

Рәмзия ИЛЬҺАМОВА, рәссам:
– Мин Татарстанда яшим. Мин Татарстанны картиналарымда чагылдырам һәм укучыларымны да мондагы матурлыкны киндергә төшерергә өйрәтәм.

Алла ПРОКОФЬЕВА, Самарадан килгән кунак:
– Татарстан миңа бик ошый. Монда минем туганнарым яши. Мин аларга еш кунакка киләм һәм, ни гаҗәп, килгән саен китәсем килми!

Гадел ГАЛЛӘМОВ, «Техвент» ҖП» ҖЧҖнең коммерция буенча директоры:
– Мин Татарстанны монда яшәгән кешеләр, һәм аларның хезмәте, иҗаты өчен яратам.

Станислав БАЙРАШЕВ, Май экстракцияләү заводы мастеры:
– Мондагы киңлекләр, салкын кыш һәм эссе җәйләр өчен – җаның ни тели, барысы да бар бездә.

Венера ЗЫЯТДИНОВА, пенсионер:
– Бу туфракта бөек язучылар һәм шагыйрьләр туып-үскән. Габдулла Тукайның туган тел турындагы шигырен укыганда, күзләрем яшьләнми калмый.

Кирилл ПОНОМАРЁВ, ТР Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары, Россия халыкара туризм академиясенең Казан филиалы директоры:
– Безнең Татарстанда тормыш матур, яшәү рәхәт, моңа инанып өчен, Агропромпаркка бару да җитә.

Елена ТРОИЦКАЯ, КНИТУ-КХТИ студенты:
– Табигатенең матурлыгы өчен. Кунакчыллык өчен. Безгә соңгы елларда бик күп башка шәһәрләрдән һәм илләрдән кунакка агылалар. Бу мине бик сөендерә! Алар алдында Казаныбыз һәм республикабыз өчен йөзебез кызарырлык түгел.

«Татарстан» журналының язылу кампаниясенең генераль иганәчесе – «ПРОСТО МОЛОКО» ИК

Реклама, 16+

PRESSA.RU

Реклама 16+